Спустя десять лет, в 1935 году, появилось Татарское культурное общество (Finlandiya Turkleri Birligi), которое помимо религиозных праздников и обрядов начало устраивать культурные мероприятия со спектаклями, народной музыкой и танцами, декламацией стихов. Есть сведения об успешных премьерах драматических произведений Сании Гыйффат. Пьесы и драмы С. Гыйффат были востребованы в Финляндии, Эстонии, Китае, Румынии. В январе 1937 г. в Хельсинки с большим успехом прошла премьера её драмы «Зеркало жизни», на которую съехались татарские зрители со всей Финляндии. Вместе пели, читали стихи, играли на фортепиано народные песни. В конце первого отделения с яркой речью выступил З. Кадыйри. Он говорил о большой и благородной роли театра, литературы в сохранении национальной культуры и традиций. «Зеркало жизни» – пьеса в 4 действиях, посвящённая народной жизни и обычаям, очень тронула общество финских тюрок. Период пребывания семьи Кадыйри в Финляндии был связан с двумя памятными датами. 20-летие со дня создания Национального Собрания, работавшего в Уфе в 1917 г., широко праздновалось в зарубежных странах: Китае, Японии, Турции, Финляндии, Эстонии. С особым торжеством юбилей прошел в Финляндии, на котором присутствовал Г. Исхаки. В центре празднования находились З. Кадыйри и С. Гыйффат, они подготовили массу разных мероприятий, посвящённых этой дате. Тогда и появилось стихотворение С. Гыйффат «Страна 20 лет назад». В нем в приподнятом духе она рассказывала о днях, когда была провозглашена республика «Идель-Урал». Г. Исхаки считал началом своей писательской деятельности 1897 г., поэтому 1937 год отмечался соотечественниками и как 40-летие его писательской деятельности. Это историческое событие широко освещалось мировой прессой. Вдохновителем его явилась С. Гыйффат: она написала стихи, содержательную статью «Воздух, которым дышит народ», готовила выступления, проводила детские вечера.

В Тампере была основана вторая община татар. Вскоре появились меньшие по численности общинные группы в Котке, Турку, Раума, Пори и в других городах. Основатели исламской общины в Тампере также перенесли традиции жизни мусульман Поволжья в Финляндию. В частности, в общине основам ислама и грамоте по новому – джадидистскому методу обучались не только мальчики, но и девочки так, как это повелось в Актукове еще с 1910 г. Учительница Рейхана Батиршах, обучавшая девочек, в свое время получила образование в медресе Буби (в России). Преподаватели давали широкие знания по мусульманскому циклу дисциплин. Изучался татарский язык, издавались учебники. Так, только в 30-е годы была издана Татарская азбука, уже упомянутые книги С. Гыйффат и З. Кадыйри, учебник «Уроки религии для тюркских детей», написанный в 1939 г. В.-А. Хакимом. Именно в Финляндии всегда издавалось наибольшее число татар-



*Юбилей Исхаки в Тампере, 1937 г.*

ской литературы (выпущено более 100 книг), а также периодические издания.

В конце 30-х годов отношения между двумя соседними странами обострились. На фоне надвигающейся большой войны в Европе, руководство СССР инициировало переговоры с финнами о переносе границы на Карельском перешейке на более безопасное расстояние от Ленинграда. Строго говоря, для такого рода опасений были основания: граница проходила в районе нынешнего города Сестрорецк, всего лишь в 32 км от второй столицы. Переговоры с разной степенью интенсивности шли в 1938-39 гг. В ноябре 1939 г. СССР «срежиссировал» инцидент обстрела своей территории финнами и начал боевые действия против Финляндии. Возможно, все пошло бы по сценарию, который был позднее применен в Прибалтике летом 1940 г. Но финны показали себя достойным противником.

Патриотизм был необычайно высок. Для молодой нации эта война стала отечественной, в том числе и для татар Финляндии, которые встали на защиту своей новой родины. Могилы погибших в той войне татар бережно сохраняются и сегодня.

В начале марта 1940 г. ценой значительных усилий советскими войсками был взят Выборг и тогда же подписан мирный договор. Финляндия потеряла значительные территории: весь Карельский перешеек, часть территорий на севере, но сохранила самое главное – независимость. Небезынтересен следующий факт: СССР получил новые территории фактически без населения – уникальный случай в современной истории. Более четырехсот тысяч финнов (10% тогдашнего населения) покинули свои дома в считанные часы, унеся только самое необходимое. Именно в эти посёлки устремились новые переселенцы, в том числе из Поволжья. По их воспоминаниям, уровень благосостояния и комфорта покинутых домов был невиданным для советских новосёлов…

## Будни татарской общины

В 1948 году в Хельсинки начала работать татарская начальная школа (Turk Halik Mektebi), финансирование которой осуществлялось на долевых началах за счет Исламской общины и городского муниципалитета. С пришедшей в 1969 году общеобразовательной реформой работа татарской школы оказалась невозможной, так как учеников было слишком мало для получения государственных субсидий. Сегодня во всех городах Финляндии, где живут татары, имеются воскресные татарские школы. В них дети членов общины изучают родной язык, узнают культуру и историю татарского народа. Еще в 50-х годах открылся и действует поныне татарский детский сад. В 70-х годах прошлого века финские татары были объединены в две организации – «Общество имени Г. Тукая», созданное профессором Хельсинкского университета Гумаром Дахером, и национально-религиозное общество финских татар «Исламия», руководителем которого являлся крупный торговец мехами и пушниной Осман Али. В настоящее время эти организации практически слились в одну. После смерти Гумара Дахера руководителем татарской диаспоры в Финляндии остался его сын Окан Дахер.

В свою очередь татарская молодежь создала собственную организацию – «FTB» («Fin tatar birligi»), основной задачей которой является решение культурологических проблем. С 1934 года у финских татар существует своя футбольная команда «Алтын Урда» («Золотая Орда»). После Второй мировой войны в Хельсинки было основано самостоятельное спортивное общество «Йолдыз», которое существует и поныне. Главная его гордость – футбольная команда, которую называют по имени клуба, на майках футболистов запечатлен полумесяц и звездочка. Многие из членов «Йолдыза» прославились на всю Европу, их приглашали в известные финские команды. Круглый год «Йолдыз» организует дни спорта. Еще одна ежегодная традиция – Сабантуй.

Пожалуй, одним из самых ярких представителей творческой интеллигенции финской диаспоры является Дениз Бадретдин – финский татарин в четвертом поколении, бизнесмен и музыкант. Музыкальную карьеру он начинал в 70-х годах в Хельсинки вместе с татарским рок-ансамблем «Башкарма». В 1992 году основал собственную группу – «Kazan Gruppasi Bedretdin» (сокращенно «KGB»), в репертуаре которой как традиционная татарская музыка, так и собственные сочинения. Стилистика музыки современная – в аранжировках заметно ощущается влияние рок и отчасти джазовой и блюзовой музыки. Некоторые наши соотечественники довольно остро отреагировали на некоторые его песни. Вот как это комментирует сам Дениз Бадретдин: «Я всего лишь говорю о том, что времена переменились, теперь у Татарстана суверенитет, но многие татары продолжают сидеть, жаловаться на судьбу и ждать какой-то манны небесной, как будто свобода, независимость, хорошая жизнь упадут им с неба или будут даны кем-то сверху». В этих словах заложен один из идеологических принципов финской общины татар. В начале прошлого века, добившись личного материального благополучия, влиятельные татары не стали просить помощи на дела общины у государства, а справлялись со своими проблемами самостоятельно. Этот принцип действует и сейчас.

О дисциплине и строгой регламентации действий в диаспоре можно судить хотя бы по такому факту: имя каждого члена махалли, в том числе каждого нового, его родных и близких четко зафиксировано. В диаспоре существует своя иерархия и структура: наиболее важные решения принимаются советом общины, текущие вопросы, в том числе социальные проблемы членов общины, выпуск новых книжных изданий и полиграфической продукции, проведение религиозных обрядовых дей-

ствий, спортивная деятельность и прочее решают специальные комиссии при махалле. Татарам Финляндии удалось утвердиться на влиятельных позициях в экономической и культурной жизни страны в качестве предпринимателей, врачей, юристов, инженеров, преподавателей. Они полностью интегрировались в финское общество, при этом сохранив свою подлинную идентичность.

Как же такой не очень большой по численности группе людей вдали от своей исторической родины удалось сохранить язык и культурные традиции, более того, сделать это блестяще? По словам Окана Дахера, в каждодневной будничной жизни важное место занимают культурные традиции, в которых объединяющей силой является религия. Преподавание основ Ислама, религиозные праздники, совместные богослужения и поминки составляют важную часть жизни общины, повышают самосознание молодежи, помогают осознать свою этническую идентичность. Один из определяющих факторов успешности финской диаспоры – автономность от государства. Если у меня есть финансовые возможности плюс сильное желание, зачем мне просить помощи от кого-то? Даже учитывая толерантнейшую политику Финляндии по отношению к представителям различных языковых групп и национальностей, финские татары предпочли материальную, а стало быть, организационную самостоятельность.

Развитие культуры невозможно без влияния извне и связующих мостов. В 60-х годах во времена хрущевской «оттепели» возобновилось общение финских татар с исторической родиной, тогда впервые в гости в общину были приглашены из России художники, певцы, танцоры, музыканты и ученые.

## Финские татары в 21 веке

Сегодня в Финляндии проживает около 800 татар, большая часть живет в Хельсинки. Бережное отношение ко всему, что связано с национальной историей, культурой, языком и обычаями, свойственное татарской диаспоре в Финляндии, проявляется и в активных научно-культурных связях с Татарстаном. Так, например, в свое время на сцене Татарского государственного академического театра им. Г. Камала с успехом прошел спектакль «Галиябану» в постановке молодежного самодеятельного театра из Хельсинки. Совместные творческие работы финских татар и наших соотечественников были показаны в Нью-Йорке и Сан-Франциско. Общество «Исламия» часто приглашает в гости татарстанских деятелей науки, культуры и искусства. Известный архитектор-дизайнер из Хельсинки Первин Имадитдин была приглашена к участию в реставрационных работах исторического центра Казани к 1000-летию столицы.

Татары Финляндии всегда уделяли огромное внимание семье. В деле сохранения родного языка главная роль принадлежит родителям, вместе с ними ответственность за воспитание ребенка разделяют бабушки с дедушками и прочие родственники. Несмотря на то, что в повседневной жизни татары Финляндии разговаривают, как правило, на финском языке, в семье общение всегда идет на татарском. При махалле (общине) существует своя учительская организация. Раз в неделю родители приводят маленьких детей в детский сад, где их учат сказкам, стихам и песням на татарском языке. Ребята школьного возраста регулярно посещают воскресные школы, где им преподают родной язык и основы ислама. После окончания занятий в школе дети едут на 2–3 недели в летний лагерь («Кемп»). Здесь школьники из Швеции, Германии, Турции, США, Канады, а в последнее время и из Татарстана изучают язык, культуру и историю татар. По окончании курсов проводится большой Сабантуй.

На собственные средства махалля выпускает книги, в том числе, сказки, стихи, учебники для детей, сборники песен для старших и др. Все тексты отпечатаны на основе латинской графики. Учебные пособия по татарскому языку – это, в основном, татарстанские издания, выпущенные в советское и постсоветское время. Кроме перевода учебного материала с кириллицы на латиницу, существует еще одна проблема – его адаптация к особенностям речи финских татар. Последние десять лет были налажены контакты с татарами по всему миру, этому, разумеется, в значительной степени поспособствовала и глобальная сеть. В конце 80-х годов студентка из финской диаспоры татар Айнур Низаметдин приезжала специально в Казань для того, чтобы углубленно изучить родной язык, тогда же она дала интервью одной из казанских газет: «Нам нужна помощь культурных организаций Татарии, нужна коротковолновая радиостанция, вещающая на татарском языке из Казани». Спустя 15 лет ее слова звучат не совсем актуально.

Рассказывает татарская певица из Финляндии Джамиля Низаметдин: «Когда я услышала «TATAR RADIOSI» в режиме онлайн в Интернете, я послала около 350 ссылок на этот сайт всем своим знакомым татарам по всему миру. В этот день несколько часов дежурила у компьютера, слушая незнакомые и вместе с тем такие родные мелодии».

Иногда татарская община пополняется новыми членами, обязательное условие – свободное владение татарским языком. Отношение к смешанным бракам и детям от смешанных браков достаточно суровое, об этом, кстати, сами представители финской диаспоры рассказывают неохотно. Тем не менее, если член общины женится или выходит замуж за представителя другой национальности, вход на все собрания махалли будет разрешен лишь одному человеку – члену общины. Детей от смешанных браков не принимают в детские сады, воскресные школы и летние лагеря. Тем самым члены диаспоры хотят сохранить свой язык и культуру. Условия крайне

жесткие, но и так же крайне необходимые, считают они. В последнее время появилась новая тенденция – специальные вечера для смешанных семей, где гостей знакомят с особенностями татарской культуры, традициями и обычаями. Быть может, этот своеобразный мостик сумеет как-то сгладить возникшие противоречия.

В целом стоит отметить высокую степень образованности членов татарской общины – приблизительно в два раза выше, чем у среднего жителя Финляндии. По результатам проведенного интернет-анкетирования, среднестатистический член общины знает 4–5 языков. Как правило, это финский, шведский, татарский, турецкий, английский и другие языки. Среднестатистический представитель махалли приходит на встречи общины дважды в месяц. Главная цель, так называемых, «Чай Кичине», то есть чаепитий – душевное общение и обмен мнениями. Самодеятельные ансамбли песен и танцев, небольшая театральная труппа готовят культурные программы с чтением стихов, шуточными сценками, выступлением профессиональных и непрофессиональных исполнителей.

Политические перемены в России в последнее десятилетие XX в. активизировали контакты российских и финляндских мусульман. В Тампере побывали Талгат Таджутдин, Равиль Гайнутдин, имамы из Казани, Москвы и Нижнего Новгорода, а также имамы из нижегородских татарских деревень. Были и ответные визиты, в частности, в Нижний Новгород в 1991 г. и в татарские деревни юго-востока Нижегородской области, на родину предков. В путешествии по Нижегородчине финляндскую делегацию сопровождал Умар Идрисов, руководитель нижегородской мусульманской общины.

Совсем недавно, в декабре – январе 2014 г. по телеканалу «Татарстан – новый век» прошла серия сюжетов о финских татарах, в которых участвовал новый председатель общества Атик Али, человек молодой, ответственный и образованный.




Сейчас имамом в Хельсинкской общине является Рамиль Беляев, выпускник Московского исламского университета, который одновременно занимается в докторантуре Хельсинского университета на отделении мировых культур факультета гуманитарных наук. Он рассказал, что до 1991 г. в Финляндии мусульман представляли только татары, сейчас же в страну активно заселяются беженцы из различных исламских стран, в связи с чем был создан Мусульманский совет Финляндии. В одном из интервью Р. Беляев поднял вопрос о получении мусульманского образования для жителей Финляндии, исповедующих ислам: «Мусульмане Финляндии делают попытку создать учебный стандарт по подготовке собственных священнослужителей. Для этого при поддержке МИД Финляндии, Министерства образования и Хельсинкского университета была создана рабочая группа, которая изучила опыт стран Европы в этом вопросе. Я уверен, что опыт наших российских коллег и стран СНГ будет востребован… Но нельзя забывать и про процесс ассимиляции.

У татар Финляндии тоже появилась своя культура, которая представляет собой особый менталитет. Они являются патриотами своей страны, европейцами, которые бережно относятся к священной религии предков – исламу, родному языку, национальной культуре. В европейском обществе происходят масштабные изменения. В свете миграционных потоков из стран Азии и Африки национальный состав европейских городов меняется в пользу мигрантов. Политики Европы говорят о провале идеи мультикультурализма, утверждая, что столкновений на этой почве не избежать. В этой мрачной картине татары Финляндии на протяжении полутора веков выступают позитивным интеграционным примером, сумев на своём опыте показать, что идея гармоничного сосуществования разных этносов вполне реалистична».

В Финляндии, так же как в Турции, имеется представительство Татарстана по торгово-экономическим связям, потому делегации бывают довольно часто, что помогает налаживать взаимовыгодное сотрудничество. Кстати, в Турции, в Стамбуле в 2011 году мне довелось принять участие в памятном вечере, посвящённом 100-летию со дня рождения профессора Хельсинкского университета Гумара Дахера, немало сил отдавшего сплочению финских татар. На этот вечер собралась татарская молодёжь, проживающая в Турции. Вёл презентацию идейный руководитель турецкой общины татар, историк Надир Давлет. С огромным уважением он рассказывал о заслугах Г. Дахера, о финской татарской общине, а в конце встречи справедливо отметил, что современные татары Финляндии являются наиболее сплоченной, активной и самодостаточной диаспорой во всём татарском мире.

*Примечание автора:* При подготовке статьи были использованы материалы Интернет-сайтов.

***Самар шәһәрендәге бердәнбер «Яктылык» татар мәктәбенең чишмә башында кемнәр булган, дип сорасагыз, Асия Госман кызы Сәйфетдинованың исемен Хәридә Габделҗан кызы Дашкинадан соң ук атап бирерләр иде. Алар бит 80нче елларда 12нче кичке мәктәптә дә бергә укытканнар, бергәләп якшәмбе татар мәктәбен дә башлап җибәргәннәр, аннары аны тулы хокуклы мәктәп ясап, татар дөньясына танытуга зур көч куйганнар.***

*Эльмира ШӘВӘЛИЕВА*



# Тәрбия дәвамлы булырга тиеш

Аның белән мин дә инде егерме еллар чамасы таныш. Асия Госман кызы «Яктылык» балаларын Польшага алып киткән, музей ачкан, күргәзмә, хәйрия ярминкәләре уздырган, «Малыш» балалар йортына, мәктәптә укучы ятим балаларга ярдәм оештырган... кебек «Яктылык»тагы яңалыкларны ишетеп, «Бердәмлек» газетасына язып торганда күп аралашырга туры килде безгә, һәм бу аралашу күңелдә гел уңай тәэсирләр генә калдыра иде.

Ләкин елмаючан, тыйнак, башыннан яулыгы төшми торган бу хатын сүзенең үтемлелеге шаһиты да булырга туры килгән иде миңа. Берничә еллар элек ата-аналар һәм бер укытучы арасында аңлашылмаучанлык килеп чыккач, Асия Госман кызының катнашы белән бер атна чамасы дәвам иткән низаг өч минут дигәндә юкка чыкты да куйды. Нинди сүзләр таба алды ул? Белмим. Гади, әмма бик дөрес сүзләр иде ул.

Ә бүген Асия Госман кызы белән без тәрбия темаларына иркенләп сөйләшеп утырабыз әле менә. Татар авылларында балаларны тәрбияләү темасына кереп киткәч, ул үзе үскән гаиләне мисал итеп китерде. Минем карашка, бик гыйбрәтле хикәя булырлык теманы күтәрде ул.

Асия Челно-Вершины районының Хөсәен авылында 1955 елда туган. Руслар бу авылны Благодаровка дип атасалар, татарлар аны бергә килеп төпләнгән һәм мәчет салып исемен мәңгеләштергән Хөсәен авылы, дип йөртәләр. Өч урамлы бу авылның бер башында күбрәк руслар яшәсә, икенче очында татарлар төпләнгән. Арада мордва да, чуваш халкы да булган, әлбәттә.

Авыл күпмилләтле булуына карамастан, башлангыч мәктәптә татар балалары аерым программа буенча ана телендә белем алганнар. Ә бишенче сыйныфка Сиделькино мукшы авылына укырга килгәч, кыенрак булган, билгеле. «Тапкырлау таблицасын русча әйтә башлаган идем, үзем дә сизмәстән татарчага күчеп киткәнмен. Мине беркем дә туктатмады, «Молодец, Камалетдинова!» - дип, «бишле» куеп утырттылар. Аннары гына татарча җавап биргәнлегемне аңладым», – дип көлеп искә ала Асия ханым беренче имтиханын.

Алар гаиләдә башта өч бала үскәннәр – Гөмәр, Фәүзия һәм иң кечкенәләре Асия. Алты почмаклы өйдә унлап кеше - эчке бүлмәдә хатыны һәм ике малае белән Ильяс абыйлары яшәсә, алгы бүлмәдә алар – этиләре Госман, әниләре Зәйтүнә, өч бала һәм аларның яраткан «якын әби»ләре.

Өйдә демографик мохит тыгыз булуына карамастан, бер генә тавыш-тын да чыкмый. Олыларны олылап, кечеләрне кече дип белеп, тату гына яшәп яталар Камалетдиновлар. Гаиләдәге тәртип иң олы кешенең, «якын әби»нең җитәкчелегендә бара. «Урамга чыккач, Ильяс абыең хатыны белән ничек яши дип сорасалар, «Бар да яхшы!» - дип җавап бирегез. Белмәгәннең башы авыртмый», –

дип әйтеп торган әбиләре. Шулай ул аларны күп сөйләмәскә, өйдәге чүпне урамга чыгармаска өйрәткән бит инде.

Икенче мисал: Асия мәктәптән кайткач, әбисенә зарлана икән: «Нәхәр апа, сөйләшеп утырган өчен, чәчемнән тартты!» Әбисе шундук кызның чәченнән эләктереп ала да, маңгаен шак иттереп өстәлгә бәрә: «Тагын бер тапкыр укытучың турында начар сүз ишетсәм, бер бөртек чәчеңне дә калдырмыйм!» Бусы да мөселман гаиләләренә хас тәрбия – үзеңнән олы кешене хөрмәт ит, аның турында начар сөйләмә.

Өч километр ераклыктагы мукшы авылында укый башлагач, татар кызлары иртән киеп чыккан оекларын, яулыкларын ферма артына качып салып җибәрәләр, ә авылга кергәндә яңадан кияләр икән. Ә яулык мәктәптә онытылып калган булса, урам буйлап яланбаш йөрү килешми дип, өйгә бакчалар аша гына кайтырга туры килә. Ә шулай да күрүчеләр табыла һәм әтисе эштән кайтканда барысын да белгән була инде: «Нишләп башыңкүзең тондырып яулыксыз йөрисең әле, кыз! Башкача алай итәсе булма!» – дип шелтәли Госман абзый. Сүз җиткерүчеләргә ул вакытта үпкәсе зур булса да, хәзер Асия бик яхшы аңлый, бу бит халык тәрбиясе булган. Балаларны бөтен авыл тәрбияләгән ич! Хәзерге балалар, кисәтү ясасаң: «Кем соң әле син мине өйрәтеп торырга!» – дип җибәрергә дә кыенсынмыйлар. Ә ул вакытларда: «Ай Аллам, Шакир бабай, Ибраһим бабай ни дип әйтер», – дип шикләнгәннәр. «Башыма яулык бәйләмичә чыксам, тәнем ояла иде, күземне күтәрә алмыйча, кача-кача бара идем», – дип исенә төшерә Асия ханым.

Бу гаиләнең салмак тормышы 1966 елда челпәрәмә килә. 38 яшьлек әнисен инсульт суккач, ул ике ай гына ята да, вафат була. Әнисе авыргач, ике кодагый эшне бүлешәләр – әнисенең әнисе – «ерак әби» – кызын карый, «якын әби» балаларны үз өстенә ала. Ә җиңгиләре зур керләрне, тәрәзә пәрдәләрен юып китереп, элеп үк китә. Авыр хәлгә калган гаиләгә ярдәм итү тәрбия түгелмени?

Ә әниләрен җирләп, кырык көн узгач, олырак туганнары җыелып: «Әниең картайган инде, 82нче яше белән бара. Балаларыңа да күз-колак кирәк. Әнә, Якты Күл авылында Фатыйма исемле бер дә кияүгә чыкмаган ялгыз хатын яши икән. Ул синең балаларыңа яхшы әни булырлык кеше», – дигәч, Госман каршы килми, авылда хатынсыз яшәве бик кыен бит, үзе дә аңлый.





Шулай берсен-берсе күрмәгән ике ялгызга никах укыталар. Бәхеткә, Фатыйма әни, чыннан да, бик яхшы кеше булып чыга. Яңа килен төшкәч тә, гаиләдә яхшы мөнәсәбәтләр һәм тынычлык хөкем сөрә.

Асия ханым гаилә тормышындагы ата роленә дә зур бәя бирә. «Гомере буе Сиделькино мәктәбендә шофер булып эшләгән әтиебезнең дүрт сыйныф белеме дә юк иде. Шулай да мин аны интеллигент кеше дип атарга курыкмыйм, – дип сөйли кызы. – Ул беркайчан да тавыш күтәрмәде. Эштән кайткач, аш әле әзер булмаса, чәйнек авызыннан салкын чәй эчә иде дә, безнең белән бергә йорт эшләрен эшләргә керешә иде. Эш беткәч, бергәләп ашавы бигрәк тә күңелле була иде».

Госман ага бөтен эштән дә бәйрәм ясый белгән. Җәй буе ярып киптергән утынны сарайга таշуы, кәбестә тозлавы, пилмән ясавы, бәрәңге алуы, сатуга дип унбиш сотый чәчелгән суганны кисү булсынмы - Фатыйма әни аш бүлмәсендә бәрәңге бәлеше, таба ашлары пешерә. Эш тәмамланугa бөтен балалар да (тора-бара тагын ике бала – Әлмирә һәм Әнвәр туалар), олылар да өстәл тирәсенә җыелышып, көлешә–көлешә чәй эчәләр. Бәлки, эш авыр да булгандыр, ләкин ата белән ана ул эшне яхшы мөнәсәбәт, балаларны үсендерүче яхшы сүзләр белән җиңеләйтә белгәннәр, мәҗбүриләп эшләтеп, күңелләрен кайтармаганнар.

Госман ага - Бөек Ватан сугышында катнашкан кеше. Ул Курск дугасы янында каты яраланып, госпитальләрдә дәваланганнан соң, хозчастьтә хезмәт иткән. Тик беркайчан да сугыш афәтләре турында сөйләргә яратмаган. Балалары күңеленә шом салырга теләмәгәндер инде.

Хозчастьтә Госман тегәргә дә өйрәнгән. Гаилә тормышы белән яши башлагач аның бу осталыгы бик кирәк булып чыга – иске шәлләрдән балаларга бияләйләр тегеп бирү,



*1 сентябрь 2005 ел.*
*Яшь коллегалар белән*

бишмәтләрне әйләндереп яңарту, бәрән тиресеннән яңа яка ясап кую бер һөнәре булса, авылдагы бөтен ватык сәгатьләрне, кер юу, тегү машиналарын, радиоалгычларны ремонтлау, бөтен туганнарына агачтан киштә, сандык, өстәл–урындыклар ясау иkenче мавыгуы булган. «Никүпме яшәде эткәй, шул гомер изгелек эшләде», – дип сөртте Асия ирексездән бөреләнгән күз яшьләрен.

Шундый дус һәм зур гаилә әгъзалары еллар һәм кыенлыклар аша үтеп, туганлык хисләрен ныгыталар гына. Алар әле дә очрашып, бер-берсенә ярдәм итешеп яшиләр. Кызганычка, Госман абый гына егерме ел чамасы элек вафат булды. Фатыйма апа да, балалары да аны әле дә сагынып, юксынып искә алалар.



Асия Сиделькино авылы укытучыларын да бик җылы сүзләр белән искә ала. Интернатта кунарга туры килгәндә мәктәп директоры Борис Иванович һәм аның хатыны тетя Лида ятим баланың хәлен белергә кереп йөриләр. Аз гына кәефе начаррак булуын күрсәләр дә, үзләренә алып кайталар һәм Асиядән күпкә олырак кызларына аның белән шашка уйнарга кушалар. Кызлары киреләнсә, читкәрәк алып китеп, нәрсәдер әйтәләр һәм Люся бөтен эшен ташлап, кич буе кунакның күңелен күрә. «Сиделькинода ул вакытта укыткан бөтен укытучыларны әле дә бик яратам», – дип искә ала укытучы.

Сыйныф җитәкчесе Петр Иванович Рассказов балада педагог таланты булуын беренче булып күреп ала. Кыз табиб булырга хыялланса да, «Ты должна оправдать мое доверие, должна стать хорошим учителем, это благодарный труд», – дип торган кешегә каршы килеп булмый инде. Кыз мәктәпне тәмамлагач, Куйбышевның педагогия институтына укырга бара, ләкин авылда чит ил телләре укытылмаганлыктан, керә алмыйча, авылга кайта.

Бу вакытта Яңа Эштебенькино авылында директорлык итә башлаган Сиделькино мәктәбенең элеккеге директоры Алексей Евдокимович Яковлев кызның кайгысына бик шатланган булса кирәк. Химия һәм биология укытучысы булмаганга күрә, ул аны пионервожатый итеп эшкә ала һәм берничә дәрес химия һәм биология укытуны да йөкли. Ләкин песи баласын суга ташлаган кебек ташламый ул аны, ә һәр көнне Асия белән бергә дәресләргә әзерләнә, еш кына үзе, йә завучларының берсе дәресләрендә утырып, кызның эшен тикшерәләр. Ә инде яшь укытучы авыл тормышыннан мисаллар китереп, балаларга дәрес аңлата башлагач, директор: «Все, Асенька, теперь я спокоен, ты будешь хорошим учителем!» – дип, үз карамагыннан азат итә.

Асия бу вакытта пединститутның химия һәм биология факультетында читтән торып укый була инде. Ә берничә ел эшләгәннән соң, Яңа Тормыш авылы егете Нәҗипкә кияүгә чыга һәм кайнап торган авыл тормышын калдырып, Самарга китә. Ул шәһәр тор-



мышын башта бик күңелсез, дип таба...

Үткән гасырның сиксәненче еллары уртасы була бу. Ире Нәҗип Сәйфетдиновның Камышлы егете Рәшит Сәлахов һәм самаралы Шамил Дашкин белән Мәскәүнең сәүдә институтында укып йөри торган чаклары. Әлбәттә, аларның хатыннары да үзара йөрешә башлыйлар һәм Хәридә апа моңа кадәр балалар бакчасында эшләгән Асияне үзенең кечке мәктәбенә лаборантка итеп димли. Менә шулай Асия Госмановнага «Яктылык» мәктәбенә таба юл ачыла да инде.

– Хәридә Габделҗановна белән эшләве җиңел дә, шул ук вакытта авыр да булды. Ул, элеккеге укытучыларым кебек үк, артымда ныклы тыл булып торды. Бөтен эшне аңлатып, кайдан алып, кайда куярга

икәнен әйтеп бирә, аннары эшеңне тикшерә дә әле. Ул, минем кебек үк, авыл кызы булуына карамастан, татар мәктәбен ачканда мәгариф министрлыгы, татар зыялылары, хөкүмәт органнары белән ничек кыю эшләде! Исем китә иде. Беркайчан да мин аңардан «белмим» сүзен ишетмәдем. Белмәсә дә, каян белергә икәнен әйтеп бирә иде.

«Яктылык» мәктәбе өчен бирелгән ташландык балалар

1997 елдан, «Яктылык» мәктәбе ремонтланган шушы бинага күчкәннән бирле, Асия Госман кызы тәрбия эшләре буенча бүлек мөдире булarak хезмәт куйды. Улы Йосыф та шушы татар мәктәбен тәмамлап, төзү һәм архитектура институтына укырга керә. Әнисе укыткан акыллы, сабыр һәм ыспай Юлиягә өйләнеп, әбисенә өч онык бүләк итәләр. Йосыф укуын һаман дәвам итә әле һәм медицинада да,

ды, музее күз явын алырлык һәм көнннән-көн экспонатларга байый бара, ә балаларның вокал төркеме сандугачларны да уздырырлык итеп җырлый башлады. Шушы уңышлары өчен Асия Госман кызы, беренче чиратта, таләпчән һәм булдыклы Хәридә Дашкинага, җайлы һәм сабыр Дания Мидхәтовнага, тәртип яратучы Радик Рифкатовичка, бәйрәмнәрне матур һәм эчтәлекле итә белүче музыка



бакчасы бинасын амброзия басып киткән иде. Без аның янында озак аптырап йөргәнебезне хәтерлим. Ничек бу эшне башлап, ничек ерып чыгарга? Ләкин Хәридә Дашкина башлаган эштән куркып чигенә торганнардан түгел. Ул бит әле «мөмкин түгел» сүзен дә белми, үзенә ияргән кешеләрдән дә шуны ук таләп итә. Ул барысын да чәйнәп, авызга каптыра, ә инде булдыра алуыңны күргәч, күләгәгә чигенә. Хәридә апада ниндидер серле сеңер бар сыман. Мин шундый кеше белән эшләвемә чиксез горурланам.

төзелеш эшләрендә дә кулланыш тапкан «Үсә торган матдәләр» темасы өстендә фәнни тикшеренүләр алып бара.

Асия Госман кызы мәктәпкә килеп кергәч, кабинетына тиз генә барып җитә алмый. Һәрберсе белән сөйләшеп, үткән көнне катырак әйтелгән сүзләре өчен берсеннән гафу үтенеп, икенчесен, кирисенчә, орышып, өченчесе белән булачак чара турында фикер алыша-алыша байтак вакыты уза.

Ул үзенең эшен яратып, тәм табып эшли. Ул башлаган «Йолдыз» бию театры бөтен дөньяга таныл-

һәм хореография белгечләренә рәхмәтләр укый.

Гомумән, ул беркайчан да кабинет хезмәткәре була белмәде. Балалар кая - ул шунда. Асия Госмановна да үзенең укытучыларының, әбисе, ата-анасы сеңдергән тәрбияне кулланып, укучыларына ныклы тыл, укытучыларга – ышанычлы хезмәттәш һәм татар җәмгыятенә – зыялы укытучы була белде. Ә хәзер ул белгәннәрен үзе урынына килгән яшь укытучы Рәхимә Илдусовнага тапшыра. Тәрбия эшенең дәвамлы булырга тиеш икәнен ул бик яхшы белә бит.

# ТОРМЫШ ТАВЫ БИЕК



*Ир кеше үз гомерендә өй салырга, агач утыртырга, нәсел җебен дәвам итәрлек ир бала үстерергә тиеш, диләр. Гомәр абый Шәкүров үз гомерендә бу бурычларның барысын да үтәгән. Хәтта арттырып та. Ник дисәгез, аның ике улы Самар төбәгендә танылган акыл ияләре, төрле өлкәләрдәге профессорлар - Илдар һәм Ильяс Шәкүровлар, ә кызлары Равилә Революционный урамындагы йөз хезмәткәре булган "Кулинария" кибете җитәкчесе. Шушы игелекле балаларның әниләре Галия апа белән әтиләре Гомәр ага да кадер-хөрмәттә, бер ел элек кенә ремонт ясалган өч бүлмәле киң, якты һәм уңай фатирда яшәп яталар.*

*Эльмира ШӘВӘЛИЕВА*

**Гомәр**

Яшь чагында Гомәр Шәкүровның тормышына кызыгучылар булмагандыр, дип уйлыйм. Чөнки язмыш бит ул кешене сынар өчен бәрә, кага, суга, ялгыш юлдан җибәреп карый. Ә инде сынмый-сыгылмый калганнарны тормыш ахырында бәхет-сәгадәт белән бүләкли. Менә Гомәр агага да беренче чиратта үзен, күңеленә ошаган эшен табу өчен күп нужа күрергә туры килә.

Аның әти-әнисе егерменче гасыр башында Ульян өлкәсенең Моисеевка авылыннан Елховка районының Алмалы авылына җир алырга килгәннәр. Шунда аларның малайлары Гомәр туган да инде. Ул туганда әтисе дә, әнисе дә олы яшькә чыкканнар иде. Закир ага, салкын тидереп, нык интегә һәм 1957 елда вафат була. Әнисе Гөлфрүз апа да озак яши алмый, Закиры вафатыннан соң, бер ел дә үтми, бакыйлыкка күчә. Зәгыйфь туган ике бертуган апалары дә бер-бер артлы дөнья куялар.

Гомәр бигрәк тә итәгендә җан биргән Бибизәне гомере буе сагына. Балачагыннан яналифны да, латин графикасын да яхшы белгән апасы аңа да, башка авылдашларына да Коръән укучы, хәреф өйрәтүче буларак танылган иде бит.

Башлангыч сыйныфларда малайны "бик яхшы" билгеләренә укыганы өчен икенче сыйныфтан турыга дүртенче сыйныфка күчерергә телиләр. Ләкин әтисе-әнисе моңа каршы килә, һәм Гомәр укуын сабакташлары белән бергә дәвам итә. Бу вакытта сугыш башланган була инде. Бишенче сыйныфтан башлап, Тупли мәктәбендә укыган балага бер көн барып, ике көнен калдырып, белем алырга туры килсә дә, ул алдынгылар исәбендә була. Сугыш тәмамлангач, Мәләкәс педу-









чилищесына укырга керергә дә кыен булмый Гомәргә.

Яхшы укучыга армиядән кайткан Рухулла Миникаевка ярдәм итү вазифасын йөклиләр. Шәкүров подшефные белән көн саен очрашып, дәрес әзерләргә булыша. Шулай алар дүрт ел буе бергә йөриләр, дуслашып бетәләр. Гомәр абый әле дә чыгарылыш имтиханнарында Рухуллага диктант язарга ярдәм итә алмавына кыенсына. Шулай итеп, Гомәр педучилищены тәмамлау турында диплом алып чыга, ә Рухулла дипломсыз да Ульян өлкәсе мәктәпләренең берсендә уңышлы гына эшләп китә.

## Галия

Бу вакытта Гомәрнең булачак хатыны, Ульян өлкәсенең Карсун районы, Татар Горенкасы авылында туып-үскән Галия, Камышлы педагогия училищесында укый. Сугыштан соңгы авыр еллар, училищеның базасы да, читтән килеп укучы яшүсмерләргә тулай торагы та булмаган чаклар. Студентларны Иске мәчеткә урнаштыралар. Галия Әләветдин кызы бу елларны болай тасвирлый: «Шушы зур мәчеттә бер генә түгәрәк мич бар иде. Без анда яшәгәндә айлар буе мунча кермәгән чаклар да булды. Ашарга 500 грамм чи арыш ипие бирәләр, ә йокларга идәнгә тезелешеп ятабыз. Уку елы колхоз эшеннән башлана иде. 10-12 километр ераклыктагы кырларда ишелеп уңган киндер йолкабыз, зур-зур көнбагышларны кисеп, капчыкларга тутырабыз. Ачлыктан бер-ике көнбагыш башын каккалап, фуфайка эченә тегеп куйган кесәләргә тутырып, курка-курка алып кайтабыз да, кичен шуның белән тамак ялгап, салкын идәнгә ятып йоклыйбыз.

Ике ел шулай интектек. Укытучыларыбыз Хәмзә абый белән Гафифә апаның урыннары оҗмахта булсын инде, алар безгә өченче курста укыганда мунча салдырдылар. Шунда юынып, эчке күлмәкләребезне юып, киптерергә мөмкин булды.

Ә инде соңгы курста укыганда хәтта конфет та ашый башладык. Шушы ике изге җан кибеткә кайткан пластилин кебек конфет, повидло сатып алып, безгә өләшәләр иде. Без шуларны да ашамыйча, аниләргә күчтәнәчкә алып кайтырга тырыштык...»

Камышлы педучилищесын тәмамлаган кызны Елховка районындагы Тупли мәктәбенә татар теле укытырга җибәрәләр. Галия бу юлламага чиксез шатлана, чөнки иптәшләренә андый бәхет тә елмаймый әле, күбесе Төркмәнстан, Үзбәкстан республикаларының кышлакларына укытырга китеп баралар.

## Уртак тормыш

Галиянең бәхете дә шушыннан икән. Армиядә танк командиры булып хезмәт иткән, аннан кайткач, Алмалыда математика укыта башлаган Гомәрне нәкъ шул вакытта Туплига күчерәләр. Егетнең күзе яңа укытучыга төшә һәм алар, бераз очрашып йөргәннән соң, уртак тормыш корып җибәрәләр.

Беренче малайлары Илдар 1956 елда дөньяга килә. Бу вакытта Галия Казан педагогия институтында, ә Гомәр авыл хуҗалыгы институтында укыйлар. Яшьләргә тормышны башлап җибәргә бик авыр була. Чөнки Гомәрнең әтисенең вафат булган, ә әнисенең каты авырый торган чагына туры килә. Галия каенаны да сабыен да карый, хуҗалыкны да алып бара, укырга да, эшләргә дә өлгерә. Тик менә сессияләргә барганда баланы калдырырга гына кеше булмый. Икенче сессиясен Галия апа аеруча яхшы хәтерли: «Улымны Казанга алып барырга туры килде. Аны карарга дип апамны да иярттем. Базарга чыгып җиләк алган идек, Илдар аны ашап дизентерия белән авырды. Шулай итеп, сессиянең кызган чагында хастаханәгә эләктек. Өч-дүрт көн дә узмагандыр, баланың хәле яхшырды һәм мин, авыру өчен үзем җавап бирәм дип кул куеп, хастаханәдән чыктым һәм имтиханнарымны бирдем. Менә шулай укыдык без. Ләкин укуны ташлау турында сүз дә булмады».

Ул вакытта студентларга түләнгән стипендиягә үзеңне дә, гаиләңне дә асрарга мөмкин булган. Куйбышевның авыл хуҗалыгы институтының көндезге бүлегендә укучы Гомәр Алмалыдагы өен Туплига күчереп сала, аңа янкорма өсти, сыер ала. Чөнки аның хатыны балаларына тик яңа сауган


Шәкүровлар гаиләсе


Галия апа онысы Наилә белән


Туган йорт каршында

сөт кенә эчерергә теләве турында белдерә. «Сыерыбыз бик сөтле иде. Иртән сыерны савып керәм дә, йокыдан да уянып җитмәгән балаларыма эчерәм.

Әллә инде, чынлап та, яңа сауган сөт эчеп үскән балалар башлы була дигән сүз дөресме икән? Әнә бит, ике улым да профессор булдылар!»

Институтны тәмамлагач, Гомәр Кошки районы колхозларында механик булып эшли башлый. Аннары үз авылында механизаторлар өчен курслар ачып җибәрә. Шуннан аны Кошки районының Надеждино авылындагы СПТУга эшкә алалар, аннары Кошкидагы ДОСААФка...

Ә гаилә бу вакытта ишәя тора. 1965 елда улы Ильяс, 70нче елда Равилә туа. Гомәр ага Кошкида да зур өй сала, чөнки кайчан да булса гаиләсен шунда алып килеп яшәргә хыяллана. Ләкин Туплида татар телен укыткан Галия, башка җирдә үзенә эш булмас дип, Туплидан китәргә теләми. Шулай итеп, Гомәргә ял көннәрендә генә гаиләсе янына кайтып йөрергә кала.

Галия бөтен гомерен балаларга багышлый. Класстан тыш эшләр, җыелышлар, бәйрәмнәр, чыгарылыш кичәләре һәм яңа уку еллары арасында ярты гомере үткән дә киткән. Менә үзенең балалары да үсеп җиткәннәр инде.

«Минем балалар бик мөстәкыйль иделәр. Ярты көннәре мәктәптә уза. Кайтып, капкалап алалар да, малларны карыйлар, су ташып куялар. Ә Равилә өйләрне ялт иттереп җыештыра. Аннары йә чаңгы шуарга, йә класстан тыш эшләр белән шөгыльләнергә китеп баралар. Кичен барыбыз да өйдә җыелып, бер өстәл тирәсенә тезелешеп утырабыз. Балалар дәрес карый, ә мин өем-өем дәфтәрләр тикшерәм, иртәгәгә планнар язам. Ә вакыт калса шашка, шахмат уйныйбыз»...

## Илдар

Илдар ундүрт яшендә Куйбышевның приборлар ясый торган техникумына укырга китә. Ә тәмамлагач, 1974 елда, иketуган абыйсы Шамил Сатдаров эзләре буенча медицина институтына укырга керә. Авыл малаена әнисеннән акча сорамас өчен яхшы укырга да, коймалар буярга да, вагоннар бушатырга да, базарда эшләргә дә, сарайлар салырга да туры килгән. Ә инде дерматовенеролог һөнәренә ия булгач, яраткан эшенә ябыша. Баштa табиб, аннары бүлек мөдире булып эшләгән егет 1986 елда Самар өлкә дерматовенерология диспансеры җитәкчесе булып китә. Илдар Гомәр улы фән белән мавыгып, туксанынчы еллар ахырында кандидат диссертациясен, ә 2003 елда медицина фәннәре докторы исемен яклый.

## Ильяс

Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган Ильяс Шәкүров Куйбышев дәүләт университетының кичке бүлегенә укырга керә. Шуннан аны армиягә алалар. Мәктәпнең комсомол комитеты әгъзасы булarak, күп эшләгән егетне тиздән рота комсоргы итеп сайлап куялар. Ә демобилизациядән соң армиядә туплаган лидер сыйфатлары аңа комсомолның район комитетында инструктор булып эшләргә мөмкинлек бирә.

Университетны тәмамлап, юридик фәннәр белгечлеген алып чыккан Ильяс Шәкүров сиксәненче еллар ахырында шәһәр комсомол комитеты каршындагы «Яшьләр инициативасы фонды»нда җитәкче урынбасары булып эшли башлый. Аннан китә инде - «Яшьләр үзәге» директоры, кыйммәтле кәгазьләр белән эш итә торган фирма директоры һәм оештыручысы, «Волжский универсальный банк»та правление рәисе урынбасары...

Үзгәртеп кору елларында аңа банкротка әверелеп баручы Фермербанк белән җитәкчелек итүне тәкъдим иткәч, ул үзен сынап карарга теле. Булдыра алмас, Фермербанк шартлар, дип торучылар бик ялгышалар. Әкренләп, җитәкченең үлчәп атлаган адымнары нәтиҗәсендә, банк яхшы гына эшләп китә, һәм бераздан ул Ипозембанк булып теркәлә. Шушы чорда Ильяс әфәнде экономика фәннәре буенча кандидат диссертациясе өстендә эшли башлый, ә аны уңышлы яклагач, ярты юлда туктап калмый, докторлык диссертациясен дә язып, экономика фәннәре докторы исеменә лаек була. Шулай итеп, Ильяс Гомәр улы студентларга экономика фәннәре буенча лекцияләр укый башлый һәм практика белән теорияне параллель рәвештә алып бара.



*Алтын туй*



*Ильяс улларында кунакта*



*«Баламның баласы балдан татлы»*

«Профессор булып тумыйлар, әлбәттә. Моның өчен бик күп укырга, бик күп тырышырга, энә белән кое казырга кирәк. Әти белән әни, безнең ерак бабаларыбыз биргән геннар да ничектер уңышлы урнашканнар күрәсең. Өчебездә дә укуга, яңа белемгә омтылыш зур. Без бик күп эшлибез, һәм моның нәтиҗәсе көттерми», - дип, Ильяс Гомәр улы бөтен кешегә дә билгеле сүзләрне әйтте. Тик менә татарлар арасында, Шәкүровлар кебек, бертуктаусыз укуга, белемгә омтылучылар бик күп түгел шул әле.

Милли җанлы Ильяс әфәнде татар тормышын ярып керде, дисәм дә ялгышмам. Башта «Яктылык» мәктәбенең попечительләр советы рәисе генә булып торган бу кеше ике ел элек өлкә «Туган тел» оешмасын җитәкләде. Шушы вакыт эчендә аның командасы күзгә күренерлек нәтиҗәләргә ирешә. Бу турыда «Бердәмлек» газетасы бертуктаусыз язып тора һәм аның укучылары Ильяс әфәнденең татар тормышына керткән өлешен күреп, бәяләп өлгергәннәрдер, дип уйлыйм.

Ә Равилә Мәскәүнең сәүдә институтын тәмамлап, гаилә бизнесы булып саналган «Кулинария» кибете белән уңышлы гына җитәкчелек итә. Бу Илдарга һәм Ильяска фән белән дә, җәмәгать эшләре белән дә иркенләп шөгыльләнергә мөмкинлек бирә.

### Бәхетле картлык

Гомәр абый, балалары Самарда укып чыгып, үзләре сайлап алган юл белән киткәч, Кошкидагы өен сатып, яңасын алып, аны да төзекләндереп, тагын сатып, акча эшли һәм Самардан йорт ала. Шулай алар олы яшьләренә җиткәч, балалары янына килеп урнашалар.

Авылдашлары бу гаиләне әле дә ятатып искә ала. Бигрәк тә Галия апаның Самарда яшәүче укучылары Коръән мәҗлесе уткәрсәләр дә, бәйрәм-фәлән булса да, беренче кунак итеп Шәкүровларны чакыралар. Уллары-кызлары да әти-әниләрен зурлап, аларның юбилей-туган көннәре мәҗлесләрен Самарның Җәмигъ мәчетендә уздыралар иде. Хәзер инде картлар алай йөрергә теләмиләр. Ни дисәң дә, Гомәр агага 10 февральдә 85 тулды бит инде. Иң мөһиме, Равиләнең “Кулинария” кибете янында гына урнашкан фатирдан (алар анда бер ел элек күченделәр) Гомәр ага һәм Галия апаның өч баласы, алты оныгы һәм бер оныкчыгының эзе суынмый, бөтен кирәк-яраклары, медицина ярдәме – барысы да бар.

Шулай авыр башланган тормышта яшәгән кешене Ходай Тәгалә картлыкта нинди җимешләр белән бүләкли бит! Татар милләтенә, илебезгә игелекле, укымышлы балалар үстереп бирүләре өчен бу ике кешегә рәхмәттән башка ни әйтеп була?! Исән булсыннар, балаларын һәм оныкларын шатландырып, тагын озак еллар яшәсеннәр иде!

# НЕ ЗАБУДЬТЕ ПОДПИСАТЬСЯ!

## ПРОДОЛЖАЕТСЯ ПОДПИСКА НА ГАЗЕТЫ И ЖУРНАЛЫ 2014 ГОД

В почтовых отделениях Самарской области вы можете подписаться и на журнал «Самар татарлары» («Самарские татары»). Подписной индекс издания 72675. Стоимость подписки на 3 месяца составляет 212 рублей 3 копейки, на 6 месяцев – 424 рублей 6 копеек.

На сегодняшний день на журнал подписаны 60 человек!

Напомним, что полноцветный глянцевый журнал «Самар татарлары» выходит с декабря 2012 года периодичностью один раз в квартал. Издание рассказывает об истории, культуре, современной жизни самарских татар. 15 октября журнал получил свидетельство о регистрации средства массовой информации в Управлении Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области.

ПОДПИСАТЬСЯ НА ИЗДАНИЕ МОЖНО
**В ЛЮБОМ ПОЧТОВОМ ОТДЕЛЕНИИ!**




ОАО Агентство «Роспечать»

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал **72675** (индекс издания)

**Самар татарлары**

(наименование издания) | Количество комплектов:

на 201_ год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда

(почтовый индекс) (адрес)

Кому

(фамилия, инициалы)

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал **72675** (индекс издания)

**Самар татарлары**

(наименование издания)

| Стои-мость | подписки | руб. коп. | Количество комплектов | |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | руб. коп. | | |

на 201_ год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда

(почтовый индекс) (адрес)

Кому

(фамилия, инициалы)



# Заман ритмына кушылып

***Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы Рәсәй картасында татарлар яшәгән оазисны хәтерләтә. Бу районның мәдәнияте, Ислам дине, тормышы, халкының гореф-гадәтләре белән кызыксынмаган кеше юктыр. Кызыксынмаслык та түгел, чөнки ул үзенең бай тарихын саклап, эшчән һәм талантлы халкын туплап, үз алдына яши дә яши.***

**Рөстәм Арифуллин,**
*Россия журналистлар Союзы әгъзасы. Иске Кулаткы*

Әле күптән түгел, 2013 елның 10 июлендә генә, Иске Кулаткы районы үзенең 85 еллык юбилеен билгелеп үтте. Бу истәлекле чара әйтерсең лә ераклардан килгән кунакларга да, үз халкына да районның күркәм йөзен күрсәтте.

Шушы 85 ел эчендә Иске Кулаткы районы озын һәм катлаулы юл үткән. Аның тарихы XVII гасырның азагы - XVIII гасырның башына туры килә. Элек бу җирләр Саратов губернасының Хвалынск өяздына кергән. Ә инде 1943 елда, Ульяновск өлкәсенә кушылгач, биредәге татар авыллары бердәм булып, тупланып яши башлаганнар.

Иске Кулаткы районы дигәч, күз алдына бай урманнары, текә таулары, яшел хәтфәдәй иркен болыннары, табигать куенынннан челтерәп аккан чишмә сулары белән матур төбәк килеп баса.

Биредә яшәгән халык үз юлында булган киртәләрне җиңеп, үзгәртеп кору чорында да үз йөзен, татар телен саклап калган, киләчәккә нык нигез салган.

Дөрес, Советлар Союзы таркалгач, биредә дә берара вакыт тукталган кебек була, һәм авыл хуҗалыгы тармагында колхозлар һәм совхозлар юкка чыгып, халыкка яшәргә катлаулыклар тудыра. Ләкин җирдә хезмәт иткән халык нинди генә кыенлыклар булмасын, югалып калмады һәм башка формада үзләренә хуҗалыклар оештырып, икмәк үстерүне, терлек үрчетүне дәвам итте.

Район территориясендә ике авыл производство кооперативы, 42 крестьян-фермер хуҗалыгы игенүстерү һәм терлек үрчетү белән шөгыльләнәләр. Хуҗалыкларда һәм шәхси секторда 5523 баш мөгезле эре терлек, 1763 баш сыер, 11 964 баш вак терлек исәпләнә.

Бүген Иске Кулаткы районының тормышын алып баруда, халык ихтыяҗларын яклауда район башлыгы Эдуард Әнвәр улы Ганеевнын роле шактый зур. Ул идарә иткән кыска гына вакыт эчендә районыбызның йөзе яктырып китте, һәм төрле өлкәдә уңай якка үзгәрешләр сизелә башлады.

Хәзерге вакытта Иске Кулаткы районында Атлаш, Терешка, Зеленай авыллары һәм Иске Кулаткы шәһәр поселениесе бар. Алар үзләренә 22 авылны берләштерәләр. Бүген шушы поселениеләрдә 13200 кеше яши, аларның 95 процентын татарлар, 5 процентын руслар белен чувашлар тәшкил итә.

2013 - 2014 уку елларында районда булган 6 урта, 3 төп һәм 2 башлангыч мәктәпләрдә 959 укучы белем ала.

Шунысы мөһим – 1998 елда Иске Кулаткы эшчеләр поселогында дәүләт механика-технология колледжы ачылды. Биредә 9 һөнәр алу буенча белем бирәләр. Хәзерге вакытта уку йортында 310 студент исәпләнә.

Механика-технология колледжында килешүләр нигезендә Ульяновск дәүләт авыл хуҗалыгы академиясенең төрле факультетлары эшләп тора.

Иске Кулаткы эшчелер поселогында ике балалар бакчасы эшли, һәм аларда 247 бала тәрбияләнә. Авылларда балаларга тәрбия бирер өчен мәктәпләр каршында шулай ук махсус төркемнәр дә эшли. Халыкның сәламәтлеге сагында бер үзәк район хастаханәсе, авылларда фельдшер-акушерлык пунктлары авыруларны дәвалауда зур эш башкаралар.

Соңгы елларда районыбызда төзекләндерүгә, халык ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә тагын да зур игътибар бирелә башлады. Шушы нигездә авыллар таушалган өйләрдән азат ителеп, алар



урынына яшеллек зоналары барлыкка килде. Узган 2013 елда Урта Терешка, Югары Терешка, Кирюшкино, Яңа Зеленай һ.б. авылларда су линияләре яңартылды, һәм урамнарга яңа колонкалар куелды.

Иске Кулатки районының 9 авылында табигый газ яна. Бүгенге көндә зәңгәр ягулыкны бирү өчен Иске Зеленай авылында мөһим эшләр башкарыла. Махсус программа нигезендә 2018 елда барлык авылларны да табигый газ белән тәэмин итү планлаштырылган.

Менә 83 ел инде Иске Кулаткы районында саф татар телендә "Күмәк көч" район газетасы басылып килә. Аны районның көзгесе, дип әйтсәк, һич ялгыш булмас, чөнки газета битләрендә бу төбәкнең бар тормышы яктыртыла. "Күмәк көч" район газетасының баш мөхәррире итеп озак еллар талантлы журналист Әнвәр Закир улы Мөхәммәтрәхимов хезмәт итте. Хәзерге вакытта коллектив белән үз эшенең остасы Сабира Әдип кызы Абитова җитәкчелек итә.

Газетаның журналистлары, бу юлларның авторы Р.И. Арифуллин, М.С. Масиева, Д.Р. Хәйрова, З.А. Хәсәнова, Е.Ш. Яфарова, Д.Д. Насыйрова, Г. Р. Хәбибуллина (бухгалтер) авыллардан бай материаллар туплап, халыкка җиткерәләр. Безнең районыбызның иҗат сөючеләре Самар шәһәрендә озак еллар басылып килүче "Бердемлек" газетасы белән дә нык элемтәдә торалар, аның битләрендә талантлы язучыларыбызның шигырьләрен, хикәяләрен даими укып була.



Хәзерге заманның ритмына кушылып, Рәсәйнең башка төбәкләре белән бергә атлый Иске Кулаткы. Аның тормышын яктыртуда шулай ук саф татар телендә эфирга чыгучы "Яңа дулкын" район телевидениесенең роле зур. Телевидение директоры Венера Әделхан кызы Деникаева һәм аның журналистлары 3 мәртәбә тапшырулар ясап, районыбызда булган мөһим вакыйгаларны чагылдыралар, татар культурасын, Ислам динен үстерүдә зур эш алып баралар.

Гомумән, Иске Кулаткы районында татар культурасын, Ислам динен үстерүгә район башлыгы Эдуард Ганеев зур игътибар бирә һәм төрле чаралар алып баруга хәтта үзенең хәләл малын да кызганмый.

Аның инициативасы һәм зур ярдәме белән Иске Кулаткы районында Бөтенроссия "Түгәрәк уен" татар фольклор фестивале уздырылды. Ә инде 2013 елның 10 июлендә Иске Кулаткы районының 85 еллык юбилеен билгеләү уңаеннан изге җиребездә беренче мишәр фольклор фестивале гөрләде. Искекулаткылылар үзләренең җыр-моңга талантларын чит төбәкләрдә дә күрсәтәләр.

Соңгы елларда һәвәскәрләребез Самар, Төмән, Мәскәү һ.б. шәһәрләрдә Бөтенроссия татар фольклор фестивальләрдә катнашып, сәхнәләрдә искиткеч чыгышлар ясыйлар.

Ислам диненең гореф-гадәтләрен саклап, аны яшь буынга өйрәтеп яши белә безнең халык. Бүген Иске Кулаткы районының һәр авылында нурлы манаралардан моңлы азан тавышлары сибүче 27 мәчет эшләп тора. Мәчетләрнең каршында ук яшь шәкертләргә Ислам динен өйрәтүдә "Җомга мәктәп"ләре зур эш башкаралар. Рамазан айларында ураза тотучыларның, Корбан айларында корбан чалучыларның саны хәзер шактый күбәйде.

Иске Кулаткы эшчеләр поселогында дини укулар үткәрү матур гадәткә әйләнде. Алар Рәсәй төбәкләреннән, Казан шәһәреннән килгән танылган мөгаллимнәр катнашында 10нчы мәртәбә уздырылды инде. Районыбызның мөселманнары һәр ел Бөтенрәсәй дин әһелләре форумнарында катнашып, Изге Болгар җиренә дә сәяхәт кылалар. 2012 елның июнендә якташларыбыз өчен Изге Болгар җирендә V дини Кулаткы укулары оештырылды.

Кырда тир түгеп, икмәк үстерүчеләр дә данланалар безнең районда. Моны һәр җәй матур табигать кочагында, яшел урман янында күркәм итеп оештырылган Сабан туйлары ачыктан-ачык дәлиллиләр.

Сабан туе – ул мөселманнарның да, кырларда хезмәт итүчеләрнең дә, өлкәннәрнең дә, сабыйларның да гүзәл бәйрәме.

2013 елда бу бәйрәм Иске Кулаткыга керер алдыннан, аның якты йөзен, эшчән халкын күрсәткән сыман, яңа урында гөрләп үтте. Биредә кыр эшчәннәренә, төрле өлкәдәге хезмәт алдынгыларына зур бүләкләр тапшырылды. Соңгы Сабан туйларында әби-бабаларыбызның элеккеге заманда җир эшкәртүен, йолаларын "Авыл йорты" дигән рәсмиләштергән мәйданчыклар чынбарлыкта күрсәттеләр.

Районыбыз территориясендә аккан Терешка, Кулатки, Избалык елгаларының сулары аккан кебек, Иске Кулаткыда да тормыш алга ага да ага. Агымсуларда билгеле төрле киртәләр дә була, ләкин биредә яшәүче эшчән татар халкы шушы киртәләрне буйсындырып, гореф-гадәтләрен саклап, горур итеп яши белә.

**Рөстәм Исмәгыйль улы Арифуллин Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районының «Күмәк көч» газетасында 34 ел журналист булып хезмәт итә.**

**Ул балачактан шигырьләр язу белен мавыга. Шушы вакыт эчендә аның меңнән артык шигыре район газетасында, Ульяновск өлкәсенең «Өмет», Самар өлкәсенең «Бердәмлек» газеталарында дөнья күрделәр.**

**Аның шигырльәре шулай ук Казан шәһәрендә “Идел” альманахында да, Татарстан Республикасының газеталарында да басылалар.**

**2011 елда ул үзенең шигырльәрен Татарстан телевидениесенең «Җырлыйк әле!» тапшыруында сәнгатьле итеп укыды.**

**Россия журналистлар союзы әгъзасы Рөстәм Арифуллин бүген дә «Күмәк көч» район газетасында хезмәт итеп, үзенең шигырьләр җыентыгын чыгару өстендә эшли.**

**«Самар татарлары» журналы редакциясе аңа уңышлар теләп, милләттәшебез Рөстәм Арифуллинның шигъри тәлгәшләрен журнал укучылары игътибарына тәкъдим итә.**



# «Семерка»

1980 еллар. Иске Кулаткы халык потребительләр җәмгыяте (райпо) складына өр-яңа «ВАЗ-2107» маркалы автомашина, гади халык теле белән әйткәндә, «семерка» килеп төште.

«Кемгә сатырлар икән бу «семерка»ны, кем шундый бәхеткә ирешер? - дигән сораулар белен Кулаткы мыж килде. Чөнки ул вакытта машина дигән нәрсә дефицит иде.

Машиналарга сокланып, дефицит дөньясын аксатып, заманалар алга чапты. Бу киртәне ерып, 95нче елларда авыл урамнарында бер-бер артлы яңа «семерка»лар пәйда булды. Халык арасында көн аша яңа машиналар алучылар турындагы хәбәрләр яшен тизлегедәй таралып торды.

Тәгәрмәчләр тәгәри, кешеләр шатлана. Кулаткы урамнарында бер-бер артлы, төрле сигналлар биреп, төрле төстәге яңа «семерка»лар колоннасы «яшел юл» алды. Инде бу машинадан да әйбәт машина юк кебек иде дөнья йөзендә. «Яшел юл»дан җай гына тәгәрәгәндә, көннәрдән-беркөнне Кулаткы урамнарын гаҗәпләндереп, «семерка»ларга сигнал-сәлам биреп, «Калина» маркалы машина узды. Озак та үтми аларның саны арта башлагач, «семерка» кабинасында утыручыларның масаеп елмаюлары, көлеп сигнал бирүләре сирәгәя башлады. Инде өстенлек «Калина» машинасына бирелде, һәм аларның хуҗалары көлә-көлә үзләрен урам геройлары итеп күрсәтергә керештелер.

Кеше көлә, тормыш дәвам итә дигәндәй, тәгәрмәчләр һаман алга тәгәрәделәр. Ахыр чиктә Кулаткы урамнарына, зур сенсация булып, башта бер, аннан ике, соңыннан берничә иномарка пәйда булды. Иномаркалар күбәя башлагач, «Калина» машинасында йөрүчеләрнең борыннары түбән салынды, ә «семерка»дагыларның йөзләреннән елмаюлар качты, һәм алар урамда юкка-барга сигналлар биреп йөрмәскә булдылар.

Тормыш үзенекен итә. Бүген урамнарда бер-бер артлы төрле чит ил машиналары йөри. Масаймый гына, салмак тизлек белән, тарихка кереп калган, 1980 елларда безнең буын өчен дефицит булган «семерка» да алардан калышмаска тырыша.

### Шул ук темага
### Азындың син, балакай

Мәрхүм бабаңның сыер җигеп, урманнан утын ташыганын оныткансың инде, улым. Нәрсәгә миңа ул «семерка?». «Семерка» ул - инвалидлар арбасы, миңа иномарка кирәк, дип теңкәгә тиясең тагын. Ай-яй, азындың син, балакай, азындың дим. «Семерка» бит тоже машина. 1980 елларда ул күп кешегә тәтеми иде, ул «крутой тачка» иде.

### Исләре дә китми

Диалог.

Егет:

– Авылыбызның түбән очында Ибәдулла бабай үзенең оныгы Инсанга иномарка сатып алган ди.

Вахит:

– Таптың яңалык. Машина алганга хәзер кемнең дә исе китми. Ибәдулла бабаң оныгына җир эшкәртергә трактор сатып алган булса, һәммәсе дә гаҗәпләнер иде.

### Хыяллана Хыяли..

Юк, юк, әни, авылдан да, күршедән дә өйләнмим. Иномарка алып, «иностранка»га өйләнү - минем хыял, – диде Хыяли.

Рөстәм Арифуллин.
Иске Кулаткы,
Ульян өлкәсе.

## Яшь түгеп озаталар

*Иртән таңнан, бер сукмактан*
*Ашыгалар ир-атлар.*
*Авылда тагын бер мәет*
*Кабул итә зиратлар.*

*Кабул итә, сорамый ул*
*Гөнаһлымы, гөнаһсыз?*
*Теге дөнья каршы ала*
*Һәммәсен дә, чиратсыз.*

*Сыкрап кала, яшьләр түгеп,*
*Моңсуланып йорт-нигез.*
*Монда кем дә артык түгел,*
*Монда һәммәсе тигез.*

*Елый-елый туган кеше,*
*Туачагын белмичә.*
*Хаталанган, нужа чиккән*
*Гомер юлы кичә-кичә.*

*Китәчәген бу дөньядан*
*Яши-яши аңлаган.*
*Кем белән шулай булмаган,*
*Кем үлемнән калмаган.*

*Инде бүтән еламый ул,*
*Кичерелә хаталар.*
*Яшь түгеп туган баланы*
*Яшь түгеп озаталар.*

## Кеше гомере

*Кычкырып бала туа да*
*Елый тәелеп яшенә.*
*Яшьләр аша яшәү килә,*
*Әйтерсең күк кешегә.*

*Яши ул, яши дөньяда,*
*Шатлык һәм кайгы күреп.*
*Җитә дә гомер көзенә,*
*Яшәү кала өзелеп.*

*Туганда үзе елаган*
*Үкси-үкси яшь бала.*
*Яшәп, гомере өзелгәч,*
*Якыннар елап кала.*

*Туганда яшь, үлгәндә яшь,*
*Бер мизгел – кыска ара.*
*Ике яшь уртасында күк*
*Кеше гомере санала.*



## Туган якка кайту

*Һәркем, чит җирләрдә яшәп,*
*Туган ягын сагына.*
*Мин дә шундый хисләр белән*
*Кайттым туган авылыма.*

*Исәнме, туган авылым!*
*Кендек кан тамган җирем.*
*Сәламемне кабул ит! - дип,*
*Мин аңа башым идем.*

*Авылыма баш идем дә*
*Ташты кайнап хисләрем.*
*Сиздем шунда еллар үтеп,*
*Олы яшькә җиткәнем.*

*Исәнме, минем балачак,*
*Мин уйнап йөргән урам.*
*Шау-гөр килеп үстек анда,*
*Бер урам тулы олан.*

*Урам тып-тын, беркем дә юк,*
*Юк балалар тавышы.*
*Уртаклаш, дидем, авылым,*
*Йөрәктәге сагышны.*

*Хатирәләргә күмелеп,*
*Уйланып тордым озак.*
*Туган йортка килеп керсәм,*
*Ишектә тимер йозак.*

*Хатирәләр, хатирәләр*
*Гел чагылды күземә.*
*Туган йортта сабый сыман*
*Булып китте үземә.*

*Күз алдымда һаман да шул -*
*Су янында тал бакча.*
*Әтием, чалгысын кайрап,*
*Тир түгеп печән чаба.*

*Әнием яшел чирәмдә*
*Каз бәбкәләрен саклый.*
*Мин ялантәпи йөгерәм*
*Дөньяны таный-таный...*

*Бакча да шул йортта, чирәм -*
*Элеккечә һәммәсе.*
*Чалгы таккан тик буш йортта*
*Кычкырмый каз бәбкәсе.*

*Уйларыма төелдем дә*
*Сорау бирдем: кем соң мин?*
*Кайтаваз килде күк күктән -*
*Син туган йортта ятим.*

*Елларымны саный-саный,*
*Язмыш белән килештем.*
*Учым тутырып, бакчабыздан*
*Кизләү суларын эчтем.*

*Кизләвебез һаман да шул,*
*Суы ага да ага.*
*Әтием топольләре үсә,*
*Агымнар бага-бага.*

*Сагынуларым һәрчак шулай*
*Минем белән калсыннар.*
*Язган шигъри тәлгәшләрем*
*Әтиемә-әниемә,*
*Мәрхүмнәргә, авылдашларга*
*Дога булып барсыннар.*

## Кереп барам көземә

*Бу көзләрдә ышанмыйча*
*Мин йөрмен үземә.*
*Көзләр белән кереп барам*
*Гомеремнең көзенә.*

*Кереп барам гүя дөньям*
*Гел көзләргә уралган.*
*Тынычланам, миндә генә*
*Гомер көзе булмаган.*

*Уйларымны уртаклашып,*
*Йөрим урман буенда.*
*Чал чәчемә сары яфрак*
*Алтын булып коела.*

*Алтынга тиңлим көземне,*
*Үткән яшьлек-гомерне.*
*Гүя аны алып киткән*
*Торналарның төркеме.*

*Бу минме соң? Кайда яшьлек?*
*Тик җавап юк сүземә.*
*Көзләр белән кереп барам*
*Гомеремнең көзенә.*



# Халыкның хөрмәтен, балаларының мәхәббәтен тоеп яшиләр




«Самар - күпмилләтле гаилә» дип аталган конкурс-фестивальдә Мәхмүтовлар гаиләсе үзенең дүрт буынын тәкъдим итте.

***Өлкәбезнең Кызыл Яр районында бик матур табигатьле Ялтай бистәсе урнашкан. Биредә искиткеч ягымлы пар Сабирҗан Хафиз улы һәм Миңлегөл Хәсәнҗан кызы Мәхмүтовлар яши. Алар турында инде мин күптән ишетеп белә идем. Алты ел элек Литвинов исемен йөрткән Мәдәният йортында уздырылган "Самар - күпмилләтле гаилә" дип аталган конкурс-фестивальдә Мәхмүтовлар гаиләсе үзенең дүрт буынын тәкъдим иткән иде. Чарада булучыларны әлеге гаиләнең чыгышы таң калдырган булган, аны гаилә башлыгы, Ялтай бистәсе мәчете имамы Сабирҗан ага Коръән сүрәләре белән башлап җибәргән, һәм бу мизгелдә тамаша залында тынлык урнашкан.***

***Мин үзем дә Сабирҗан ага һәм Миңлегөл апа Мәхмүтовларны күреп сөйләшкәч, аларның, чыннан да, ачык йөзле, зыялы һәм аралашучан булуларына инандым, һәм үземнең тәэсирләрем турында язмый кала алмадым.***

*Римма НУРЕТДИНОВА*

Сабирҗан ага һәм Миңлегөл апа тумышлары белән Татарстанның Аксубай районы Иске Ибрай авылыннан. Алар икесе дә сабый чактан ук Аллаһы Тәгаләнең берлеген һәм бөеклеген аңлап, Аның кодрәтенә ышанып, дини гаиләләрдә үскәннәр. Әхлаклы һәм инсафлы кыз белән егет никахлашып, туган авылларында яши башлаганнар. Никахлары бәрәкәтле булып, аларның бер-бер артлы кызлары һәм уллары дөньяга килгән.

Әлеге кешеләр Аллаһы Тәгаләнең сөекле бәндәләре, күрәсең. Ходай сөйгән колларын авырлыклар биреп сыный, диләр бит. Сабирҗан ага белән Миңлегөл апаның капкасын да кайгы җилләре каккалап торган шул. Аларга яңа туган сабыйларын һәм инде үсеп җиткән улларын да җирләргә туры килгән. Тик алар беркайчан да язмышларына зарланмыйча, башкалар өчен борчылып яшәүләрен дәвам иткәннәр. Бу олы җанлы кешеләрнең сабырлыгына, рухи ныклыгына сокланырга гына кала.

Ни генә булмасын, тормыш елгасы бер ашкынып, бер тынып, үз ярларында ага биргән. Язмышларына күнеп, исән-сау булган сабыйларына куанып яшәгәннәр Мәхмүтовлар. Сабирҗан әфәнде төпле белем алган – читтән торып Минзәлә



*Мәхмүтовлар гаиләсе. 1972 ел.*

шәһәрендәге авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаган. Бу вакытта гаиләдәге «муеннан» эшне, балаларны тәрбияләүне хәләл җефете үз өстенә алып, иренә булышлык күрсәткән.

Гомумән, Мәхмүтовның тормышы хезмәттә үткән. Иң элек Иске Ибрай авылы хуҗалыгында эшләгәннәр, аннан соң Ялтай бистәсенә күченеп, хезмәт юлларын бередәге «Дружба» колхозы, соңрак «Металлурглар» заводының ярдәмче хуҗалыгында дәвам иткәннәр. Сабирҗан ага ветеринар, зоотехник, ферма мөдире, ясалма орлыкландыручы вазифаларын башкарган. Коллективта ул үз кеше, киңәшеннән һәм ярдәменнән ташламаучы остаз буларак кабул ителгән, эшенә намус белән карaганга, һәрвакыт беренчеләрдән булган. Бу турыда аның күпләгән Мактау кәгазьләре дә сөйли.

Шул арада Мәхмүтовларның балалары да үсеп җиткән. Һәркайсы белем алып, йөрәгенә якын һөнәрен сайлаган. Әти-әни лачын кебек канат җәеп, балаларының һәр адымын да күзәтергә өлгергән: «Аллаһы сакласын, берәрсе «кыек» басып куймасын».

«Оясында ни күрсә, очканында шул булыр», – диләр бит. Кайгыртучан һәм бер үк вакытта таләпчән гаиләдә үскән мәхәббәт җимешләре Әлфия, Әмир, Фәния, Фәрһәд, Әнвәр бүгенге көндә матур итеп яшиләр, кияүләре Мөҗаһит һәм киленнәре Румия, Альбина, Әнисә белән сигез онык үстерәләр.

Самар өлкә «Туган тел» татар җәмгыяте оештырылганнан бирле милли җанлы Мәхмүтовларның биш баласы чаралар оештыруда актив рәвештә катнашып килә. Алга таба эстафетаны оныклары да дәвам итә. Уллары Фәрһәд һәм киленнәре Альбина – бүгенге көндә дә өлкәбезнең татар милли хәрәкәтенең әйдәп баручылары, алар күпләргә таныштыр, мөгаен. Нәкъ Миңлегөл апа 23 ел дәвамында Самар шәһәрендә уздырылган Сабан туйларына, катыктан тәңкә эзләү уенын үткәрер өчен, тәмле катык оета.



*Мәхмүтовлар гаиләсе. 2009 ел*

Сабирҗан ага һәм Миңлегөл апаның тормышлары мул, алар әле дә мал-туар асрыйлар. Йортларына барып керсәң, үзенә бер төрле нур, гаилә җылысы бөркелеп тора биредә. Балалары – әни-әтиләренең өйләрендә иң кадерле кунаклар. Алар еш кына кучтәнәчләрен, бүләкләрен тәяп кайталар, йорт эшләрендә булышалар, әти-әниләренең үтемле киңәшләрен тыңлыйлар, аларның саваплы гамәлләрен күреп, үзләре дә игелек кылып яшәргә тырышалар.

Әйе, бу гаиләдәге яшәеш, тәртип динебез буенча көн күрү белән бәйле шул.

Ялтай бистәсендәге таш мәчетнең сафка басуы да Сабирҗан аганың тырышлыгы нәтиҗәсендә икән. Моңа кадәр намазлар бер карчыкның өендә укыла торган булган. Бу дөрес түгел дип санап, Сабирҗан әфәнде һәм аның авылдашы Касыйм ага Баһаутдинов мәчет төзү уе белән яна башлаганнар. Башларына шундый уй кергәч, аны тормышка ашыру юлларын эзләргә керешкәннәр, таныш-белешләрен барлаганнар. Ялтай бистәсендә «Металлурглар» заводының ярдәмче хуҗалыгы урнашылганлыктан, иң элек завод директоры Максим Борисович Оводенкога, аннан авыл халкына, региональ Дия нәзарәтенең Попечительләр шурасына мөрәҗәгать иткәннәр.

90 еллар башы – бик авыр вакытлар... Хәтта аларның җыелган акчалары инфляциягә дә юлыккан. Тик мәчет салырга теләүчеләр бирешмәгәннәр, Аллаһы Тәгалә ризалыгы белән башланган изге ниятнең уңышка ирешүен төгәл белгәннәр, күрәсең.

– *Аллаһыга шөкер, иман йортын төзергә булышучы кешеләр дә табылды,* – дип, Сабирҗан хәзрәт Арсен Рамазанов (хәзер мәрхүм, урыны җәннәттә булсын) кебек иганәчеләрне дә телгә ала.

Әйе, әлеге төзелеш, анда күрсәтелгән тырышлык, ярдәмчеллек үрнәкләре турында аерым бер китап язырлыктыр, мөгаен. Шулай итеп, биредә кирпечтән Аллаһы йортын төзеп, эчке эшләрен дә башкарып куйганнар, һәм 1996 елның гыйнварында әлеге мәчетне ачу мәҗлесе дә үткәрелгән. Нәкъ шушы вакыттан бирле Сабирҗан

ага Ялтай бистәсендә имам-хатыйб вазифасын башкарып килә дә инде.

Әлеге эшне башкару – мәчет йортының барлык мәшәкатьләрен дә үз өстенә алу дигән сүз дә бит. Алары да бихисаптыр шул. Әнә, газ мәсьәләсе буенча гына да Сабирҗан әфәндегә күпме йөрергә туры килгән, ул бу эшкә хәтта улларын да тарткан. «Металлурглар» заводы үзенең ярдәмче хуҗалыгыннан баш тарткач, мәчетне җылыту зур проблемага әйләнә. Җирле торак-коммуналь хуҗалыкка теркәлгәч, үзәктән җылытыр өчен коммуналь бәяләр бик кыйммәтләнә. Иман йорты әлеге чыгымнарны каплый алмагач, бинаны җылытудан бөтенләй туктатканнар, һәм бер ел дәвамында намазлар салкын мәчеттә укылган. Шуннан соң хәзрәтнең һәм аның улларының тырышлыгы нәтиҗәсендә мәчеттә, законлаштырылган проект буенча,



аерым газ белән җылыту булдырылган.

– *Самар газ челтәренең җитәкчесе Хәлиулла һәм проект ясаучы Рамил Кудралиевларга мөрәҗәгать итеп ялгышмаганбыз икән шул, алар безгә бу мәсьәләдә бик зур булышлык күрсәттеләр. Аллаһының рәхмәте яусын үзләренә,* – ди Сабирҗан ага әлеге вакыйгаларны искә алып.

Бүгенге көндә мәчеткә авылдан унлап карт йөри, җомга, гает намазларына күрше-тирә авылларда яшәүче үзбәкләр, таҗиклар, әзәрбайҗаннар, чеченнар һәм башка мөселман халыклары да киләләр икән.

– *Мәчеткә бирелгән садакалар җыелган саен кешене җирләгәндә кирәк булган нәрсәләрне алып куярга тырышабыз. Олылар кәфенлекләр, мәет юарга комганын, кабер такталарын әзерләп куйса, яшьләр бу турыда уйламыйлар бит әле. Әдөнья хәлен беркем*



*Самар шәһәр округының “Теремок” никахлашу сараенда уздырылган алтын туй мәҗлесе.*





иде аларга. Гомумән, Сабирҗан аганың һәм Миңлегөл апаның балалары әти-әниләрен куандырыр өчен бик тырышалар, аларга зур бәйрәмнәр оештыралар. Әнә 2011 елның 26 мартында аларның алтын туй мәҗлесләре, өлкә ЗАГС вәкилләре ярдәме белән, Самар шәһәр округының «Теремок» никахлашу сараенда зур тантана рәвешендә уздырылган. Әйе, ярты гасырга сузылган мәхәббәт һәм тугрылык, тату тормыш тәҗрибәсе аларның балаларына һәм оныкларына гына түгел, башкаларга да үрнәк булырлык бит.

Сабирҗан ага: *«Балаларыбызның һәм оныкларыбызның уңышларын күзәтеп кенә торабыз, алар өчен шатланабыз»,* – ди. Үзара сөйләшкәндә болай

*дә белми, шуңа да без һәрвакыт әзер торырга тиешбез.*

*Мәетне җирләргә хәленнән килмәгәннәргә дә булышлык күрсәтәбез. Халыкка җиңелрәк булсын дип маташабыз инде. Барлык таләпләргә туры китереп, җиназлыйбыз да.*

*Авыл зиратын да тәрбиядә тотарга тырышабыз, чөнки бу – адәм баласының җир йөзендәге соңгы йорты бит. Соңгы елларда авыл тирәсендәге кыр-җирләрне шәхси куллар сатып ала башлагач, аны зурайтып калырга кирәк, дигән уй-фикергә килдек. Бу ниятне башкарып чыгар өчен, авыл халкы, түрәләр арасында зур аңлату эшләре алып барырга кирәк булды. Улым Фәрһәд бу мәсьәлә буенча өлкәбезнең хөкүмәт идарәсе вәкилләре белән дә очрашты. Мөфти Вагыйз хәзрәт Яруллинны чакырып, авылда җыелышлар да уздырдык. Нәтиҗәдә, зиратыбызның мәйданы ике гектарга киңәйтелде,* – дип сөйләде Ялтай авылы имамы.

Сабирҗан хәзрәт шулай ук үзенең борчулары белән дә уртаклашып алды. Биредә аны алмаштырырдай кеше әлегә юк икән. Авылда яшәүчеләр мәдрәсәгә укырга барырга ашыкмыйлар. Ә инде имам-хатыйбны читтән алып килсәң – бик кыйммәткә төшә. Аңа фатир да, эш хакы да булдырырга кирәк була ич, ә бу әлегә мәхәлләнең хәленнән килми.

Гомер дигәнең аккан су, искән җил кебек шул. Менә быел май аенда Мәхмүтовлар гаиләсе башлыгына да 75 яшь тула икән...

Минемчә, яшәүне еллар гына түгел, ә кешеләргә кылган яхшылык, игелек, тәрбияләп үстергән тыйнак, сөйкемле балалар, башкаларның кадер-хөрмәтен тою да билгелидер шул. Аллаһыга шөкер, Сабирҗан ага һәм Миңлегөл апа халыкның хөрмәтен, балаларының мәхәббәтен тоеп яшиләр.

Гадәттәгечә, бу гаиләдә әти-әниләренең юбилейлары уңаеннан зур мәҗлесләр үткәрелә, һәм бирегә бик күп туганнары, дуслары җыела икән. Гаилә бәйрәмнәрендә Сабирҗан ага һәм Миңлегөл апаның оныклары Коръән аятьләрен укып, татар җырларын башкарып, шигырьләр сөйлиләр. Уллары Фәрһәд әлеге чараларга махсус презентацияләр әзерли: зур экраннан гаилә архивындагы фотосурәтләрне күрсәтә. Гаилә башлыгының булачак юбилеен да сау-сәламәт булып, матур итеп үткәрергә насыйп булсын



дип тә әйтеп куйды ул: *«Тормыш – ул басу. Яшьлегеңдә ни чәчсәң – картлыгыңда шуны җыярсың».* Менә хәзер Мәхмүтовлар үз гомерләрендә чәчкәннәренең мул уңышларын җыялар да инде.

*– Әлхәмдүлилләһ! Балаларыбыз, оныкларыбыз динебез кануннары буенча, үз тамырлары белән кызыксынып, безне хөрмәт итеп яшиләр. Алардан безгә фәкать әйбәт хәбәрләр генә килеп тора,* – дип, шөкер итә Ана даны медале белән бүләкләнгән Миңлегөл апа да.

Әйе, әлеге гаилә әгъзалары белән сәгатьләр буе сөйләшергә була икән. Алар белән аралашканнан соң, газиз телебезгә, динебезгә, ата-анабызга мәхәббәт арта. Дөньяда мондый кешеләр күбрәк булса, яшәү дә ямьлерәк булыр иде, дип уйлап куйдым мин Мәхмүтовлар гаиләсе белән хушлашканда.

# Многодетные семьи

## Пособия, льготы и другие меры государственной поддержки



***Растить детей – дело хлопотное и недешевое. Этот очевидный факт осознает даже наше государство, поэтому по мере своих возможностей старается облегчить участь родителей.***

***Иногда это выглядит довольно смешно, а иногда – эффективно. В отношении многодетных семей смешных и эффективных мер в Самарской области примерно поровну.***

***Эта статья описывает все действующие в Самаре и Самарской области льготы, пособия и меры государственной поддержки для семей, имеющих трех и более детей возрастом до 18 лет (да, к сожалению, по достижении старшим ребенком возраста 18 лет семья утрачивает статус многодетной, так что, чтобы воспользоваться всеми льготами, лучше не мешкать).***

*Мария Кинжалеева*
*www. samarskie-roditeli.ru*




## Для всех многодетных семей предусмотрены:

1. Льгота (ежемесячная денежная выплата) по оплате коммунальных услуг в размере 23 процента от стоимости регионального стандарта жилищно-коммунальных услуг независимо от формы собственности жилищного фонда. Что это означает: допустим, Ваша квартплата равна 5000 рублей. И в вашей семье трое детей до 18 лет. Квартира приватизирована (или не приватизирована, это значения не имеет, льгота применяется в любом случае). Вы оплачиваете квартплату в полном размере. После чего отправляетесь в Управление социальной защиты и поддержки населения и получаете там список документов, который Ваше управление требует для предоставления льготы, вот их адреса:

**Адреса и телефоны Управлений социальной поддержки и защиты населения районов городского округа Самара**

| Район | Адреса | Телефоны |
|---|---|---|
| Железнодорожный | ул. Мечникова, 50 | (846) 336-35-27, 336-36-76 |
| Кировский | Каховская, 65;<br>пр. Металлургов, 11 | (846) 931-52-24,<br>931-52-26, 954-68-91 |
| Красноглинский | ул. С. Лазо, 33 | (846) 950-55-82 |
| Куйбышевский | ул. Рижская, 9 | (846) 330-05-91, 330-68-23 |
| Ленинский | ул. Спортивная, 25 В | (846) 337-83-17, 336-38-60 |
| Октябрьский | ул. Первомайская, 26 | (846) 337-30-36 |
| Промышленный | ул. Вольская, 113А | (846) 995-18-68 |
| Самарский | ул. Галактионовская, 55 | (846) 332-66-37 |
| Советский | ул. Победы, 91 | (846) 992-73-74 |

**Рассмотрим порядок расчета субсидии на оплату коммунальных услуг многодетным семьям.**

Он определяется Постановлением правительства Самарской области от 5 августа 2013 года и приложением к этому Постановлению: *http://www.rg.ru/2013/08/13/samara-post364-reg-dok.html*

Тот самый региональный стандарт стоимости жилищно-коммунальных услуг отличается в Самаре и Новокуйбышевске, в Кинеле тоже отличается.

Рассмотрим Самарские нормы:

Если семья состоит из трех и более человек, то на одного человека стандарт стоимости ЖКУ составит 1836 рублей. На семью из пяти человек 1836*5=9180 рублей.

Предположим, фактическая квартплата Ваша равна 5000 рублей. При расчете льготы используется региональный стандарт.

То есть 9180*23% (размер льготы для многодетных семей) = 2111,4 рубля.

Именно эту сумму обязаны *возвращать* вам органы социальной поддержки и защиты. Начисление обычно производится на карту сбербанка.

2. Следующая мера государственной поддержки – предоставление бесплатных лекарств детям до шести лет, вне зависимости от группы здоровья. О порядке предоставления и способах получить бесплатные лекарства, читайте в статье: *http://samarskie-roditeli.ru/content/5617-besplatnye-lekarstva-vsem-detyam-kak-poluchit.html*

3. Так же действует ежемесячная денежная компенсация расходов на проезд на внутригородском транспорте, а также в автобусах пригородных и внутрирайонных линий для учащихся общеобразовательных школ в размере 100 рублей на каждого ребенка. Их оформление так же осуществляется в управлениях социальной защиты.

## Пособия для многодетных семей

С 2013 года статьей 22.21 Закона №122-ГД с 2013 года установлено право на ежемесячную денежную выплату на третьего и последующего ребенка в размере 7109 рублей.

Описание льготы канцелярским языком можно почитать здесь: *http://suprema63.ru/msdr/portal/social/privileges/privilege/detail/print.do;jsessionid=109449A8478B8C979B9140A79BEC3359?categoryId=262974197&pconditionId=262974230*

Отмечу, что данная льгота предоставляется всем семьям, где доход на одного человека не превышает 24000 рублей. То есть на семью из пяти человек совокупный доход (зарплата мамы и папы) вместе не должен превышать 120 тысяч рублей.

Выплата производится ежемесячно, оформление так же производится управлениями социальной защиты и поддержки.

Так же на каждого ребенка предоставляется доплата к ежемесячному пособию в размере ста рублей.

Отдельный список пособий предоставляется семьям, которые отнесены к малоимущим. В таких семьях доход на одного человека меньше прожиточного минимума: для взрослых – 7 838 рублей, для детей – 6 857. На семью из пяти человек – двое взрослых и трое детей – ниже прожиточного минимума считается семейный доход меньше 36247 рублей.

Тогда вы можете оформить еще ряд пособий:

- ежегодное единовременное пособие на ребенка к началу учебного года в размере 200 рублей
- ежемесячное пособие на детей в возрасте от 1,5 до 3 лет, не посещающих дошкольную образовательную организацию (не посещающие детский сад), в размере 1000 рублей за воспитание первого ребенка, 1500 рублей за воспитание второго ребенка, 2000 рублей за воспитание третьего ребенка и последующих детей
- на ребенка, обучающегося в общеобразовательном учреждении, имеющем государственную аккредитацию, пособие на питание ребенка в размере 350 рублей





## Единовременные пособия

Каждая семья, в которой рождается третий ребенок, имеет право на «региональный материнский капитал» в размере 100000 рублей. Капитал выплачивается сразу после рождения третьего ребенка, при условии подтверждения целевого расходования средств капитала:

1. приобретение и ремонт жилья, в том числе по ипотеке;
2. получение детьми образования в профессиональных образовательных учреждениях на территории РФ и оплату учреждений дошкольного образования на территории Самарской области (оплата детских садов и школ);

3. получение детьми или самим заявителем платных медицинских услуг;
4. приобретение транспортного средства;
5. приобретение предметов, необходимых для ухода и развития ребенка (детей) первого года жизни.

Требования, предъявляемые к документам, подтверждающим расходы, достаточно жесткие, их нужно уточнять по месту Вашего жительства. Обязательно предоставление документов, подтверждающих многодетность и подлинников фискальных документов (чеков) в случае, если расходы произведены на товары для детей. Часто возникают недоразумения при неполном наименовании товаров в чеках, т. к. нельзя точно установить – детские товары приобретались, или предназначенные для всех категорий граждан. Наиболее просто будет потратить региональный материнский капитал на приобретение жилья. Впрочем, это актуально и для федерального материнского капитала на второго ребенка.

И, наконец, семьи, в которых воспитывается три и более ребенка, имеют право в соответствии со ст. 28 Земельного кодекса Российской Федерации приобрести бесплатно, в том числе для индивидуального жилищного строительства, находящиеся в государственной или муниципальной собственности земельные участки.

*http://самара.рф/administration/dept/17034*

Участки предоставляются в том муниципальном образовании, где прописана семья, либо где она проживает. Одновременное предоставление земли в нескольких участках не допускается.



Для оформления земельных участков необходимо удостоверение многодетной семьи и заявление, которое можно скачать по ссылке выше. Там же находится перечень документов, который предоставляется в Департамент семьи, опеки и попечительства Администрации городского округа Самара, который ведёт прием заявлений граждан, имеющих троих и более детей, желающих бесплатно приобрести сформированные земельные участки из земель, находящихся в государственной или муниципальной собственности.

Как видите, предоставляемые льготы довольно многочисленны, а порядок их получения бывает замысловатым.

На форуме Самарские родители многодетных семей много, накоплен опыт получения всех перечисленных пособий, так что обращайтесь!

**Юридический отдел:**
http://forum.samarskie-roditeli.ru/forum/53-iuridicheskii-otdel/
**Сообщество многодетных мам**
http://forum.samarskie-roditeli.ru/forum/344-multimamy/



***Капитан московского «Спартака» Игорь Нетто частенько кричал вслед бросившемуся в скоростную атаку дебютанту Галимзяну Хусаинову: «Ну куда ты опять, татарин, понесся!». Правда, когда тот завершал свои проходы по футбольному полю меткими ударами или голевыми передачами, что случалось нередко, капитан только разводил руками. Но, согласитесь, не самый удачный вариант обращения к Гиле, с точки зрения толерантности, выбирал спартаковский вожак.***

*Рашид Шакиров*



# «КРЫЛЫШКИ» ДАЛИ ЕМУ КРЫЛЬЯ



*Спартаковский капитан с Кубком СССР по футболу*

Редактор федерального журнала «Татарский мир» Ринат Мухамадиев в разговоре с Хусаиновым-ветераном затрагивал эту тему. «Да, – отвечал тот, – некоторые футболисты в пылу борьбы на поле и «татарином» называли. Не обижался я... А Гилей звали ребята, с которыми мы во дворе гоняли мяч... А уже потом так стали ко мне обращаться и коллеги-футболисты, тренеры, журналисты...».

Да, Гилей его начали звать в Куйбышеве, а потом появились и другие прозвища: «маленький танк», «Великий Малыш», «спартаковский рысак», «Резак Пехлеви» (обыгрывались его резаный удар внешней стороной левой стопы и имя последнего шаха Ирана Мохаммеда Реза Пехлеви, который был на слуху в СССР, поскольку трижды в 50-70-е гг. приезжал в Советский Союз. Короче, «шах футбола с классным ударом»). Зарубежная пресса окрестила его «летающим хозяином футбольного поля», когда в 1965 году сборная СССР сыграла вничью с командой Бразилии во время турне по Южной Америке. А после победы в ходе того же турне над сборной Уругвая со счетом 3:0 (два мяча на счету Галимзяна) репортаж об игре вышел в местной газете под заголовком: «Этот маленький советский бриллиант погубил весь Уругвай!». Популярный спортивный комментатор Николай Озеров говорил: «Когда на поле Хусаинов, жди острых моментов и голов!». А другой известный в спортивном мире Николай – Старостин – написал о нем такие слова: «Галимзян – из славного племени маленьких гигантов футбола».

Как-то в ходе чемпионата страны 1962 года москвичи одержали победу в Ташкенте в 47-градусную жару. Закончился первый тайм, и хозяева вели со счетом 2:0. Играть в таком пекле было невозможно... Но после перерыва затерзавший оборону «Пахтакора» Хусаинов дважды поразил ворота хозяев. Вскоре туда же влетел третий мяч. И в раздевалке «Спартака» прозвучало в адрес вожака: «Да, Гиля, глядя на твою всесильность, становится понятно, почему Русь жила триста лет под татарским игом». Правда, по другим источникам, это было сказано после тяжелейшей двухдневной игры с минским «Динамо» в финале Кубка СССР 1965 года, когда два гола Хусаинова принесли победу его команде.

О его популярности среди болельщиков лучше всего свидетельствует анекдот, как один из них приходит в Большой театр на балет «Спартак» и спрашивает: «А Хусаинов играет?» Встретить имя действующего спортсмена в анекдоте – большая редкость. Так выделяли только избранных.



*«Крылышки» в атаке. Удар Г. Хусаинова*



*Отец и мать братьев Хусаиновых*



*Завиль Хусаинов (в центре)*




*Галимзян и Халиль Хусаиновы, 1992 г.*



*Галимзян, Вадим, Наиль Хусаиновы*

Путь к такой популярности начался 27 июля 1937 года, когда в семье Салиха Фаттаховича и Зямзямии Ахметовны, проживавших в селе Новое Иглайкино Татарской АССР, родился первенец Галимзян. Вскоре родители с маленьким сыном переехали в г. Куйбышев – к новому месту работы отца. «Жили всей семьей в небольшой коммуналке, – вспоминал впоследствии Хусаинов. – Там мы и выросли (братья Галимзян и родившиеся в Куйбышеве Завиль – в 1939 г., Наиль – 1941 г. и Халиль – 1945 г. – *Прим. авт.*), получили образование. Отец-фронтовик умер рано, в 1953 году... В том же 1953 году я поступил в Куйбышевский гидротехнический техникум (ныне – Самарский энергетический колледж) и через четыре года получил специальность мастера инженерной геологии и гидрологии. А в футбол пришел через дворовые команды… Летом играли в футбол двор на двор, улица на улицу, а зимой в хоккей с мячом. Я еще был и одним из лучших баскетболистов…».

Почему-то Хусаинов промолчал о том, что в 14 лет считался сильнейшим пловцом области среди юниоров, а его городской рекорд для 25-метрового бассейна продержался четверть века.

Один из игроков «Крыльев Советов» 60-х годов Владимир Бреднев так описал начало своей и Гили спорткарьеры: «Когда «Крылышки» стали играть на «Динамо», мы, пацаны с Арцыбушевской улицы, постоянно «проходили, пролезали, проползали» на все матчи, посещали почти все тренировки мастеров...

Зимой на катке случайно прослышали, что клуб «Динамо» проводит отбор в детскую команду мальчиков 1937-38 годов рождения. Отбор – по воскресеньям в спортзале имени Дзержинского. И мы пятеро с той самой Арцыбушевской тоже пришли на просмотр. Отбор был прост. Играли пять на пять, потом тренер говорил, кому приходить в следующее воскресенье... Мальчишек в результате осталось около 20. В число счастливчиков из нашей пятерки попали трое, в том числе я. Здесь впервые судьба свела нас с Галимзяном Хусаиновым. Нам выдали настоящую, причем новую, футбольную форму. Хотя и не совсем по размеру. Представьте малыша Гилю в футболке и трусах 46-48 размера. Зато бутсы были точно по ноге. Тогда наша команда выиграла первенство города, и футбольная федерация наградила каждого книгой Семена Бабаевского «Кавалер Золотой Звезды» с дарственной надписью: «Чемпионам г. Куйбышева по футболу среди детей». Бреднев отмечает, что первым их тренером стал М.А. Сенин, учивший играть и в футбол, и в русский хоккей. В 1955 году юношеская сборная города под его руководством стала чемпионом Советского Союза по хоккею с мячом. В ней выступали четыре динамовца, в том числе Г. Хусаинов.

С 1953 года Гиля становится игроком футбольной юношеской команды «Динамо» (Куйбышев), с равным успехом играя и в полузащите, и на острие атаки. А зимой достойно защищал честь куйбышевского «Труда» в первенстве РСФСР по хоккею с мячом (к нему даже приезжали гонцы из московского «Динамо» с предложением стать столичным игроком). Но Гиля видел себя в большом футболе, и эта мечта стала сбываться. Когда по итогам первенства 1957-1958 годов хоккеист Хусаинов был признан лучшим нападающим чемпионата, старший тренер куйбышевской футбольной команды «Крылья Советов», выступавшей в классе «А», Александр Абрамов пригласил его в клуб (правда, в 1957 году Галимзян уже выходил один раз на поле в составе дубля этого коллектива).

Итак, приглашение получено, но новичок слабо начал сезон-58 в дубле «Крылышек». И после проигрыша резервистам московского «Локомотива» Абрамов сказал парню: «Все, хватит! Сдавай форму!»

Следующая игра «Крыльев» была с московским «Торпедо». Хусаинов расположился на трибуне. Но минут за 20 до начала матча выяснилось, что заболел один из нападающих. Галимзяна нашли среди зрителей и вручили бутсы, бывшие на три размера больше нужного! Но Гиля и слова не сказал, а, выйдя на поле, показал класс.

Об отчислении Абрамов больше не вспоминал, а молодой футболист благодаря своим природным задаткам и огромному трудолюбию стал любимцем публики. Небольшого роста (164 см) форвард,



*Г. Хусаинов – хоккеист*



*«Резак Пехлеви» в действии*

случалось, творил чудеса на левом фланге. Со временем Хусаинов становится капитаном «Крыльев», за которые он сыграл 64 матча и забил 13 голов.

В 1960 году куйбышевец дебютировал в списке 33 лучших футболистов страны и начал получать приглашения от ведущих клубов. «Некоторое время я всем приглашениям, – вспоминал Хусаинов, – ... отвечал отказом, не хотел предавать родную команду и город, в котором я вырос, где впервые влюбился и нашел себе верную спутницу жизни – Любовь Леонидовну». Добавим, что и первый вызов в сборную СССР от Гавриила Качалина в том же году Галимзян получил как игрок «Крыльев Советов» (это был первый случай в истории клуба). После игры в Лейпциге Качалин посоветовал Гиле перебираться в Москву и составил ему протекцию: сначала в ЦСКА (армейцам невысокий игрок не приглянулся), затем в «Спартак», который переживал смену поколений и в чемпионате 1960 года финишировал седьмым.

Новый сезон Гиля встретил в «Спартаке». Усилиями ряда новобранцев команда поднялась в чемпионате-61 на третью ступеньку пьедестала почета. Год спустя «Спартак» стал чемпионом, а Хусаинов – вторым бомбардиром команды, забив в 23 матчах 10 голов. Судьба золотых медалей решилась в киевском матче (2:0), и первый гол был на счету Гили.

Поначалу он в «Спартаке» действовал так же, как в «Крылышках», где на правах лидера брал мяч, в одиночку стремясь обыграть трех-четырех соперников и забить гол. Однако затем освоил короткие пасы. Со временем он вырос в лидера команды, выиграв со «Спартаком» два чемпионата СССР и три Кубка страны, а также две серебряных и две бронзовых медали первенства.

«В игре Галимзян был неутомим, – писал в своей книге Н. Старостин. – Когда-то в «Крыльях Советов» он… привык все 90 минут беспрерывно гоняться за мячом от своих до чужих ворот и обратно. Он проделывал в сборной и в «Спартаке» тот же колоссальный путь... На любом поле, при всякой погоде, в самых трудных игровых ситуациях Галимзян являл пример стойкости, бодрости, воли к победе».

По мнению Никиты Симоняна, под началом которого Хусаинов провел многие годы в «Спартаке», он был единственным игроком в команде, который мог сыграть на любой позиции. Симонян как-то попросил его выйти на поле крайним защитником, на что Гиля ответил словами героя фильма «Парень из нашего города», несколько видоизменив их: «Если надо, то и танки могут полететь». Сам он всегда руководствовался фразой: «На футбольном поле главное – рысачить».

Хусаинов как никто другой умел настраиваться на решающие матчи, проявлять бомбардирские качества и вносить перелом в игру. Он забил пять голов в разных финалах. Четыре из них в Кубке СССР: «Шахтеру» ударом с углового, армейцам Ростова и пару мячей в упомянутом уже двухдневном сражении с минчанами. А пятый финальный гол Галимзян провел в ворота испанцев в Кубке Европы-64. Ну а про точность его ударов говорят сами за себя 145 забитых мячей в зачет клуба Григория Федотова. Первый его гол публика увидела 15 апреля 1958 года, а последний – 8 ноября 1972 года.

Но не только отменным дриблингом, скоростью и умением забить мяч из любого положения славился Хусаинов: он был душой и настоящим лидером «Спартака». Не случайно в течение шести лет подряд партнеры избирали его капитаном, а болельщики клуба



*Сборная СССР – бронзовый призер чемпионата мира в Англии, 1966 г.*

с 60-х годов начали говорить: «В «Спартаке» обязательно должен играть татарин». (И действительно, следом за Галимзяном в команде блистали «сборники» Ринат Дасаев, Вагиз Хидиятуллин и Руслан Нигматуллин, играли Альмир Каюмов, Ренат Сабитов и др.)

Как игрок «Спартака» Гиля семь раз по итогам сезонов входил в состав 33 лучших футболистов страны! Привлекался он и в сборную СССР, за которую провел 33 игры и забил 4 гола. Хусаинов дважды участвовал в финальных турнирах чемпионатов мира: в 1962 году в Чили и в 1966-м – в Англии, где наша сборная получила бронзовые медали за четвертое место. А в 1964 году Галимзян, как уже отмечалось, стал серебряным призером чемпионата Европы. Играл он



и в отборочных матчах чемпионата мира 1970 г. Французская газета «Экип» писала: «Таким футболистам, как Понедельник, Хусаинов, Иванов, незачем учиться у европейских звезд».

Безумно любя футбол, Хусаинов не замыкался на нем. Он всерьез увлекался джазовой музыкой, в заграничных поездках тратил деньги на пластинки, чтобы пополнить свою богатую коллекцию. В кругу меломанов было в ходу выражение: «пластинки от Хусаинова». Он вел обмен ими с коллекционерами из других стран, учил английский, чтобы понимать и петь джаз. Гиля даже собаке своей, карликовому пуделю, дал кличку «Джазик». В «Спартаке» капитана называли «музыкальным цехом», поскольку по вечерам послушать хорошую музыку в его номер собиралась почти вся команда.

Кроме джаза Галимзян «дружил» и с родными мелодиями. «Очень люблю татарские народные песни, – отвечал он корреспонденту. – А вот современную эстраду не очень воспринимаю».

И в клубе, и в сборной СССР Галимзян считался хорошим шахматистом. Любил он и попариться, пристрастив к этому партнеров. Вот что вспоминал Геннадий Логофет: «Возвращаясь с выезда воскресным утром, мы … спешили в Сандуны или в Центральные бани. А когда домашняя игра выпадала на среду, то в четверг предпочитали Оружейные или Строчановские. В Строчановских собирались татары – по-моему, лучшие парильщики в мире. Вот и у Гили всегда с собой были свежие венички, мята, эвкалипт, а в парной он задавал такого жару, что без привычки не выдержишь».

Он был великолепным рассказчиком анекдотов, которых знал огромное количество. Вокруг него всегда было многолюдно и весело.

Не мог Хусаинов жаловаться и на нехватку друзей, которые часто приходили к нему в гости, где их ожидал накрытый Любой стол. Однажды вечером Галимзяна подвез до дома известный артист цирка и кино Юрий Никулин. Вхож в дом Хусаиновых был и победитель Велогонки Мира 1962 года в личном зачете, многократный чемпион страны и капитан сборной СССР по велоспорту Гайнан Сайдхужин. Хорошо относился к Гиле популярный бард и артист Владимир Высоцкий, с которым они нередко говорили и о музыке, и о футболе.

По словам жены, Галимзян по натуре своей был «старшим братом». Он опекал мать и младших братьев даже после того, как уехал в Москву. Получая в «Спартаке» 180 рублей в месяц, половину зарплаты регулярно отправлял в Куйбышев. И супругу всегда защищал, правда, в первую очередь от... некоторых своих родственников. Мама Гили хотела, чтобы ее сыновья женились обязательно на татарках. Но Завиль и Наиль так и не стали семейными людьми, а Халиль взял в жены Маргариту, которую свекровь уже не обижала. Когда врачи установили Завилю страшный диагноз, Гиля, как мог, спасал брата. Но операция не помогла, и Завиля в 32 года похоронили на татарском кладбище в Куйбышеве. А самому младшему брату Галимзян не порекомендовал становиться футболистом, хотя Халиль явно подавал большие надежды, играя на пер-

венство города, а во время службы в армии – за команду ЗабВО. «Хватит в семье одного футболиста», – сказал Гиля.

Сыграв в 1973 году всего четыре матча за «Спартак» и не забив ни одного мяча, Хусаинов «повесил» бутсы на гвоздь. Началась другая карьера – тренерская. В ходе ее он в 1976 году окончил институт физической культуры, а через три года получил и диплом Высшей школы тренеров. Работал Галимзян в «Спартаке» Нальчик (1974), юношеской сборной СССР (1975), «Спартаке» Москва (1976), «Шахриханце» Узбекистан (1979), «Пахтакоре» Ташкент (1980-1982), «Спартаке» Быково (1983-1986), «СК «Мясокомбината» Москва (1989-1991). Но больших успехов команды при нем не добивались, да и трудился Гиля в качестве помощника тренера, не получив возможности для самостоятельной деятельности. От переживаний начал курить, чего за ним ранее не наблюдалось. Позже он сожалел, что побоялся в первые годы тренерства возглавить бакинское «Нефтчи», – возможно, всё на этом поприще сложилось бы по-другому.

Одним словом, знаменитым тренером Гиля не стал – не хватило жесткости в обращении с подчиненными, умения требовать выполнения своих установок. Боец на поле, в жизни Галимзян слыл очень мягким человеком.

Иногда тренерство перемежалось чиновничьей работой в спорткомитетах, но этот род деятельности он не любил. Наверное, поэтому Хусаинов с удовольствием принимал предложения стать игроком различных сборных команд ветеранов г. Москвы по футболу. С 1985 года он в течение десятилетия участвовал в матчах, проводившихся в разных городах. Именно на эти годы пришелся период, когда Галимзян, «злоупотреблял алкоголем», о чем он говорил, не щадя себя: «Дело закончилось тем, что однажды ... отвезли меня в больницу, где я долго лежал под капельницей. Оттуда меня выписали инвалидом первой группы».




*С любимыми пластинками*

Да, после банального пьянства нагрянула в 1994 году тяжелая болезнь – атрофия головного мозга. Героическими усилиями жены и при помощи врачей, друзей жизнь Гили удалось спасти, но часть клеток мозга перестала функционировать, и следствием этого стали провалы в памяти, плохая ориентация на открытой местности, беспомощность в быту. На календаре был 1995 год...

Судьба не раз наносила ему чувствительные удары. Уже отмечалось, что в юности Хусаинов рано остался без отца, а вскоре после переезда в Москву в его семье случилась трагедия – выпала из окна и насмерть разбилась полуторагодовалая дочь. Больше детей у него и Любы не было. «Вся команда переживала вместе с ним горе, – вспоминал Н. Симонян. – Нам предстояла поездка на игру в Баку. Взяли с собой и Галимзяна с женой, надеялись, что все-таки полегче им будет с нами. О том, чтобы Галимзян участвовал в матче, даже и подумать не могли. И вдруг в день игры он сказал: «Я выйду на поле».

Друзья не бросили инвалида в беде. Ведь сбережений, пока Галимзян играл за «Спартак» и сборную страны, он не накопил. Из-за границы привозил родным и близким подарки, покупал жене драгоценности, которые и выручали в первое время. Любин оклад в МГУ ситуацию не менял. Больше «вкладывал» в бюджет семьи Хусаиновых в начале 90-х годов Джазик – ежемесячно 100 рублей благодаря спросу на вязки.

А потом на помощь пришел бывший спартаковец Анатолий Коршунов, создавший фонд поддержки ветеранов. В честь 60-летия Галимзяна друзья устроили большой футбольный праздник. Президент «Спартака» Олег Романцев выдал ему пожизненный сертификат, по которому ежемесячно можно было получать 200 долларов.

Поддержали Гилю в трудные дни и самарцы. В 1994 году на стадионе «Динамо», где он начинал свой путь в большой спорт, состоялся благотворительный матч ветеранов «Крылышек» и киевского «Динамо», весь сбор от которого (почти миллион рублей) был передан семье известного спортсмена. Кроме того, горадминистрация выделила три тысячи, а команда «Крылья Советов» – одну тысячу долларов в помощь одному из лучших нападающих советского футбола. Активно помогало АО «Самараэнерго» и друг Юрий Серяпин, у которого Хусаиновы останавливались, приезжая в Самару.




*С женой Любовью Леонидовной*



*Н. Симонян поздравляет Г. Хусаинова с 60-летием*



*В матче с французскими ветеранами футбола*

В начале XXI века в пользу знаменитого спартаковца проводились и благотворительные аукционы. А следующему юбилею Галимзяна Салиховича – 70-летию – был посвящен IX турнир по мини-футболу на «Кубок Российского Фанклуба «Спартак» Москва». Турнир собрал 19 спартаковских коллективов из регионов России. В церемонии награждения призеров принял участие и Галимзян. Все участники соревнований получили футболки с изображением юбиляра. А российский Фанклуб «Спартак», команды «Авторадио», «М-Видео», «ДПР» и Московская городская Дума вручили Хусаинову подарки.

В том же году Российский футбольный союз в рамках церемонии вручения премий РФС за достижения в российском футболе за 2007 год наградил Виктора Понедельника, Анатолия Исаева и Галимзяна Хусаинова в номинации «Легенда футбола».

Несмотря на инвалидность, Галимзян часто бывал на детских и ветеранских футбольных турнирах, вручал призы лучшим молодым игрокам. Хусаинов всегда помнил о Самаре и «Крыльях», давших крылья ему, и часто приезжал в город на Волге. В 2007 году он шел с флагом «Крылышек» по самарскому стадиону «Металлург» вместе с другими ветеранами клуба, когда команда его молодости переживала тяжелые испытания.

Дважды Галимзян Салихович становился главным героем передачи «Южная трибуна» на канале «РИО». Успел он вместе с женой побывать и в Музее самарского футбола, которому подарил книгу о себе, плакат и открытку с автографами, а также расписался на доске почетных гостей. В 2009 году великий спортсмен присутствовал в качестве почетного гостя 10-го турнира по пляжному футболу «Золотые пески Самары». Когда комментатор попросил присутствующих поаплодировать находящемуся здесь Галимзяну Хусаинову, у него на глазах появились слезы. Он улыбался сквозь них, а люди стояли и горячо хлопали.

Не забывал Хусаинов и свое родное село Новое Иглайкино в Татарстане, всегда находя время, чтобы навестить родственников и сходить на могилу мамы. «Такой был внимательный, чуткий, открытый, – вспоминает Сания апа Бильданова, – гостинцы всем нам привозил, ходил на кладбище».

В сентябре 2001 года он вместе с 35 другими известными представителями татарского народа, проживающими за пределами Республики Татарстан, обратился с просьбой к народным депутатам не переводить татарскую письменность на латинский алфавит, не разрушать, а совершенствовать родной язык.

Кәримовлар бергә җыелганда балаларының шуклыкларын көлеп искә алырга яраталар. «Әх, безнең әни дә, күрше апа кебек, эчүче булса, гел йоклар иде, ә безгә бәйләнмәс иде. Вәт рәхәт булыр иде шунда», - дип хыялланганнар икән. Әйе, барыбыз да балалар үстердек, беләбез. Көне-төне эштә булган хатынга нарасыйларын урам тәэсиреннән аралап калу җиңел булмагандыр шул. Ул бит кеше өйләре җыештырудан, аш пешерүдән туеп кайткан булса да, кабат шул ук эшләрне өйдә дә эшләгән. Аннары әле балаларының өй эшләрен дә тикшергән, көне буе нәрсә белән шөгыльләнүләре турында белешкән, ә йокларга яткырганда серләшү вакытлары җиткән. "Мин алар белән озаклап сөйләшеп утырырыга ярата идем. Шулай күзгә-күз карап сөйләшкән вакытларда бала дөньяны аңлап белергә дә, кешеләр белән аралашырга да өйрәнә".

Кәримовлар, ниһаять, парогенератор һәм юа торган пылесос сатып алалар. Мөнирә үзе белгән уңган һәм чиста эшли торган татар хатыннарыннан эшче төркем туплый. Хәзер инде аларның фирмасында егермеләп кеше хезмәт күрсәтә. Мөнирә ханым эш табучы, аның күләмен, бәясен билгеләүче булса, Руслан, инде күптән нефть чыгару компаниясендә эшләвенә карамастан, әнисенең клининг компаниясен рәсми рәвештә ачу мәшәкатьләрен үз өстенә алган.

Яңа туып килүче "Лазурит" компаниясен яңа фирма, дип атарга тел әйләнми. Егерме ел гомерен шушы эшкә багышлаган Мөнирәгә күптән инде җитәкче креслосында утырырга вакыт. Ә ул эшчеләренә ияреп, эшкә бармыйча булдыра алмый. Бергәләп эшләү күңеллерәк дә, тизрәк тә, дип саный ул. Әле бит яңа хезмәткәрләренең эшен дә тикшермичә булмый. Ничәмә еллар буе кешеләр аңа өйләре, балалары куркынычсызлыгын ышандырганнар икән, димәк, алга таба да фирманың репутациясен төшерергә ярамый.



Бар, бар Самарда яхшы кешеләр. Бай булсалар да, авыр хәлгә калган кешене аңлый, ярдәм итә беләләр. Мөнирә авыр вакытларында аңа ярдәм иткән бөтен хуҗаларына, юк, эшкә алган, бурычка биреп торган, башка күп нәрсәләр белән ярдәм иткән дусларына бүген чын күңеленнән рәхмәтләр укый, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итеп яши.

Шундый авыр тормышны үз җилкәсендә татыган хатын бүген үзе дә хәйрия эшләре белән танылып килә. Ул таныш татар әбиләренең келәмнәрен бушлай чистартып савап ала. Ә әбиләр чиста паласка утырып, намаз укыганда Мөнирәгә һәм аның игелекле балаларына дога кылырга онытмыйлар.

Балалары үсеп, үз тормышларын кора башлагач, Мөнирә онығы Ритага күбрәк вакытын бирә башлый. Ул аны мөмкин булган кадәр ешрак өенә алып кайтып тәрбияли, менә инде тимераякка да бастырган, үзе дә шушы нәни кызчык белән бергә спорттан ләззәт ала башлаган. "Оныклар балалардан татлырак була", диләр. Чыны шул икән, дип көләРитаның яраткан әбисе.

Әйе, бу дөньяда бернәрсә дә очраклы түгел. Кемнеңдер улы юлдан язганмы, ире эчәме, йә булмаса, берәрсе туганнары, күршеләре, балалары белән тыныша алмый икән, болар барысы да кешенең үзеннән килә, дип саный Мөнирә Кәримова. Бөтен бәлаләрнең чыганагы - ялкаулык, рухи ярлылык, күңел киңлеге җитмәүдән һәм динебез Исламны хөрмәт итмәүдән. Шушыны аңлаган кешеләрдә берниндидә очраклы хәлләр булмый. Димәк, Мөнирә белән минем очрашу да очраклы булмаган икән.



*Самарның 2 санлы икмәк заводы күренеклеләр исемлегендә. Аны милләттәшебез Муса углы Али Сөләйманов җитәкли. Унҗиде яшеннән эшкуарлык белән шөгыльләнә башлаган Али тора-бара тормышта зур казанышларга ирешеп, дәрәҗәле кешегә, уңышлы эшбатырга әйләнә.*

**Миләүшә Газимова**



# ЧЫН "КАРА" ИПИНЕ ТИК АЛИ СӨЛӘЙМАНОВ ЗАВОДЫНДА ГЫНА ПЕШЕРӘЛӘР

Ул Самарның кооператив техникумында, Ульяновск шәһәренең авыл хуҗалыгы академиясендә, Мәскәүнең кооператив университетында, Россия Президенты каршындагы академиядә укый.

Дәрәҗәле кешеләр белән дә таныш милләттәшебез. Шулай Россиянең элеккеге премьер-министры Евгений Примаковтан мактау сүзләре ишетеп, Мактаунамә белән бүләкләнә ул.

Татарстан Президенты Рөстәм Минниханов белән таныш булуына да шатлана Али әфәнде. Татарстанны Минтимер Шәймиев, Рөстәм Минниханов кебек дәрәҗәле, лаеклы кешеләр җитәкләве - зур бәхет, дип саный ул.

Бүгенге көндә 41 яшен тутырган Али әфәнде, икмәк заводыннан тыш, башка төр эшкуарлык белән дә шөгыльләнә: кибетләр тота, сәүдә йорты ачарга ниятли. Шулай ук аның нефть эшкәртүче, комбикорм заводлары да бар.

Али Сөләйманов, милли җанлы кеше буларак, татар милли хәрәкәтенә матди ярдәм күрсәтә, дин юлында да игелекле гамәлләр кыла. Үзенең туган авылы – Ульян өлкәсенең Зур Черкели авылында 2000 елда мәчет салдырган.

Самарның Тарихи, Иске мәчетләренә һәр җомга ипи биреп тора. Һәр елны Җиңү көне уңаеннан татар ветераннарын һәм икмәк заводы урнашкан Тимер юл районы ветераннарын бүләкли. Балалар йортларын ай саен акча, икмәк белән тәэмин итә ул. Шулай ук гарип-горабаларга да мәрхәмәтле милләттәшебезнең ярдәме тия. Төрле төбәкләрнең мәдрәсәләрендә укучы шәкертләргә да булыша.

Гомумән, Али Мусеевич үзенә ярдәм сорап килгән кешеләргә, татарларга, кулыннан килгәнчә, һәрвакыт ярдәм итә.

Ул дини кануннарны үтәргә тырыша. Аның эш офисындагы шкафында Коръән, догалар язылган рамкалар тора. Бередә гаиләсенең фотосурәтләре дә урын алган.

Эш офисы зәвык белән эшләнгән, барысы да үз урынында, монда тәртип, чисталык-пөхтәлек хөкем сөрә.

Шул кабинетта Али әфәнде белән сөйләшеп утырдык.

Зур уңышларга ирешкән малкуарлар арасында тәкәббер кешеләр еш очрый. Ә менә Али Сөләйманов бик гади, аралашучан, саф күңелдән сөйләшүче ир булып чыкты. Шуңа күрә аның белән аралашып утыруы да үзенә бер сихәтлек өстәде.

**- Али әфәнде, икмәк заводында эшегез ничек башланып китте?**

- Үз вакытында мин бодай бизнесы белән шөгыльләндем. Бирегә он китерә идем. Аннан соң Аллаһы Тәгалә шушы заводның хуҗасы булырга насыйп итте. Моны мин Ходай бүләге, дип саныйм.

Ул вакытта миңа 26 яшь иде. Идел буенда мин бердәнбер шундый яшь җитәкче булдым. Шул рәвешле минем турында гәҗитәгә дә яздылар.

**- Завод хуҗасы булгач, үзгәрешләр кертергә туры килдеме?**

- Әйе, башта җиһазларны алмаштырдым. Шулай ук өстәмә эшчеләр алдым.

Хәзер безнең өлкә буенча элеваторлар, тегермәннәребез бар.

**- Көненә ничә тонна ипи пешерелә?**

- Көн саен 17 тонна ипи һәм 20 тоннага якын кондитер ризыклары: прәнекләр, тортлар, печенье, чәкчәк, крендел пешерәбез, мармелад та ясыйбыз.

**- Тауарларыгыз кайларга тарала?**

- Бөтен Россия буенча тарала. Мәскәү, Ульян, Сарытау, Волгоград шәһәрләрендә. Башкортостан, Татарстан, Мордовия Республикаларында сатыла. Күптән түгел ашамлыкларыбызны Кавказга да җибәрә башладык.

"Магнит", "Пятерочка" кибетләрендә безнең ризыклар күпләп сатыла.

**- Али әфәнде, нәкъ менә Сезнең заводта пешерелгән чикләвек торты гына элеккеге еллардагы тәмен саклап калган. Аны ашаганда балачак искә төшә.**

- Әйе, бу, чыннан да, шулай. Бер таныш түрә дә миңа: “Али Мусеевич, кызыксынып, Сезнең тортны лабораториядә тикшердек. Башкаларныкына караганда, аңарда химик матдәләр бик аз”, - диде. Гомумән, миңа җитештергән ризыкларыбызның яхшы сыйфаты мөһим.

Самарда хәләл колбаса җитештерергә дә ниятлим, Аллаһы теләсә. Бүгенге көндә минем Ульян өлкәсендә шундый Австрия комплексы бар. Тиздән аны эшләтеп җибәрәчәкмен.

**- Елына ничә тонна он кулланасыз?**

- 10 мең тонна он кулланыла. Бездә он үзебезнеке. Өч тегермәнебез бар. Берсе – элеккеге еллардан калган, икесе - заманча тегермәннәр.

**- Кибетләрдә еш ялган арыш ипие сатыла. Белгечләр әйтүе буенча, “кара” ипинең пешерү технологиясе үзенчәлекле, һәм аны озак әчетеп пешерергә кирәк. Циклны кыскартыр өчен, химик матдәләр кушалар, дип сөйлиләр. Сездәге “кара” ипи элеккеге еллар стандарты буенча пешереләме?**

- Бу турыда горурланып, әйе, дип әйтә алам. Алда әйтеп үткәнемчә, завод җитәкчесе булгач та, мин биредәге җиһазларны яңаларга алмаштырдым, тик берсен генә калдырдым. Ул – 1933 елгы мич. Аны немецлар төзегән булган.

Әгәр бу мичтә ипине төрле химик матдәләр өстәп пешерсәң, ул килеп чыкмый. Без шундый тәҗрибә ясап карадык. Ягъни мич химик матдәләрне кабул итми! Шуңа күрә аңарда арыш ипие элеккеге еллар стандарты буенча пешерелә.

Без үзара бу икмәкне кара уылдык (икра), дип атап йөртәбез. Аңа тоз сибеп ашасаң, тәме уылдыкныкын хәтерләтә. Россиядә модный мич бездә генә бар.

**- Ә бу мичне ничек калдырырга булдыгыз?**

- Мин балачакта бик еш Самарга туганнарыма килеп йөри идем. Поездда авылга кайтканда тимер юлы вокзалы янында гына урнашкан бу заводтан арыш ипие сатып ала идем. Аны безнең авылда да бик яраттылар. Самарга йомыш белән баручылардан кешеләр: “Миңа Самар ипиен алып кайт әле”, - дип сорыйлар иде.

Үземә дә бу ипи бик ошады. Шушы вакытларда киләчәктә бу завод хуҗасы буласымны, әлбәттә, күз алдына да китермәдем! Шушы ипине балачактан яратканга күрә, бу мичне сүттермәдем.

Мин икмәк заводын башка урынга күчерергә телим. Һәм анда шушындый ук мич төзергә ниятлим.

**- Ә бу элеккеге мичнең үзенчәлеге нәрсәдә соң?**

- Ул кирпечтән төзелгән, ә заманча мичләр – металлдан.

Шөкер, безнең прәнекләр дә югары сыйфатлы. Аларны Пензада сата башлагач, андагы кешеләрнең прәнекнең элеккеге тәме булганга исләре киткән. Мәскәүдә безгә мондый тәмле прәнекләр башка беркайда да юк, диделәр. Чөнки Россиядә бик күп заводлар ябылды.

**- Сезнең кул астында ничә кеше эшли, һәм аларның ничә проценты ир-атлар?**

- Бездә 400 хезмәткәр. Ир-атлар 30 процент тәшкил итә.

**- Уртача эш хакы күпме?**

- 25 – 30 мең сум.

- Иң күп алучыларның хезмәт хакы?

- 120 мең алучылар да бар.

**- Ә иң түбән эш хакы?**

- Иң түбән эш хакын даими кайдадыр эшләп, бездә өстәмә хезмәт итүчеләр генә ала. Ул 10 – 12 мең сум тәшкил итә.

**- Барлыгы ничә цех?**

- Өч цехыбыз бар. Берсе – икмәк, икенчесе – кондитер ризыклары, өченчесе – вак ризыклар цехлары.

- Хезмәткәрләрегезнең туган көннәрендә бүләккә торт бирү каралганмы?

- Туган көннәрдә акчалата бүләк һәм торт бирәбез.

**- Эшчеләрегез арасында татарлар бармы?**

- Әйе, заводта татарлар да эшли. Күбесе вахта белән эшләп йөриләр. Пенза, Ульян өлкәләреннән, Татарстаннан, безнең Черкели авылынан килүче татарлар да бар.



*Али Сөләйманов, Евгений Примаков һәм Константин Титов.*



*Зур Черкели авылында үзе төзеткән мәчеттә.*

Алар атнасына 7 – 8 мең сум алалар. Ерактан килеп йөрүче эшчеләр өчен тулай торак та бар. Алар бик канәгать.

Заводка эшкә алган күп кешеләр әти-әниемә дә рәхмәтләрен белдерәләр.

**- Намаз укучылар өчен махсус бүлмә каралганмы?**

- Әйе, андыйлар гыйбадәтләрен махсус бүлмәдә кылалар. Мин үзем дә намаз укыйм, Аллага шөкер.

**- Ә намазлыкка күптән бастыгызмы?**

- Әле яшүсмер чагымда мәчеткә җомга намазларына йөри идем. Соңрак инде даими гыйбадәт кыла башладым. Зәкят тә түлим.

**- Намаз Сездә нинди хистойгылар тудыра?**

- Рухи көч бирә, авыр чакларда җиңеллек китерә.

**- Эш урыныгызда дусларыгыз бармы, әллә эшлекле мөнәсәбәтләр генәме?**

- Дусларым да бар. Бу - күбесенчә озак еллар бергә эшләгән кешеләр.

**- Сез дәһричелек (атеизм) чорын эләктергән кеше. Яшь вакытта дингә карашыгыз нинди иде?**



*Али әфәнде хатыны Мәрьям белән*



*Али Сөләйманов ветераннарны котлый.*



*Әти-әнисенең йорты һәм мәчет*

- Безнең гаилә һәрвакыт динле булды. Шуңа күрә кечкенәдән Исламга тартылып үстем һәм аңа карашымны беркайчан да үзгәртмәдем. Гомумән, безнең авылыбыз да дини. Нәселебездә муллалар булмаса да, дин ягыннан укымышлы кешеләр күп.

**- Ә өйләнгәндә булачак хатыныгызның дингә мөнәсәбәтенә игътибар иттегезме?**

- Хатыным Мәрьям белән без бер авылдан. Ул да дини, намазын да укый. Бергә 20 ел гомер итәбез.

**- Гаиләгез зурмы?**

- Олы кызым Әлфиягә 19 яшь тулачак. Икенчесе – Нурсинә "Яктылык" мәктәбендә 9нчы сыйныфта укый. Улым Гомәргә 14 яшь тулачак. Кечкенә кызым Камилә балалар бакчасына йөри. Аңа әле дүрт кенә яшь булачак. Шулай булгач – хатыным Герой-ана! (елмая).

**- Егетләр бик күп кызлар белән йөреп, берсен сайлап алалар. Сезне хатыныгызның нинди сыйфатлары җәлеп итте?**

- Аны бер күрүдә ошаттым. Беренче мизгелләрдә ягымлы елмаюы, чибәрлеге җәлеп итте. Аралаша башлагач, ашарга бик тәмле пешерүе дә ачыкланды. Танышкач, ике атнадан соң өйләнештек.

Хатынымнан бик канәгать мин. Балаларны да яхшы тәрбияли, яхшы пешерә дә. Үзе югары культуралы, замана белән бергә атлаучы хатын. Гаилә башлыгы буларак, минем фикеремне хөрмәт итә.

**- Ир-ат һәм эшкуар буларак, хәләл җефетегезнең өйдә генә утыруын өстен күрәсезме, әллә хатын эшләргә тиеш, дип саныйсызмы?**

- Гомумән, күп акчалы эшкуарларның хатыннары эшләмәскә тиеш, дип саныйм. Гәрчә мин хәләл җефетемә, үзе эшләргә теләсә, каршы килмим. Мәрьямнең матурлык салоны бар, тиздән ресторан ачарга торам. Аны да хатыныма бүләк итәргә ниятлим. Хәтта эшенә йөрер өчен машина да алып бирдем әле.

**- Нәселегездә малкуарлык белән шөгыльләнүчеләр тагын бармы?**

- Ике бертуган энем Равил белән Рәшит тә – эшмәкәрләр.

**- Өлкән бала буларак, энеләрегезне тәрбияләүдә катнашырга туры килдеме?**

- Әйе, кечкенәдән алар өчен җаваплылыкны тоеп үстем. Туганнарга һәрвакыт булышырга кирәк.

**- Әти-әниегезнең кайсы киңәшләре бәгырегезгә сеңеп калган?**

- Әтием Муса, әнием Асия - яхшы кешеләр. Бик яратам үзләрен. Алар безне гадел, намуслы булырга өйрәттеләр, лаеклы кешеләр итеп тәрбияләргә тырыштылар. Гомер буе хуплап, акыллы киңәшләр биреп торалар.

Әти-әнием дин юлыннан атлыйлар, 1997 елда, шөкер, хаҗ кылдылар.

Бер вакыйга истә калган. Әле Мордовиядә яшәгәндә бер дустымның велосипедын сорамыйча өйгә алып кайттым. Әнием шунда миңа кеше әйберенә беркайчан да тияргә ярамаганлыгын яхшылап аңлатты һәм велосипедны хуҗасына кайтарырга кушты. Бу минем өчен гомерлек сабак булды.

Авылга еш кына минем дусларым кунакка кайта. Әти-әнием аларны һәрвакыт якты йөз белән каршы алып, табын әзерлиләр, мунча ягалар. Алар - кунакчыл кешеләр.

Авылдашлары да әти-әниемне хөрмәт итәләр, шөкер, мәҗлесләрдән калдырмыйлар. Абруйлы кеше буларак, әтием мәчет эшләрендә актив катнаша.

Мин әти-әниемә бик рәхмәтлемен. Аларга нәрсә теләгәннәрен алып бирергә тырышам. Авылда үзләренә дүрт катлы өй салдым.

**- Самар татарларының киләчәген ничек күзаллыйсыз? Телебезне саклап кала алырбызмы?**

- Саклап калырбыз, инша Аллаһ. Татарлар күп. Араларында милли җанлылары да бар. Талип хәзрәт Яруллин, Илгиз Кәлүч, Шамил Баһаутдинов, Җәмил Вәлиуллин, Минәхмәт Хәлиуллов, Рифкать Хуҗин, Ильяс Шәкүров, Гомәр Батыршин, Ринат Сәйфетдинов кебек кешеләр булганда, татар милләте дә, ана телебез дә сакланачак, Аллаһы теләсә. Мондый кешеләрне һәрвакыт хуплап, аларның киңәшләренә «колак салырга» кирәк.

**- Башка милләтләр белән чагыштырганда, Самар татарлары нинди сыйфатлары белән аерылып торалар?**

- Гомумән, татарлар башка милләтләрдән кунакчыллыгы белән аерылып торалар, дип саныйм. Шулай ук тырышлык, уңганлык сыйфатларын атарга була.

**- Хыялыгыз бармы?**

- Самардан ерак түгел татар авылы салырга хыялланам.

***Бүгенге заман хатын-кызы нинди булырга тиеш, дип сорасалар, мин Камышлы районындагы Камышлы авылында яшәүче Җәмилә Мөхтәбәр кызы Мингалимова төсле була, дип җавап бирер идем. Ул, бер карыйсың, атыла торган вулкан төсле, икенче тапкыр күргәндә, җәйге акланда талгын җилдә тибрәнеп үсеп утыручы матур гөл-чәчкә...***

*Нурсинә Хәкимова. Денис авылы,*
*Шенталы районы*

# Ул, бер карыйсың, атыла торган вулкан төсле, икенче тапкыр күргәндә, матур гөл-чәчкә...



Минем аның белән танышуым бик кызык кына килеп чыкты.

Камышлыда үткәрелгән «Әйлән-бәйлән» фестиваленә баргач, Мәдәният Сараеның фойесында, ишек төбендә милли киемнәр киеп, бәйрәмгә килүчеләрне каршы алучы Җәмилә (мин аны Яңа Мансур авылы Сабан туенда мәйданга чыгып, биегән чагында күргән идем), янына килеп, концертка керергә кайда билет сатылганы турында сорадым. Үз исеме белән эндәшкәч, ул бераз аптырап, мине кайдан беләсез, сез кем буласыз, дигән сораулары белән күмеп ташлады. Мин кем булуым, ни эшләп йөрүем турында әйткәч, сөенечле күзләре белән бераз карап торды да, кочаклап алып: «И, Ходаем! Рәхмәт инде Сиңа! Күптән сезнең белән танышасым килеп: Я, Раббым! Нурсинәне үзең минем юлларыма чыгар инде, дип ялварган идем бит», дип әйтте. Менә шушы көннән соң без аның белән якыннан аралаша торган булып киттек тә инде.

Ә хәзер күп елларны атка чигәреп, Җәмиләнең балачак хатирәләрен, яшьлек елларын барлыйк әле!

Гаиләдә өченче бала булып, Камышлы районының Иске Ярмәк авылында гади колхозчылар гаиләсендә дөньяга килә ул. Аның олы абыйсы Җәүдәт сабый чагында вафат була, аннан соң Ильяс, Җәмилә үзе, энесе Илдар һәм сеңелләре Гамилә белән Илһамия гаиләне тулыландыра. Гаиләдә олы кыз булгач, аңа яшьли кул арасына керергә, әнкәсе Мәдинәгә булышырга туры килә. Ул вакытта заманы нинди булган бит әле! Бөтен хезмәт кул көче белән башкарылган вакыт буларак, иңенә көянтә-чиләк асып, елгадан су китерергә, туңып, боз астында калган елга кырыена басып, бәкедә, әнкәсенә керләр чайкашырга, өй җыештырырга да туры килә. Әбисе Фәхрикамал аны төрле кул эшләренә, аш-су серләренә, шул ук вакытта кыска догалар укырга да өйрәтә.

Ә җәйләрен Җәмилә ферма терлекләрен көтүче әтисе белән җәйләүдә көтү көтешә. Егетләрчә әче итеп сызгырырга, чыбыркы шартлатырга да шунда өйрәнә. Атка атланып, яисә арба уртасына басып, ут уйнатып, колакларында җил сызгыртып, урам уртасыннан чаптырып узган вакытта, авыл кешеләре ирексездән аңа борылып карыйлар һәм: «Ирдәүкә! Үсеп, җиткән кыз булгач, нинди булырсың икән?!» - дип әйтми түзә алмыйлар, ә кайберәүләре: «Булганнан барысы да була, менә дигән, тормыш алып баручы хатын-кыз булачак әле Җәмилә!» - дип өстәп куялар.

Өлкән сыйныфта, мәктәптә укыганда җәйге лагерьга баргач, аңа үзенә ат биреп, авылдан лагерьга азык-төлек ташучы итеп билгелиләр.

Тагын өстәп шуны да әйтәсе килә: ат җене кагылган кыз ямьле



Сабан туйларында ат чабышында катнашыр өчен көн саен яраткан атында җилдерә, шулай итеп, әзерлек алып бара. Ә билгеләнгән Сабан туе көне килеп җиткәч, аны ярышка җибәрмиләр, кыз бала бит син, егылып төшеп, имгәнеп куюың бар, дип әйтәләр. Бу эше барып чыкмаган үҗәт кыз, кышларын чаңгыда шуарга керешә. Әти-әнисе рөхсәт итмәгәч, кеше күрмәгәндә генә, чаңгыларын капка астыннан урамга төртеп чыгара да, тиз-тиз генә киенеп, урамга чыгып китә.

Менә шулай итеп, «иреккә чыккан Җәмилә» урманга китеп бара. Ә анда аны үзенең саф һавасы, тынычлыгы белән кышкы урман каршы ала. Кышкы урманның да бит үз тормышы, үз гаме, үз сере бар. Әйтерсең лә биредә Кыш бабай үз эзен калдырырга тырышкандай, агач кәүсәләрен энҗе-мәрҗән белән «бизәгән». Алар кояш нурында искиткеч матур, күзләрне чагылдырырлык булып ялтырыйлар! Әнә агачтан-агачка басып, тиен сикерә. Менә монда – аяк астында төрле киек эзләре сузылган. Ә Кардон исемле чишмә янына килеп бассаң, ул яртылаш кар белән күмелгән, җәйге көннәрдәгечә көчле итеп акмый, бераз тыныбрак, үз алдына әкрен генә, челтерәп агып ята. Шулай итеп, үзенең талгын җырлары белән табигать-Анабызга мәдхия җырлыйдыр төсле тоела. Табигатькә җаны-тәне белән гашыйк кыз урман-кырларны урап, данлыклы Юкәле тауда туйганчы чаңгыда шуыгач кына, өенә кайтырга кузгала.

Ә җәйләрен исә ул әнкәсе Мәдинә апа белән урман уртасында урнашкан җәйге фермага сыер саварга йөри. Яңа гына көтүдән кайткан сыерлар өстендә бөтерелгән кигәвен–черкиләр дә аны куркытмый. Әнкәсе ике сыер сауганчы, ул «әһ» та итми, биш сыерны савып та куя.

Бераз алга китеп әйтәм: «Без үскәндә тормыш бик авыр иде. Күп хыяллар, теләкләр тормышка ашмый калганда, үз-үземә: «Алдагы тормышымда мин бик матур итеп яшәячәкмен!», – дип, максат куйдым, – дип сөйли бүгенге көндә язмам герое.

Җәмиләнең мәктәптә укыган еллары матур вакыйгаларга бик бай. Ул төрле спорт ярышларында, җыр-бию, сәнгать өлкәсендә катнаша, укуда да сынатмый. Төрле җәмгыять эшләрендә дә читтә калмый. Аның яшүсмер еллары хезмәт белән үрелеп бара. Унынчы сыйныфка җиткәч, көзен басуда урып-җыю эшләре барганда, яшь кыз өлкән яшьтәге хатын-кызлар белән бергәләп, колхоз амбарлары янына икмәк бушатырга йөри. Ул вакытта колхоз тормышы белән авыл халкын таныштыру радио аша алып барыла торган була. Менә шул чагында хуҗалык җитәкчесе Эдуард Ганиев: «Авыл чибәре – Җәмилә матурлыгы белән генә түгел, эштә уңганлыгы, булдыклылыгы белән таң калдырырлык. Аны үстергән, дөрес тәрбия биргән әти-әнисенә зур рәхмәт!» - дип әйтә.

Менә шулай көн саен тормыш сиздерми дә үтеп кенә тора.

Авыл кызы Җәмилә үсеп, мәктәпне тәмамлап, Сергиевск районында мал табибы һөнәрен үзләштерә башлый.

Яшьлек үзенекен итәме, әллә үзе теләгән һөнәр үзләштерү файдасымы, Җәмилә тагын да матурланып, басынкы, сабыр холыклы кызга әйләнә. Күпмедер вакыт укыгач, ул практика үтәргә туган авылындагы колхозга кайта. Авыл фермасында мал табибы булып эшли башлый.

Ә җәйге кичләрне авыл өстендә гармун моңы агыла. Шундый матур төннәрнең берсендә, күктә бер-бер артлы йолдызлар кабынгач, Җәмилә авылдагы Мәдәният Сараена ашыга. Чөнки бүген бирегә Татарстанның Казан шәһәреннән Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары «Кыр казлары артыннан» исемле спектакле белән килгән булалар. Яшь кыз бирегә килеп кергәндә залда алма төшәрлек урын калмаган була.

Ләкин ул аптырап калмый, стена буенда басып торучы яшьләр төркеменә барып кушыла. Озак та үтми, сәхнәдә спектакль башлана. Биредә Ясминәнең (төп рольләрдә - Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар) авыр язмышы чагыла. Ул сөйгәне белән кавыша алмый, гомере буе әрнеп яши. Бичара Ясминә язмышын үзгәртә алмаудан ни кылырга да белмәгәч, утырып, күз яшьләре аша җырлый башлый:





*Кыр казлары артыннан*
*Биеклеккә тартылам.*
*Хыялыма китәр идем*
*Кыр казлары артыннан.*

Залда чебен очкан тавыш ишетелә. Тамашачы Ясминәгә кушылып яши, аның өчен борчыла, елый.

Билгеле, менә шушы вакытта Җәмилә дә төп героиняның язмышына битараф кала алмый, аның йөрәгендә сәхнәгә карата мәхәббәт уты кабына. Аның да шушы сәхнәдә кеше язмышларын чагылдырасы, матур образлар тудырасы килә башлый. Хәер, бу турыда соңрак...

Ә спектакльгә килгәндә, ул дәвам итә. Аның белән бергә яшь кызның кичерешләре дә дәвам итә.

Тик шул чагында, кемнеңдер үзенә текәлгән берөзлексез карашыннан кыз йокыдан уянып киткәндәй була. Ул аптырап якягына каранса, ни күрсен, аңардан ерак та түгел Искәндәр исемле авыл егете аңа гашыйк күзләрен тутырып карап тора. Аларның күз карашлары очраша... Ә кайтыр юлга чыккач, егет аның артыннан килә һәм үзен озатырга рөхсәт сорый. И, риза булмый димени Җәмилә! Чөнки аңарга да шушы егет ошап тора бит әле! Тик нигәдер, ул аны урамда очраткан саен оялудан бит алмалары кызара.

Менә шулай итеп, бер-берен ошатучы егет белән кызны чит күзләрдән сакларга тырышкандай, төн караңгылыгы үз пәрдәсе белән каплый.

Шушы көннән башлап, ике яшь йөрәк, айлы төннәрдә очрашып, алсу, матур таңнарны бергә каршылыйлар, матур хыял диңгезендә сәяхәт кылалар.

Санаулы вакыт бик тиз үтеп китә бит. Җәмиләнең практикасы тәмамланып, ул укырга китеп бара. Аларга бары тик ял вакытларында авылга кайткач кына очрашырга туры килә.

Ә бераздан соң, кыз укуын тәмамлап, авылга әйләнеп кайта. Ял итәргә туры килми, чөнки Искәндәр Җәмиләгә тәкъдим ясый.

Яшьләрнең туйлары бик матур, күңелле үтә. Искәндәр бу вакытта Камышлыда машина йөртүче булып эшли торган була. Җәмилә дә биредә инкубаторда эшләп, декрет ялына чыга. Озакламый аларның кызлары Гүзәлия гаилә тормышын тулыландыра. Бәхет өстенә нур өстәп, дүрт елдан соң, Җәмилә тагын бәбигә уза. Ул вакытта Камышлыда «Мир» колхозының гөрләп торган чагы, Искәндәрне бирегә механизатор итеп эшкә алалар. Аллаһының рәхмәте, икенче балалары Илнар дөньяга килгәч, яшь гаиләгә фатир бирелә. Тормыш үз җаена әкрен генә ага бирә. Тик шунысы бар, шатлык белән борчу янәшә йөри, дигән сүзләр бик тә дөрес икән. Искәндәр эш урынында күзен авырттыра. Аңа катлаулы операция кичерергә туры килә. Соңыннан Искәндәргә өченче төркем инвалиды, дигән кәгазь бирелә.

Ул хастаханәдә дәваланып ятканда, ир йөрәкле Җәмилә елап утырмый, хәләле белән төзи башлаган мунчаны өлгертеп куя, аңа бары тик мич чыгарасы гына калган була. Менә шулай итеп, тормыш үз көенә төшеп, әкрен генә ага башлый. Озакламый Җәмилә социаль хезмәткәр булып эшкә урнаша. Бүлек җитәкчесе итеп билгеләнгәч, курсларда белемен күтәрә.

«Мин биредә 25 ел эшләү дәверендә Камышлы районындагы бөтен авыл кешеләре белән таныш. Әгәр дә минән кем ярдәмгә мохтаҗ, дип килеп сорасалар, әһ тә итми, шундук әйтеп бирәм. Чөнки мин үземә беркетелгән кешеләр язмышы белән яшим, алар өчен борчылам, алар бәхетле булсалар, мин дә бәхетле», - дип сөйләде миңа Җәмилә ханым. Аның тырыш хезмәте район хакимияте, Самар губерна Думасы тарафларыннан бихисап мактау кәгазьләре һәм рәхмәт хатлары белән бәяләнгән.

Шушы ханымның тагын башка төрле асыл сыйфатлары бар. Уд ярдәмчесез, ялгыз калган өлкәннәрне картлар йортына, өлкә хастаханәсенә дәваланырга илтеп, урнаштырып кайткан. Ә Бөек Ватан сугышы елларында фашист концлагерында газап чиккән, шунда яраланган Шамил ага Гарифуллинга тиешле ташламалар, пенсия ясаткан.

Җәмиләнең тагын кызык яклары бар. Ир яки хатын эзләүчеләр аңа килеп, тиң ярларын табуда ярдәм итүен үтенәләр икән. Шулай итеп, аңа башкода ролен дә үтәргә туры килгәли.

Тагын шуны искәртеп үтәсе килә: ул эштән кайтып барганда берәү эчеп, исереп, өенә кайта алмый урамда егылып ята икән, йомшак бәгырьле хатын аны кызганып, җилкәсенә күтәреп сала һәм гаиләсе янына, үз өенә кайтарып куя. Бу турыда сөйләшеп утырганда, язмам герое: «Ярый әле, Искәндәрем көнче кеше түгел», - дип көлде.

Җәмилә белән сөйләшеп утырганда ул мине кунак бүлмәсенә алып керде дә, киштәләргә тезелеп куелган бүләкләргә күрсәтеп:

– Менә болар барысы да Искәндәрем белән төрле чараларда, өлкә һәм районда үткәрелгән спорт ярышларында катнашып алган бүләкләр, - диде горурланып.

Я, Сөбханалла!Ниләр генә юк биредә!

– Искәндәр белән спорт ярышына барырга җыенгач, күрсәң иде безнең шатлыгыбызны! – дип дәвам итә Җәмилә Мөхтәбәр кызы. – Бер ай алдан чемоданыбызны ту-

тырып куябыз да, өзелеп, көннәрне санап көтәбез. Менә шулай итеп, тормышның кызыгын, матурлыгын тоеп яшибез без. Әгәр дә ул миннән башка катнашырга китсә, мин аңа уңышлар теләп, хәер-дога кылып, аның кайтуын түземсезлек белән көтеп торам, - дип тә өсти әңгәмәдәшем.

Дөрестән дә, Мингалимовлар гаиләсе спортка гашыйк. Җәмилә ханым ире Искәндәр белән беррәттән чаңгы ярышында,





йөзү, ату, йөгерүдә һәм күп спорт төрләрендә үзен күрсәтергә ярата. Тагын шунысын сер итеп әйтәм, аның куллары бик көчле, ул кул көрәше ярышында, ямьле Сабан туйларында гер күтәреп, призлы урыннар яулаган хатын –кыз да бит әле. Ул волонтёрлыктан да баш тартмый. Газеталарга мәкаләләр яза. Камышлы авылы поселениесендә музей төзүдә зур өлеш керткән кеше буларак та билгеле. Өстәвенә, «Авыл хуҗабикәсе» акциясендә катнашып, диплом һәм бүләкләр алган, үзе төшергән рәсемнәре белән Самар шәһәрендә уткәрелгән «Һәр кешедә спорт яши!» дип исемләнгән фотокүргәзмәдә катнашып, призлы урынга лаек, дип табылган.

Мин Җәмилә ханымнан:

– Бу тиклем һөнәрләрең күп булгач, машина йөртәсеңме соң? – дип сорадым.

– Юк, машина йөртергә өйрәнә алмадым. Без үскәндә машина юк иде. Ирем эчми-тартмый. Рульдә ул йөри. Ә мин хәзер дә атка атланып җилдерергә яратам.

Искәндәр Сәйфулла улы турында сүз чыккач, аның турында берничә сүз әйтеп узасым килә. Ул мәчеттә мәхәллә рәисе, мәет юып йөрүче, мәчетне җыештырып, мичен карап, аны җылытып торучы, җәйләрен мәчет бакчасын чүп-чардан арындырып торучы да бит әле.

Язмамны дәвам итеп, Җәмиләнең тагын бер Ирдәүкәлеген әйтеп үтми ярамас. Беркөнне эштән арып кайтып, ял итәргә яткач, ул сикереп торып утыра да:

– Искәндәр! Әйдә, җаным, өряңа өй салабыз! – дип ярып сала. Ә хәләле:

– Кит инде, Җәмилә, безнең фатирыбыз бар бит, нигә безгә яңа өй?

– Минем матур итеп яшисем, үземнең җир кишәрлегемдә гөлләр үстерәсем килә, - дип үзсүзләнә хатыны. Я, Хода! Мондый тәвәккәл хатын-кызны кем генә җиңә алыр икән соң?! Иртән таң атуга, Җәмилә авыл поселениесенә ашыга. Ул биредә урманнан үзләренә делянка бүлеп бирүләрен үтенә. Ә икенче көнне ире белән урман кисәргә китеп бара. Ир белән хатын көне буе бертуктамый кул пычкысы белән агач кисәләр. Көн азагында болар янына алардан ерак та түгел «Дружба» белән агач кискән ике ир кеше киләләр дә, үз күзебез белән күрергә килдек, чалбар кигән, башына яулык бәйләгән кеше ир-атмы, әллә хатын-кыз затыннанмы икән? – дип сорыйлар.

Алар Җәмиләне күргәч, чак егылып китмиләр.

– Бар, сеңелем, аяктан егылганчы ят, ял ит, арыгансыңдыр, өстәвенә, көне дә бик кызу булды, диләр, аны кызганып. Бу сүзләргә каршы Җәмилә кычкырып көлә генә. Ә Искәндәр:

- Сез мине кызганыгыз, мин арый башладым. Ә хатынымның тагын бер урман кисәрлек көчкуәте бар әле, - дип җавап бирә.

Сүз уңаеннан әйтеп китим әле: мин шушы гаиләнең үз көчләре белән төзегән өйләрендә булып, сокланмый кала алмадым. Картлар әйтмешли: җыры да, көе дә килгән, дип әйтер идем.

– Акча чыгарып тормадык, үз кулларыбыз белән төзедек, - дип аңлаттылар алар мине өйләре белән таныштырып йөргәндә.

Менә, ниһаять, төп темага килеп җиттем бугай. Алдарак, Җәмиләнең яшьлек еллары турында язганда, сүзем сәхнә тирәсендә тукталып калган иде.

Мингалимовлар гаиләсе тормыш диңгезендә генә түгел, сәхнә тормышында да йөзәргә осталар. Чөнки сәхнәдән башка, Камышлы авылы халык театрында матур образлар тудырмыйча, җир йөзендә яшәүне күз алдына да китерә алмыйлар. Озакламый алар Самар шәһәрендә Бөек Җиңү көнендә уткәреләчәк «Җиңү Салюты» дип аталган бәйрәм тантанасында Кләүле районындагы начар күрүче инвалидлар оешмасы белән берлектә Гогольның «Ревизор» исемле пьесасыннан өзек тәкъдим итәргә җыеналар. Ә хәзер вакытны берничә ел артка кичектереп, шушы матур гаиләнең театрда нинди сәнгать җимешләре тудырулары турында якты, матур истәлекләрне искә алып үтәсе килә.

Алар Әнгам Әтнабаевның «Законлы никах белән» исемле ике пәрдәле комедиясендә зур осталык белән уйнап, тамашачы күңеленә тирән эз салалар һәм гомерлеккә!

Аннан соң язучы, драматург Данил Сәлиховның «Язмыш» дип аталган драмасында Җәмилә - Зәмзәмия, Искәндәр – Насыйб, уллары Илнар – Сәер кеше рольләрен аеруча бер мавыгу белән уйныйлар.

Биредә Җәмилә – Зәмзәмия үз ролен тулысынча ачып бетереп, кайгы-хәсрәт диңгезендә йөзгән, бераз кырысрак булса да, мәхәббәтен саклап кала алган хатын-кыз, ана ролен тамашачы йөрәгенә үтеп керерлек итеп башкарган.

Аннан соң алар «Мөгез», «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Ул кайтты» исемле пьесаларда рольләрен югары биеклектә уйныйлар.

Соңгысында Җәмилә Җиһания ролен бик бирелеп уйный. Биредә аның ире фронтта. Ул аны өзелеп көтә. Хәтта төшләрендә күрә сөйгәнен. Сагынуына түзә алмый Җиһания (Җәмилә) тамашачыга карап:ул барыбер исән-сау кайтачак, дип әйтә һәм кычкырып елап җибәрә. Нәкъ шушы вакытта тамашачы белән оста артистка арасында бер-берен аңлауга китергән дуслык күпере, элемтә барлыкка килә дә инде. Тамашачы Җиһаниягә (Җәмиләгә) кушылып елый, аның кайгысын йөрәк аша үткәрә, аның белән бергә сулый, ире исән-имин кайтасына зур өметләр баглый. Менә шулай итеп, олы йөрәкле, оста артистка тамашачысын үз йөрәгенә бәйли.

Искәндәргә килгәндә, Э. Альтның «Сукыр» дип исемләнгән пьесасы аның шәхси тормышыннан алынып язылган төсле. Дөньяда яшәү дәверендә күзләре буенча инвалидлыкка чыккач, ул биредә кара күзлек кигән, таякка таянган сукыр ролен бик оста башкара. Репетиция тәмамланып, өйгә кайтырга чыккач, ул хәләл җефете Җәмиләгә: мин бу образны ничек уйнармын инде, дип, үзенең борчылуы турында әйтә. Ә премьера башланып, уйный торгач, шулхәтле мавыгып китә, әйтерсең лә ул бөтен нәрсәне кабат кичерә, актыктан ихлас күңелдән елап җибәрә, ә тамашачысы аны үзенең көчле алкышлары белән биеклеккә күтәрә, яшәргә зур көч бүләк итә...

Аның чын тормышта яшәгәндә төпле гаиләсе, чын, саф мәхәббәт белән өзелеп сөюче Җәмиләсе–бәгырькәе барлыгын исбатлый сыман тоела.

Җәмилә Мөхтәбәр кызы - сәхнәдә төрле образлар тудырырга сәләтле артистка. Менә ул драматург Фоат Садриевның «Безнең авыл кызлары» дип аталган пьесасында Гайшә ролендә. Ул биредә сугыш елларында хатын-кызларның авыр хезмәткә, кайгы-хәсрәтләргә, ачлыкка, суыкка түзеп, Бөек Җиңүне якынайтыр өчен күп көч түгүләрен чагылдырган. Өйдәге сабый балаларын кызганып, бер уч ашлык урлап тотылып, кечкенә күкрәк сабые хакында гына төрмәдән котылып калуны ачык итеп чагылдырып бирә алган.

Мин бергә сөйләшеп утырганда Искәндәр Сәйфулла улыннан:



– Сәхнәдә төрле образлар чагылдыручы артистка. Бер карыйсың, ул атыла торган вулкан төсле, икенче тапкыр күргәндә, гөл-чәчкә сыман. Тормышта нинди хатын-кыз соң ул – Җәмилә?! Аңарга ышанып буламы? – дип сорамыйча кала алмадым.

– Әйе. Мин Җәмиләмне бик яратып, хөрмәт итеп яшим. Минем сөекле хатыным булса, балаларыбызга хөрмәтле әни, оныгыбыз Дианага яраткан әби дә әле ул. Мин аның миңа, балаларыбызга беркайчан да хыянәт итә алмасына ышанам. Ул үлгәндә дә тугрылык саклап кала торган кеше. 30 елдан артык гомер итү дәверендә Җәмиләмоны бер генә мәртәбә түгел, озак еллар буена раслап күрсәтте инде.

Ә хәзер Җәмилә ханымның үзеннән сөйләтеп карыйк әле. Ул үзе ни әйтер, тормышыннан канәгатьме икән соң?

– Мин җәннәт почмагыдай боргаланып аккан Сок елгасы, данлыклы Юкәле тавы янында урнашкан Иске Ярмәк авылында туып-үстем. Без үскәндә тормыш бик җиңел булмады. Сок елгасыннан көненә ун көянтә су китерә идем. Кечкенәдән гармунда уйнарга өйрәнү - зур теләгем иде. Кызганычка, акча җитмәү сәбәпле, бу хыялым тормышка ашмый калды. Шулай булса да, югалып калмадым, болында көтү көтеп йөргәндә, егетләрчә, ике бармагымны авызга кабып, сызгырырга булса да өйрәндем. Сабый чагымда Аллаһы Тәгаләдән тормыш диңгезендә йөзәргә мин яраткан, мине яратучы, тәртипле авыл егетен сорадым. Исәнлектә, муллыкта, бәхетле тормышта яшәп, сабый балалар тудырып үстерергә язсын иде, дип теләдем. Белгәнегезчә, Аллаһ Раббыбыз теләкләремне кабул иткәндер, дип уйлыйм.

Фатирыбыз бар өстенә, бик матур өй салдык, агачлар утырттык. Машинабыз да бар. Тормышыбыз җитеш.

Бүгенге көндә сөйгәнем белән кулга-кул тотынып, тормыш юлыннан янәшә атлыйбыз. Авырлыкны урталайга бүлеп, шатлыклар кичереп яшибез. Балаларыбыз үсеп җиттеләр инде. Улыбыз Илнар белән кызыбыз Самар шәһәрендә педагогик һөнәр үзләштерделәр.

Хәзерге вакытта кызыбыз Гүзәлия киявебез Радмир белән Себернең кырыс һава шартларына карамастан, кызлары Диананы тәрбиялилиләр. Оныгыбыз беренче сыйныфта укып, гимнастика бүлегендә шөгыльләнә. Ә улыбыз Илнар Тольятти шәһәрендә яши.

Менә инде Җәмилә Мөхтәбәр кызы турындагы язмамны төгәлләргә вакыт килеп тә җитте.

Мин аны Шамил ага Баһаутдин сүзләре белән тәмамлыйсым килә. Ул 2005 елда болай дип язган булган: «Социализм чорында: «Комсомолка, спортсменка, красавица», - дигән әйтем бар иде. Җәмилә ханым - нәкъ шундый кеше. Спортның төрле өлкәсендә катнашучы, суган үстерү остасы, сыер савучы, мәкаләләр язучы.Менә шундый сыйфатларга ия булган кызны бик тә игътибарлы, акыллы һәм хәйләкәр егетләр күзе генә күрә белә. Мөхтәбәр кызының һәр күзәнәгеннән нур бөрки, һәр буыны шатлык чыганагы, күзләрендә дәрт, йөзендә канәгатьлек. Ул Камышлы авылы Халык театры артисткасы. Аңардагы талант, темперамент иксез-чиксез. Җәмилә - мескен хатыннан алып, бөек татар хатын-кызы Сөембикәне уйнарлык артистка!»

***Февральдә кайнар йөрәкле милләтпәрвәр, динпәрвәр, ватанпәрвәр Таһир ага Мамышевка 86 яшь тулды. Шөкер, олы яшенә карамастан, ул хәзер дә хәрбиләрчә төз гәүдәле, ачык карашлы, аек фикерле, саф зиһенле булып кала. Әлеге сыйфатлар аның заман сулышы белән яшәвенә ачык дәлил һәм ишарә.***

*Римма НУРЕТДИНОВА*



# ИЛГӘ, ДИНГӘ ҺӘМ МИЛЛӘТКӘ ТУГРЫЛЫКЛЫ ХЕЗМӘТ

### Үз чорының кыенлыкларын тулысынча кичергән ир

Таһир Гобәйдулла улы Мамышев 1928 елның 10 февралендә Похвистнево районы Мәчәләй авылында имам Гобәйдулла хәзрәт һәм Фатыйма абыстай гаиләсендә дөньяга килеп, җиде бала арасында үсә. Ачлы-туклы балачак, тетрәндергеч сугыш еллары да аның белемгә омтылуына киртә була алмый. 1942 елда җиденче сыйныфны тәмамлап, Камышлы педучилищесына укыга керә. Ул чор турында ул болай дип искә ала: *«Көндезләрен укып, төннәрен ярым ач килеш керосин лампасы яктысында ашлык суктырып, авыр эшләр башкарып яшәдек».*

1945 елда Камышлы педагогия училищесын тәмамлап, 1948 елга кадәр, Совет Армиясенә хезмәткә алынганчы, мәктәптә эшли. Аннан Вольск хәрби авиамеханиклар мәктәбен, Васильевск авиаучилищесын, Харьковның политехник институтын тәмамлый.



***1947 елда Мәчәләй авылында Сабан туена сөлге җыйганда. Таһир Мамышев – уңда.***

Советлар чорындагы җәлладлар бик сирәк нәселләрне урап үткән, билгеле. Таһир бабайның атасы да, гомере буена дингә тугрылыклы хезмәт иткән имам буларак, репрессия корбанына әверелгән. Большевизмның «усал җиле» аның улы Таһирга да кагыла. Әтисенең хөкем ителүе аңа тормыш юлында үтә алмаслык киртәгә әйләнә. Хәрби академиягә кергәндә аны мандат комиссиясе үткәрми.

Шуңа да карамастан, кайнар йөрәкле илпәрвәр буларак, Таһир ага 30 ел дәвамында Украина җирләрендә короллы көчләрнең төп терәге булган авиация-ракета системаларына хезмәт күрсәтә. Төпле белеме белән бергә аңа югары дәрәҗәдәге әхлак тәрбиясе дә даими ярдәм итеп тора.

1982 елда гына ул гаиләсе белән Куйбышевка әйләнеп кайта. 1983 елдан 1995 елга кадәр Таһир ага Мамышев хәрби хезмәтен майор-инженер дәрәҗәсендә Куйбышевның «Прогресс» заво-



*Имам Гобәйдулла хәзрәт һәм Фатыйма абыстай Мамышевлар балалары белән. Таһир – икенче рәттә.*

дында дәвам итә.

Армия сафларында тырышып хезмәт иткәне өчен ул орден-медальләргә лаек була. Сугышсыз чорда «Кызыл йолдыз» ордены белән бүләкләнү - гадәттән тыш сирәк була торган вакыйга. Хәрби хезмәттә инженер-майор дәрәҗәсендә Таһир ага Мамышевка менә шундый югары хөкүмәт бүләге тапшырыла.

Өлкә профсоюзлары тарафыннан «Иң оста рационализатор» дип танылa, рационализаторлык өлкәсендәге казанышлары өчен Халык хуҗалыгы уңышлары күргәзмәсе (ВДНХ) бүләкләренә ия була. СССРның кораллы көчләрендә уңышлы хезмәте өчен «Фидакарь хәрби хезмәт өчен» медальләренең өченче һәм икенче дәрәҗәлеләре белән бүләкләнә.

## «Олы бүләк итеп сине миңа бер Ходаем үзе биргәндер»

Әлбәттә, Таһир бабай белән бергә күчмә хәрби тормыш авырлыкларын хәләл җефете Наилә әби кичерә.

*«Олы бүләк итеп сине миңа бер Ходаем үзе биргәндер»,* - дип ягымлы итеп эндәшә Таһир бабай тормыш иптәшенә. *«Хатыныннымның түземлеге аркасында гына бар көчемне хезмәтемә бирә алдым»,* - дип сөйли ул башкаларга.

Наилә ханым 1929 елның 19 гыйнварында Похвистнево районының Гали авылында Мөхәммәтсафа һәм Минҗиһан Мостафиннар гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга аваз сала. Сигез бала арасында үсә. Авылның урта мәктәбен тәмамлагач, Камышлы татар педагогия училищесында белем ала, аннан соң Шенталы районының Денис авылында укытучы булып эшли. Нәкъ шул елларда яшь лейтенант Таһир чибәр укытучы Наиләгә гашыйк була да инде. Озак та үтми, 1951 елның 24 апрелендә, алар никах укытып, язылышалар.



*Таһир Мамышев гаиләсе белән. 1973 ел.*

Гаилә башлыгы кайда - аның тормыш иптәше дә шунда була. Төрле хәрби частьләргә күчеп йөргәндә, Наилә ханым алар каршындагы редакцияләрдә эшли, гаиләдә өч бала тәрбияләп үстерә һәм аларның белем алуда яхшы билгеләргә укуларына, тәртипле, әдәпле булып үсүләренә бик зур әһәмият бирә.

Әле күптән түгел генә, 2014 елның гыйнварында, Наилә әби үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үткән. Тугызынчы дистәсен тутырып килсә дә, ул искиткеч ягымлы, көр күңелле булып кала, туган-тумачалары һәм иксез-чиксез дус-ишләре белән аралашып, тәмле-томнар пешереп, яшәлгән елларын канәгать, шөкер итеп искә ала.

## Таһир Мамышев - ил сакчылар нәселенең башлыгы

Таһир Гобәйдулла улы һәм Наилә Сафа кызы Мамышевлар шәфкатьле һәм ата-анага рәхмәтле балалар тәрбияләп үстергәннәр.

Таһир бабайның зур горурлыгы - үзенең эшен дәвам иткән уллары һәм оныклары. Олы улы Наил хәрби инженерлар командалык училищесын тәмамлап, хезмәтендә подполковник дәрәҗәсенә ирешә. Кече улы Рафаил да хәрби училище тәмамлаган. Бүгенге көндә ул майор дәрәҗәсендәге электроника һәм радиотехник белгече. Оныклары Илгиз - капитан, Ринат өлкән лейтенант дәрәҗәсендә хезмәт итәләр.

Мамышевларның кызлары Нәҗия әти-әнисенең беренче һөнәрләрен дәвам итеп, укытучы булып эшли, оныклары Алия – икътисад белгече.

Биш оныкчыкларын тәрбияләп үстерүдә дә әби-бабайның йогынтысы бик зур.

## Мәчет кысаларындагы ватанпәрвәрлек

Таһир аганың яшьлеге хәрби хезмәткә бирелеп, Украина җирләрендә узганга күрә, татар дөньясыннан ераграк була.

Әмма ул күп еллар туган җирен сагынып, татар сүзен ишетергә сусап яши. Ә инде Куйбышевка әйләнеп кайткач, мөселман мохитына тартыла.



*Таһир Мамышев гаиләсе белән: Рафаил (сулдан уңга), Таһир, Нәҗия, Наилә, Наил. 1996 ел.*



*Таһир һәм Наилә Мамышевлар.*



*«Россия патриоты» исемле медаль белән бүләкләнгәндә.*



*«Яктылык» мәктәбендә укучылар белән очрашканда.*



*Кызлары Нәҗия әти-әнисен теплоходта Казанга һәм Шәһри Болгарга алып барган.*

Гаскәр тәртибенә күнеккән ир динебез Ислам таләпләрен йөрәге белән кабул итә.

- *Коръән укырга өйрәнергә беркайчан да соң түгел икән. Алтмыш яшемдә мәдрәсә каршындагы якшәмбе мәктәбенә укырга килдем. Биредә биш ел Ислам нигезләрен үзләштердем.*

*Әтиемнең хаҗга бару теләге бик зур булса да, ул бу бәхеткә ирешә алмады. Ә менә миңа, шөкер, бу изге сәфәр 65 яшемдә насыйп булды,* - дип сөйли Таһир бабай.

Таһир әфәнде инде күп еллар Самар өлкәсе мөселманнарының Диния нәзарәтендә хезмәт итә, бүгенге көндә ул - мөфтият каршындагы ветераннар шурасының рәисе.

Самар Җәмигъ мәчетендә ул - дәрәҗәле кешеләрнең берсе. Аның фикеренә колак салалар, чөнки, офицер кеше буларак, Таһир Мамышев беркайчан да ашыгып карар кылмас, ә инде сүзенең төбендә хакыйкать, дөреслек, изге ният булыр.

Берничә ел элек Таһир бабай җәмәгатьчелек эшендә актив катнашканы өчен «Россия патриоты» исемле медаль белән дә бүләкләнгән иде. Әйе, ул моңа лаек шәхес, аның эшчәнлегенә исең-акылың китәр. Мәдрәсә төзелешендә дә катнашкан, төзелеш тәмамлангач, комендант вазыйфасын да үтәгән. Кирәк-яракларын туплауга, ашханәне җиһазлауга һәм башка күптөрле хуҗалык эшләрен башкаруга көч куйган.

Соңгы елларда ул Җиңү көннәрендә ветераннарның очрашуларын оештыра. Инвалидларга, интернатларга, балалар йортларына ярдәм итүне күздән ычкындырмый. Хәзрәтләр белән бергә солдатлар присяга кабул иткән җирдә катнаша. Хәрби частьләрдә мөселман солдатлары, «Яктылык» мәктәбендә укучылар белән очрашуларга бара. Татар авылларында йөреп, мәдрәсәдә укыр өчен шәкертләр сайлый.

Самардагы «Ватанны яклаучыларны мәңгеләштерү» төркеменең әгъзасы буларак, яшьләргә патриотик тәрбия бирүдә күп көч куя.

- *Күптән түгел мин Самар юридик институтында әлеге уку йортының курсантлары белән очраштым. Алар арасында 160 мөселман егетләре укый икән. Чыгышымны: «Әссәламегаләйкем», дип башлаган идем, шушы 160 курсант сикереп торып, бертавыштан: «Вәгаләйкем әссәлам!»* - дип җавап кайтармасыннармы!

- *Бу күренеш, әлбәттә, бер үк вакытта мөселман яшьләренең бердәмлеген, әдәплелеген, тәртиплелеген күрсәтте, һәм мине бик дулкынландырды. Мондый очрашулар яшьләрне берләштерсә, олы яшьтәгеләрне шатландыра,* – дип сөйли Таһир ага Мамышев яшьләнгән күзләрен сөртеп.

## Бәхетле, гыйбрәтле тормыш

Таһир бабай белән Наилә әби Мамышевларның гаиләсендә татулык, мәрхәмәтлелек хөкем сөрә. Быел аларның гаилә корып җибәрүләренә 63 ел була икән инде. *«Кай арада узып киткән ул еллар? Сизми дә калганбыз. Югыйсә, барысы да бүгенгедәй генә кебек»,* – диләр Мамышевлар. Әйе, Сөбеханаллаһ диярлек гомер шул бу.

Өч ел элек җәүһәр туйларын бәйрәм итүче Таһир бабай белән Наилә әбигә Самар өлкәсе губернаторы Владимир Артяков тарафыннан гаилә йолаларын пропагандалауга зур өлеш керткән өчен Рәхмәт хаты да тапшырылган иде. Мондый игътибар күрсәтүгә юбилярларның ихлас шатланганнары истә әле дә.

Олы яшьтә булсалар да, Мамышевлар үзләрен бик әйбәт хис итәләр, сәяхәт итәргә яраталар. Соңгы елларда кызлары Нәҗия аларны теплоходта Казанга һәм Шәһри Болгарга алып барган. Таһир ага белән Наилә әби Кол Шәриф мәчетендә намазларын укып, Казан Кремлендә һәм башка тарихи истәлекле урыннарда булганнар, болгар бабаларыбыз рухына догалар кылып кайтканнар.

Таһир ага Мамышев үзен бик бәхетле дип саный һәм аны болай бәяли: *«Мин үз хезмәтемнең җимешен татыйм. Гаиләмне, матур өй корган кебек, төзергә тырыштым. Шуңа да, шөкер, ул нык та, якты да, иркен суларлык та, ышанычлы да булды. Һәркем нәкъ гаиләнең бәхет ачкычы булуына төшенсә иде».*

Минемчә, Таһир әфәнде - үз нәселе өчен генә түгел, Самар татарларына да үрнәк булырдай шәхес. Аның тормыш юлы халкыбызның ихтирамына лаек.

Таһир бабай белән Наилә әби Мамышевларга алга таба да бәрәкәтле тормыш, сихәтлек, зиһен сафлыгы һәм оныклар куанычын татып яшәргә язсын иде, дигән теләктә калам.

*Большую часть XX века трудился в органах безопасности, расположенных в Поволжском регионе, Абдурахман Абубакирович Козлов. Поскольку его имя-отчество непросто было произнести из-за почти полного их созвучия в начале и обилия букв, коллеги по работе звали его Алексеем Федоровичем. В годы Великой Отечественной войны он жил в Татарской АССР и занимался обеспечением военных перевозок, состоя в штате отдела внутренних дел. Затем перешел в структуру НКВД и находился на оперативной работе в Куйбышевской области. Когда был создан 5-й отдел (борьба с идеологическими диверсиями противника) Абдурахман был переведен в его состав.*

*Рашид Шакиров*

# Основатель уникального музея



*А.А. Козлов в начале служебного пути*

Потом подполковник Козлов возглавил секретариат областного Управления. В этой должности он принимал участие в подготовке ответственных документов, наиболее выпукло продемонстрировав свою грамотность, пунктуальность и ответственность. Речь Абдурахмана Абубакировича была неторопливой, вдумчивой и украшенной национальной мягкостью говора. Владел он и татарским языком, не забывал родные напевы.

Как руководитель секретариата, Козлов часто встречался с начальником Управления генералом И.П. Кинаровым, и как-то однажды у них возникла мысль создать чекистский кабинет. Вскоре, в конце 70-х годов, он появился. Сначала это был своеобразный читальный зал, где сотрудники знакомились с секретными документами и закрытой литературой. Но постепенно он стал трансформироваться в музейную комнату, поскольку ветераны госбезопасности начали приносить сюда свои награды, интересные материалы и предметы. В это время на экраны телевидения вышел фильм «Тревожные ночи в Самаре» – о борьбе местных чекистов с контрреволюцией в начальные годы Советской власти. Практически это первый многосерийный телефильм в стране о чекистской работе. А консультировал молодых авторов сценария Абдурахман Козлов.

Его идея превращения чекистского кабинета в музей нашла поддержку у нового начальника УКГБ генерала В.С. Гузика. Были заказаны эскизы оформления музея, и вскоре они реализовались в металле, стекле и пластике. Большинство документальных материалов для стендов и витражей добыл Абдурахман Абубакирович, много времени проведший в различных архивах, в том числе центральном архиве КГБ, расположенном в Москве. Благодаря ему чекистская работа с 1918 года и до конца Великой Отечественной войны была представлена без временных пробелов, что оценили сотрудники, знакомясь с экспозицией.

Кроме осмотра выставленных материалов и предметов в музее начали проводить церемонии принятия присяги сотрудниками и другие торжественные мероприятия, носившие закрытый характер.

А 23 февраля 1979 года состоялось официальное открытие му-



*А. А. Козлов, слева, и С. Г. Хумарьян в музее УФСБ*

зея истории УФСБ по Самарской области. Его с тех пор посещают не только молодые сотрудники Управления, но и студенты, школьники, работники предприятий и учреждений г. Самары. Здесь можно получить информацию обо всех этапах истории Управления на протяжении более 95 лет.

По материалам музея и при участии А.А. Козлова были изданы книги «Не выходя из боя» и «Агрессия без выстрелов». Он часто публиковался в средствах массовой информации, рассказывая читателям о событиях в чекистской работе, носивших открытый общественно-политический характер. Причем



*А. А. Козлов в центре, на встрече со студентами КПтИ*

печатался и под своей фамилией, и под псевдонимом «А.Казанский». Регулярно становился Абдурахман Абубакирович участником встреч со студенческой молодежью, различных «круглых столов», активно занимался другой общественной работой по линии КПСС. По праздникам на груди ветерана-чекиста, участника Великой Отечественной войны можно было увидеть два ордена Красной Звезды и две медали «За трудовую доблесть». А всего он имел 17 различных наград, в том числе особо ценившийся в те годы знак «Почетный железнодорожник».

Минем карт бабамнарның ир туганнарына да бу канкойгыч сугышта катнашырга туры килгән. Шуларның берсе – Билалов Шәрәфетдин. 1914 нче елда туган бу карт бабамны 18 яшь тулган көнне Кызыл армия сафларына алалар.

Хәрби хезмәттә аңа Финляндия белән СССР арасындагы сугышта катнашырга туры килә. Финнар белән булган каты бәрелешләрнең берсендә авыр яраланган егет үз якларына дәваланырга җибәрелә. Тик бик кыска була шул бу ял! Әле ярасы да төзәлеп бетмәгән карт бабам 1941 нче елның 22 июнендә башланган Бөек Ватан сугышына беренче көнне ук чакырыла. Шул вакыттан алып, ул – фронтның алгы сызыгында кыю, курку белмәс командир булып сугыша. Гәрчә, аларга алдан бик күп авылларны, шәһәрләрне калдырып, чигенергә туры килә. «Иң авыры – үзеңнең көчсезлегеңне сизү», – дип яза ул бер хатында. – Совет кешеләренең бердәмлеге, рухлары нык булуы, илебез өчен горурлык фашистларны кире куарга ярдәм итә...»

Шәрәфетдин бабай Бөек Җиңү көнен күрә алмыйча, 1945 нче елның язында Латвиянең Лиепая шәһәрен немец фашистларыннан азат иткәндә, батырларча һәлак була. Инде күп еллардан соң аннан авылга аның туганнарына «Сезнең туганыгыз Лиепая шәһәре янында алтынчы каберлеккә күмелде..» дигән хәбәр килә. Шулай итеп, илебезнең бәйсезлеге, Самардан еракта булган Латвиянең азатлыгы өчен үзен аямыйча көрәшкән туганыбыз һәлак булган.

Минем әби-бабаларым – сугыштан соң туган балалар. Бәхеткә, алар буыны, безнең әти-әниләребез андый сугыш афәтләрен күрмичә үскәннәр. Алдагы көннәребез дә тыныч, якты булса иде. Киләчәктә дә безгә шундый авыр сугышларны, кайгы-хәсрәтләрне күрмичә, бу якты дөньяда яшәргә насыйп булсын иде.

*«Яктылык» мәктәбенең 6 «Б» сыйныф укучысы Алсу Гыйматдинова*

## 9 Май – Җиңү көне




2015 нче елның 9 Маенда Бөек Ватан сугышы беткәнгә 70 ел тула. Бу сугыш безнең илебез өчен бик тә газаплы, авыр булган. Бөек Ватан сугышында 27 миллионга якын кеше һәлак булган. Ә бит һәр гаиләдән кем булса да бу канкойгыч сугышта катнашкан, шуларның күбесе яу кырларында ятып калган. Минә минем әтиемнең бабасы – Хафиз Шәкуров та үзенең гомерен безнең бәхетебез өчен корбан иткән. Ул 1903 нче елда Кызылсу авылында туган. Алдан аңа фин сугышында катнашырга туры килә. Анда каты яраланып, ул госпитальгә эләгә. Аннан 1941 нче елда карт бабамны ял итәргә туган авылына җибәрәләр. Яралары төзәлгәч, 1942 нче елда минем Хафиз бабам яңадан, инде Бөек Ватан сугышына китә. Волхов фронтына эләккән карт бабам бик каты бәрелешләрнең берсендә хәбәрсез югала.

Һәр елны 9 Май көнне илебездәге һәрбер кеше сугыш кырында һәлак булган туганын, якыннарын искә ала. Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар һәм илебезнең азатлыгы өчен үзләренең көчләрен кызганмыйча, каты яралар алган фронтчылар безнең якты киләчәгебез өчен тырышканнар бит. Бу көнне мәктәпкә килгән ветераннар безгә үзләренең сугышта күргәннәре турында сөйлиләр. Ә без аларга бу Җиңү өчен зур рәхмәтләребезне әйтәбез.

*«Яктылык» мәктәбенең*
*6 «Б» сыйныф укучысы*
*Гүзәлия Шәкурова*

## Фронтчы бабама

Озын-озын юллар гизеп,
Кайткан бабам сугыштан.
Ил язмышы өчен, диеп,
Дошман белән сугышкан.

Илгә куркыныч килгәндә,
Кергән бит ул утларга.
Үзен бер дә аямыйча,
Каршы торган туплларга.

Өзлексез яуган ут эченә
Баш имичә ул кергән.
Туып-үскән авылын
Төшләрендә ул күргән.

Бабам инде күптән вафат,
Вакытсыз кергән гүргә.
Тыныч тормыш илебездә -
Яшисе иде бергә.

*«Яктылык» мәктәбенең*
*6 «Б» сыйныф укучысы*
*Илнур Исхаков*

## Алар илебез тынычлыгын саклаганнар

Без хәзер гүзәл һәм тыныч илдә яшибез, якты, зур мәктәпләрдә укыйбыз, кайгы күрмичә, бәхетле булып үсәбез.

Әгәр дә 1941 нче елда безнең илебезгә фашист гаскәрләре басып кергәч, Ватанны сакларга бөтен халык бердәм булып күтәрелмәгән булса, ничек торыр идек икән без? Шуңа да туган илебезнең азатлыгын саклап калган кешеләрнең батырлыгы беркайчан да онытылмас!

Бөек Ватан сугышы беткәнгә 68 ел булды. Мин үзем дә, Ульян өлкәсенең Муратовка авылында туып–үскән әнием дә, хәтта әбиләрем дә сугыш чорын күрмәдек. Ә минә карт бабайларым сугыш авырлыкларын үз җилкәләрендә татыганнар, чөнки аларга бу дәһшәтле канкойгыч сугышта катнашырга туры килгән. Минем әнием ягыннан булган Бәшир бабамның әтисе – Зиннәтулла Нәсибулла улы Җаббаров 1941 нче елда сугыш кырында мәңгегә ятып калган. Шуңа да Бәшир бабам әтисез, ятим булып үскән. Аңа 4 сыйныфтан соң, мәктәптә укуын ташлап, әнисе белән колхоз кырында эшләргә туры килгән.

Нәсимә әбиемнең әтисе дә – Исмәгыйль Шаһи улы Әбүбәкеров – Бөек Ватан сугышы ветераны. Ул фронтта пулеметчы булган. 1942 нче елның 4 декабрендә Ржев шәһәре өчен барган сугышларның берсендә аның аягына снаряд кыйпылчыгы тия, һәм ул аңын югалта. Бабамны сугыш кырыннан бер дә белмәгән рус солдаты алып чыга. Хәрби госпитальдә хирурглар аның аягын кисәргә теләгәннәр, тик карт бабам каршы булган һәм, бәхетенә, тиздән терелеп, тагын сугышка киткән.

Фронтта үзен аямыйча көрәшкән бабаем күпсанлы орден-медальләргә лаек булган. Инде Бөек Ватан сугышы бетеп, үз авылына җиңүче булып кайткач, Исмәгыйль бабай «За боевые заслуги» һәм «За победу над Германией» дигән медальләрен мәктәп музеена тапшырган.

Ватаныбызның бәйсезлеге өчен көрәш фронтта гына түгел, тылда да барган. Сугышта катнашучыларны ипи белән тәэмин итәр өчен, минем карт әбиләрем – Заһидә Идрис кызы Җаббарова, Әбидә Зәйнетдин кызы Әбүбәкерова авыл балалары белән бергәләп, Муратовка авылы кырларында иртәдән кичкә кадәр эшләгәннәр. Шулай итеп, Бөек Җиңүгә үзләренең берникадәр өлешләрен кертканнәр.

Илебезне немец юлбасарларыннан, дошманнан азат итү – бөтен халык эше булган. Шуңа да: «Аларга мәңгелек дан һәм хөрмәт! Ә безнең бурычыбыз – ул еллардагы халыкның батырлыгын беркайчан да онытмаска кирәк!» - диясем килә.

*«Яктылык» мәктәбенең*
*4 «Б» сыйныф укучысы*
*Алсу Әбдерәхимова*



## Блокада баласы

Минем әтиемнең әнисе – дәү әбием – Галия Сафи кызы Гыйззәтуллина. Ул 1936 нчы елда Ленинградта туа. Аның балачагы Ленинград шәһәренең блокадада булган бик авыр чорына туры килә. Бу вакытта әбиемнең әтисе һәм кечкенә сеңелесе ачтан үләләр. Аңа үзенең әнисе һәм олы апасы белән 1942 нче елның кышында эвакуациягә эләгеп, «тормыш юлы» дип исемләнгән Ладога күле аша, әтисенең туган ягы булган Татарстанның Апас районы Тутай авылына күч-хәл белән кайтып җитү насыйп була. Шунда әбием авыл мәктәбендә белем алган. Авылның бер дигән егете белән гаилә корып җибәргән. Минем кадерле дәү әбием гомер буе колхозда фермада сыер савучы булып эшләгән. Бабаем белән алар биш бала тәрбияләп үстергәннәр. Хәзер дәү әбием дә, бабам да – лаеклы ялда.Без һәр елны җәен алар янына кунакка кайтабыз. Алар да безне сагынып көтеп алалар. Без барыбыз да кадерле кешеләребез булган әби-бабаларыбызны бик яратабыз һәм хөрмәт итәбез.

*«Яктылык» мәктәбенең*
*6 «Б» сыйныф укучысы*
*Алия Гыйззәтуллина*



## Ватанны сакларга һәрвакыт әзер бабам



Минем бабам – Мидхәт Әүхәт улы Кәлимуллин 1948 елда Самарның Кызылсу авылында туа. Мәктәпне тәмамлагач, Безенчуктагы авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Техникумны бетергән яшь белгеч Совет армиясе сафларына хезмәт итәргә алына. Армиядә бик зирәк, уңган тырыш татар егетен Пенза өлкәсендәге хәрби уку йортына радиостанция җитәкчесе булырга укырга җибәргәннәр. Бу укуын бик «яхшы» билгеләргә тәмамлаган бабам Киев хәрби округына – Умань шәһәренә эләгә. Армиядә хезмәт иткән елларында ул бу округта үткәрелгән бик күп хәрби учениеләрдә, шул исәптән, «Днепр» дип аталганында да, радиостанция җитәкчесе буларак, катнаша. Аннан соң да яраткан бабам, замполит буларак, подполковник дәрәҗәсендә армиядә хезмәт итә. Үзенең туган иленә бирелеп хезмәт иткәне өчен, ул «За воинскую доблесть» медале белән бүләкләнә. Отставкага чыгып, армиядән кайткач, бабам авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Белгечлеге буенча ул – галим-агроном. Хәзер минем бабам – Самара өлкәсенең урман хуҗалыгы министрлыгында отставкадагы подполковник, ә аның Самар өлкәсенең казаклар гаскәрендәге дәрәҗәсе – полковник.

*«Яктылык» мәктәбенең*
*6 «А» сыйныф укучысы Эльвина Мөхәммәтова*

## Киң күңелле әбием



Минем әбиемнең исеме - Разыя. Бу исем гарәпчәдән «Аллага разый кеше» дип тәрҗемә ителә. Чыннан да, ул – бик сабыр кеше. Әбиемә 65 яшь. Гомер буена ул врач булып эшләгән. Минем өчен әбием – дөньяда иң матур, игелекле, миһербанлы, уңган кеше. Ул бик тәмле итеп төрле ашлар пешерә. Дөньяда аның ризыгыннан да тәмлерәк ризык юктыр кебек!

Әбием һәр кешегә хәленнән килгәнче яхшылык эшләргә тырыша. Шуңа аны да кешеләр хөрмәт итәләр. Һәр кеше өчен әби – иң кадерле зат. Мин дә: «Әбием - иң яхшы, иң кадерле, иң әйбәт кешедер», дип уйлыйм. Шуңа да мин әбиемне бик яратам.

*«Яктылык» мәктәбенең*
*6 «Б» сыйныф укучысы*
*Наилә Газизова*

***Үткән гасырның илленче, алтмышынчы елларында татар әдәбиятына, татар шигъриятенә кабатланмас үзенчәлекле үзгәрешләр кертеп, авылдашыбыз Әнвәр Давыдов килеп керә. Аңа халкыбызның күренекле шагыйре Һади Такташ, яисә башка шундый танылган шагыйрьләребез юлыннан барып, дан казанырга мөмкин булыр иде .***
***Ләкин ул үзе яшәгән, иҗат иткән чорның ихтыяҗларыннан чыгып, үзенчә язарга, поэмаларындагы, шигырьләрендәге образларны яңача тасвирларга алына һәм үз юлы белән барып, шигъриятебездә дан казана.***

**Фәрид ЗӘЙНУЛЛИН,** *Камышлы районының мактаулы гражданы. «Камышлы хәбәрләре»*

# Чын кеше, кешелекле кеше, шагыйрь



Әнвәр Давыдов 1919 елның 21 мартында Камышлы авылында күп балалы (6 җан) крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Аңа Әнвәр исеме кушалар. Ул бик якты, нурлы дигән мәгънәне аңлата. Исеменә күрә җисеме дигәндәй, бу турыда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нил Юзиев болай дип яза: «Мортаза агай улына исем сайлаганда аның кем буласын күз алдында тоткандыр, кем булуын теләгәндер, анысы безгә караңгы. Тик шунысы көн кебек ачык: Мортаза агай, күрәзәче кебек, улына исемне дөрес сайлаган...Әнвәр Давыдов белән якыннан таныш булганнар, аның белән аралашканнар яхшы беләләр: ул чын кеше, кешелекле кеше иде. Якты кеше, нурлы кеше. Ул яктылык аның пөхтә, модный киемнәреннән дә, тирән карашлы яшькелт күзләреннән дә сирпелеп тора. Барысыннан да бигрәк бу яктылык аның асыл табигатеннән чыга: эчке культурасыннан, рухи дөньясының байлыгыннан, тормышны яратуының тирәнлегеннән килә».

Әтисе Мортаза абзый, укымышлы буларак, иген игү белән шөгыльләнүдән башка, мөәзин вазыйфасын да үти. Әнвәр кечкенәдән уку-язуга бик сәләтле була, мәктәптә җәмгыять эшләрендә активлык күрсәтә - әдәби түгәрәкләрдә катнашу, стена газеталары чыгару һ.б. Камышлы мәктәбендә җиденче сыйныфны тәмамлагач, 1931 елда Камышлыда яңа гына ачылган авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Әнвәрнең беренче шигыре 1931 елда «Коммуна» Камышлы район газетасында да басыла. Шул ук вакытта Мәскәүдә «Октябрь баласы» журналында бер очеркы дөнья күрә. Шул уңайдан ул Мәскәүгә барып, ул вакыт анда хәрби хезмәттәге Мирза абыйсы белән бергә, беренче мәртәбә Муса Җәлил белән һәм Мәскәүдә эшләүче башка татар әдипләре белән очраша. Бу бала күңелендә мәңге онытылмаслык тирән хисләр калдыра. Укыган вакытында УК колхозда санау-хисаплау эшләрендә, стена газетасы чыгаруда, үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә актив катнашса, Камышлы үзешчән театрында суфлерлык вазыйфасын үти һәм рольләр башкара.

1936 елда Мирза абыйсы чакыруы белән Новосибирск шәһәренә китә һәм анда «Советская Сибирь» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Абыйсын - хәрби кешене башка җиргә күчерү сәбәпле, ул аннан бертуганнары янына Фирганәгә китә һәм анда рус өлкә газетасына урнаша.

1939 елда исәнлеге какшау сәбәпле, табиблар киңәше белән, Рәсәйгә кайта һәм укытучылар, апасы Һаҗәр, җизнәсе Ибраһим Нарбековлар янында, Түбән Новгород өлкәсенең Ләмберә районының Белозерье авылы тулы булмаган урта мәктәбендә рус теле һәм тарих укытучысы булып эшли.

1940 елда Казанга барып, аңа тагын Муса Җәлил белән очрашу бәхете туа. Ул аңа беренче поэмасын укый һәм тәнкыйтьләү, мактау сүзләрен ишетеп, канатланып, Камышлыга кайтып китә. Ләкин аңа

авылда озак яшәргә туры килми. Аны армиягә алалар һәм Монголия чигенә җибәрәләр.

Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан ук аларның частьләрен Көнбатышка озаталар, һәм сугышның башыннан азагына кадәр ул дошманга каршы геройларча көрәшә, орденнар, медальләр белән бүләкләнә.

Әнвәр Давыдов үзенең беренче мәхәббәте Нина Прокопьева белән дә сугыш кырында таныша һәм кавыша. Шагыйрь бу турыда болай дип яза:

*Тар сандыкка сыешмыйлар*
*Безнең искитәрлек мәһәрләр:*
*Көрәш белән үткән һәрбер карыш,*
*Бергә сугышып алган шәһәрләр.*
*Кыңгыраулар чыелдатып түгел,*
*Самолетлар, туплар гөрләтеп,*
*Төште туебыз, халык бәхете белән*
*Җиңү туе белән берләшеп.*

Нина Прокопьева бик тә мөлаем, халыкка ихтирамлы, аралашучан ханым иде. Аның белән олылар «Нина сеңелем» дип, кечеләр «Нина апа» дип эндәшеп аралаштылар. Татарча сөйләшергә дә тиз арада өйрәнде ул. Ярдәмчеллелеге, ачык йөзлелеге белән һәркемне үзенә җәлеп итеп тора иде.

Сугышны тәмамлап, икесе дә җиңүчеләр булып, 1946 елда Камышлыга кайталар. Кайту белән Әнвәр Давыдовны «Югары уңыш өчен» дигән Камышлы районының татарча газетасының мөхәррире итеп билгелиләр. Ул вакыт рус телендә чыга торган «Путь к коммунизму» дигән район газетасы да бар иде. Ул партиянең райком һәм бюро әгъзасы булып сайлана, бөтен көчен, белемен тыныч тормыш хезмәтенә багышлый, шигырьләр, поэмалар язуын дәвам итә.

1948 елда Казанда яшь язучыларыбызның икенче съездында катнаша һәм үзенең «Коммунизм таңы» колхозында» дигән поэмасыннан өзекләр укый, уңай бәяләүгә ирешә. Тиз арада шигырьләре һәм поэмалары белән китаплар басылып чыга башлый. Шуннан аны язучылар Союзы Казанга чакыра.

1952–1953 елларда татар китап нәшриятының баш мөхәррир урынбасары булып эшли, 1953 елда аны язучылар Союзына кабул итәләр, язучылар Союзы идарәсе әгъзасы булып сайлана һәм идарәнең җаваплы сәркатибе итеп билгеләнә. Шул ук вакытта ул иҗат эшенә дә ныклап алына һәм аның тагын күп кенә поэмалары, прозаик, тәрҗемәи әсәрләре, шигырьләр җыентыклары басылып чыгарыла. Әнвәр Давыдов янына күп кенә яшь шагыйрьләр елышалар, ул аларга ихласлык белән ярдәм кулын суза, иҗат юлларында үсәргә булыша. Шуларның берсе - якташыбыз, күренекле татар халык шагыйре Рөстәм Мингалимов.

Әнвәр Давыдов Казанда атаклы шагыйрь булып китсә дә, авылын ташламады, һәрвакыт элемтәдә булды.

Хәтеремдә, илленче еллар уртасында ул үзе белән фронтчы шагыйрь Мәхмүт Хөсәенне алып кайтып, район Мәдәният йортында зур иттереп шигърият кичәсе үткәргән иде. Мәхмүт Хөсәен «Бәрәңге», «Шинелем» дигән һәм башка шигырьләрен укыды. Әнвәр абый да үзенең яңа язган шигырьләрен, поэмаларыннан өзекләр укып, татар әдәбияты турында бик тә эчтәлекле белешмәләр белән әңгәмә алып барды. Шагыйребезнең туган авылын никадәр яратуын «Авылны сагынганда» дигән шигыреннән яхшы аңлап була. Ул шигырьнең берничә куплеты гына да туган авыл турындагы күп сүзле язмаларны алыштырырлык.

*Тау буенда салам түбәле өйләр,*
*Бормалы су, бөдрә әрәмә...*
*Авылым минем, синдә яшьлек*
*көннәр*
*Үтмәгәннәр икән әрәмгә.*
*Төрле җирдә булдым, үстем инде,*
*Эш эшләдем китереп йоласын,*
*Үскән саен һаман ныграк килде*
*Синең күз алдыңда буласым.*
*Күпме илләр, башкалалар гиздем,*
*Шомарып бетте юлда өзәнге,*
*Ләкин миңа, әй, Камышлым минем,*
*Син һаман да җирнең үзәге!*

Шуңа күрә бу шигырьнең монда язылган соңгы куплетын Мәдәният йортыбызга Әнвәр Давыдов исемен РСФСР Югары Советының Президиумыннан сорап бирдергән вакытта эпиграф итеп алган да идек.

Бүгенге көндә Әнвәр Давыдовның ике баласы - кызы Алсу һәм улы Рөстәм үзләренең гаиләләре белән Казан шәһәрендә яшиләр. Алсу ханым Әнвәр абыйның туганнан туган энесе Альберт Ибраһим улы Нарбеков белән шагыйребезнең исән вакытта дөнья күрә алмаган шигырьләрен, хикәяләрен, поэмаларын, тәрҗемәи әсәрләрен җыеп туплап, күп мәртәбәләр бастырдылар.

Альберт Ибраһимович турында аерым тукталып китәсе килә. Ул Әнвәр абыйның Һаҗәр апасының улы. Һаҗәр апа бөтен гомерен балалар укытуга багышлый: Бозбашның башлангыч мәктәбе укытучысы, Камышлының 8-еллык урта мәктәбендә ана теле укытучысы булып эшли. Альберт Ибраһимович - авылдашыбыз, Камышлы урта мәктәбен бик уңышлы тәмамлап, Казанда югары белем ала, техник фәннәр кандидаты, Казан төзүче инженерлар институтында доцент, кафедра мөдире, профессор була. 1999 елдан «Фән һәм тел» журналының җаваплы сәркатибе. Үзенең төп белеме, эше буенча әдәбият-сәнгатьтән ерак тора кебек булса да, ул яклап та күп сәләтле булды, аңа күңел бирүе һәм әдипләр белән ныклап аралашып яшәве аркасында, Әнвәр абыйның иҗади мирасын саклауга зур өлеш кертә алды. Аларның бу фидакарь хезмәтләре Әнвәр Давыдовның иҗат җимешләрен әледән-әле халыкка җиткереп, популярлаштырып торырга мөмкинлек бирде.

Әнвәр абыйның быел 95 яшьлек юбилее. Ул безнең арада күптән инде булмаса да, аның әсәрләре бүгенге көн таләпләреннән дә чыгып язылган булганга күрә, ул үзе дә безнең арада яши кебек, үзенең көр, шыңгырдап торган тавышы белән безгә шигырьләрен укый кебек...

***Суфиян-бабай был отцом моей неродной матери. Любил я его пуще родного: с ним всегда было интересно. В детстве он учил нас играть в шахматы и шашки, выдумывал разные головоломки, загадки. Знал неимоверное количество историй, читал по памяти стихи древних поэтов, сказания и баиты. Не хочешь, а заслушаешься. Когда в селе о радио еще и слухом не слыхивали, у Суфиян-бабая уже был свой приемник – детекторный. Нехитрая такая штучка, работала, а ни электричества, ни батареек не требовала. Большую часть времени дед сидел с наушниками на голове, держал перед собой тетрадку и карандаш, порой что-то записывал. Каждый день к нему приходил сельский почтальон и наполовину разгружал свою увесистую сумку с газетами и журналами, говорил, что дед выписывает периодику больше, чем все сельчане вместе взятые. И народ к нему тянулся, Суфиян-бабай считался в Новом Кадееве негласным аксакалом, с его мнением считались и сельсоветский, и колхозный председатели. Изредка у нас гостил мой дядя Латыйф Заляй, известный ученый-филолог, доктор наук, профессор. И не было случая, чтобы он не заглянул «на минутку» навестить аксакала. Эта «минутка» затягивалась на долгие часы: значит, было им о чем поговорить...***

**Ирек САЙФИЕВ**

# В КАЗАНЬ, К ТУКАЮ...

Село Новое Кадеево, где почти всю свою жизнь прожил Суфиян-бабай, – родина классика татарской поэзии Габдрахима Утыз-Имяни аль-Булгари. (Селу недавно вернули прежнее имя – сейчас это село снова называется Утыз Имэн Черемшанского района Татарстана.) Философские, религиозные трактаты, стихи Утыз-Имяни были в основном написаны на арабском языке и фарси. В советское время мало кто знал об этом поистине энциклопедически образованном ученом, литераторе. А Суфиян-бабай мог часами читать по памяти и переводить на понятный слушателям татарский язык творения великого земляка.




Сам он прожил сложную жизнь. Выходец из бедной семьи, он с детства познал и голод, и нужду. Но никогда не иссякала в нем жажда знаний. Обучился грамоте в родном селе, затем прошел курс обучения в одном из казанских медресе. В начале прошлого века стал учительствовать в селе Новое Ибрайкино (ныне Аксубаевского района РТ). Оттуда переехал в Новое Кадеево и стал муллой в сельской махалле.

Каково было мусульманскому священнику в годы советской власти? Плохо было! Мечеть закрыли, запрещали собираться верующим на пятничные молитвы. Но под разными предлогами они все же собирались в укромных домах. Суфиян-бабай каким-то чудом избежал репрессий, может, потому, что сразу записался в сельхозартель и работал наравне со всеми. Вырастил пятерых детей, трое из них выучились на педагогов, двое стали агрономами. Жил он с семьей старшего сына Азата, директора местной средней школы.



К старости дед совершенно ослеп и очень страдал, что не может читать и писать. Держал постоянно включенным радиоприемник, а потом телевизор. Мы, внуки, собравшись вокруг него, рассказывали о новостях, читали вслух статьи и заметки из газет. Однажды, когда я приехал в деревню на каникулы, застал у нас Суфиян-бабая. Стал дед расспрашивать о Казани, о студенческой жизни. Потом взял в свои ладони мою руку и начал свой рассказ:

– Вот ты готовишься стать журналистом, потому, думаю, тебе интересно будет узнать, как я познакомился с Габдуллой Тукаем...

– А ты разве был с ним знаком?

– Знаком – не знаком, но однажды встречались и довольно долго побеседовали, – дед сильнее сжал мою руку. – Ты слушай и запоминай.

– Когда я начинал учительствовать, в школах стали вводить новометодное обучение, – начал изда-


*Музей Тукая*


*Старая Казань*

лека Суфиян-бабай. – Мы, молодое поколение мугаллимов, зачитывались трудами реформаторов татарского просвещения. У всех на слуху были Ризаэдин Фахретдин, Муса Бигиев, Галимжан Баруди и другие передовые татарские общественные деятели. Но всеобщим кумиром оставался наш любимый поэт Габдулла Тукай. Мои шакирды часто расспрашивали меня о нем, а что я им мог рассказать, если я его в глаза не видел? «Вот съезжу летом в Казань, повидаюсь с ним, потом и вам расскажу», – пообещал я своим ученикам.

Раз обещал – надо выполнять. Снарядился я в дальнюю дорогу. Сначала, пересаживаясь с одной повозки на другую, добрался до Чистополя, оттуда таким же манером, а частью пешком, дошел и до Казани. Стал расспрашивать у прохожих, не знают ли они где живет Габдулла Тукай? Представь себе – знали почти все! И адрес назвали, и дорогу указали. Вот такой он был известный в народе человек!

Пришел к нему на квартиру, но не застал его. Побродил по городу, снова пришел по старому адресу, но результат – тот же. Расстроился сильно, ведь пора в обратный путь собираться, а с поэтом так и не удалось встретиться и поговорить. Решил перед дорогой подкрепиться и зашел в ближайший трактир. Половой (так раньше официантов называли) принес еды и выставил передо мной кружку пенящегося пива. А я этого напитка до того дня никогда в рот не брал и вкуса его не знал. Тут ко мне за столик подсаживается молодой еще человек, невысокого роста, цивильно одетый. Он тоже заказал себе пива.

– Какими судьбами, откуда и чей вы будете? – обратился ко мне незнакомец. А я взял и выложил ему все: что работаю сельским учителем, что обещал своим шакирдам обязательно встретиться с Тукаем, с каким трудом добирался до Казани…

– Вот и не застал я его, считай, – вздохнул я горестно. – Наверное, еще раз придется приехать.

А он не торопясь потягивал из кружки пиво, и продолжал меня расспрашивать: много ли у меня учеников, чему в мектебе учатся, что читают, как народ в деревне поживает. Чувствую, интересует его мой рассказ. И речь моя мишарская немного веселит его.

Принесли нам еще по кружке пива, а разговор продолжался в том же духе: он расспрашивает, а я отвечаю. Когда пришла пора прощаться, он с какой-то хитринкой взглянул на меня и задал свой последний вопрос:

– Так что же ты скажешь своим шакирдам? Что зря катался в Казань, а Тукая так и не застал?

– Так и придется, – снова вздохнул я. А он обнял меня за плечи и негромко произнес:

– А ты скажи им, что видел Тукая, и не только видел, но и говорил с ним, и пиво даже пил.

Как описать мое состояние? Охватила неописуемая радость, и, кажется, счастливее меня не было человека на свете! Я успел расспросить Тукая о его жизни, рассказать, как любят его в народе и каким светочем стал он для людей моего поколения. А он улыбался и продолжал держать меня за руку, вот так, как я держу твою. Чувствовал его тепло и, думаю, тогда мне передалось и биение его сердца. На всю жизнь запомнил его добрые напутствия, особенно те, когда он говорил о необходимости постоянного стремления к знаниям. «Без знаний человек раб, рабом он и останется. А мы, татары, должны и будем свободными», – эти слова врезались в мою память, и я не уставал повторять их своим ученикам…

– Вот ты спрашивал, какое событие самое памятное в моей жизни? – Дед еще сильнее сжал мою руку. – Это – встреча с Габдуллой Тукаем, которая отложила яркий отпечаток на всю мою жизнь. Когда задашься трудным вопросом и не найдешь ответа – обратись к Тукаю. В его книгах сможешь почерпнуть истину и познать смысл жизни.

Суфиян-бабай уже давно покинул этот мир, а я и поныне слышу его тихий, проникновенный голос…



## О единстве

*Его величеством царем*
*От мук все спасены кругом:*
*Тревожен смутой, мятежом,*
*Царь волю дал навеки.*

*Пусть нам свобода впрок пойдет!*
*Зазнайство – прочь! Пускай народ*
*Разумно пользу извлечет*
*Из равенства навеки.*

*О мой народ, глаза раскрой:*
*Мир изменяет облик свой!*
*Довольно спать! Над головой*
*Заря взошла навеки.*

*Упрямых жалко мне слепцов:*
*Очнитесь вы в конце концов!*
*Услышьте будущего зов,*
*Ждет счастье нас на веки.*

*Изгнать вражду пора пришла.*
*Друзья, – разделены тела.*
*Но души мы, не помня зла,*
*Объединим навеки.*

*Свет будет – хоть еще темно!*
*Мы даже яблоко одно*
*Должны делить на всех равно,*
*Дружней сплотясь, навеки.*

*Сойдемся вместе на совет,*
*Идти вразброд нам смысла нет;*
*Невежеству – в нем корень бед -*
*Закроем путь навеки.*

*Доколь татарам в спячке быть,*
*И стрелами друг в друга бить,*
*Взамен того, чтоб укрепить*
*Союз один навеки?!*

*Вперед, единства путь избрав,*
*В товариществе крепче став,*
*Как две руки в один рукав*
*Продетые на веки!*

*** 1905 год

## Туган тел

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*
*Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,*
*Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.*
*И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең белән синең,*
*Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.*
*И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:*
*Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!*

## «Читтәге бик күп өяздә...»

*Читтәге бик күп өяздә, күр, авыллар яктыра,*
*Пар, тату йолдыз кеби, школ белән мәктәп тора.*
*Бу ике дуст, берсенә чөнки аларның берсе тиң,*
*Бертигез Тәгълимнәре дә: берсе — дөнья, берсе — дин.*
*Ва әсәф! Ачлык вә коллыктан бүтән һич бездә юк.*
*Шул гаҗәп: ник бу егерменче гасырда йөз дә юк!*
*Тәгълим — өйрәтү, укыту.*
*Ва ясаф! — Ни үкенеч!*

## Дошманнар

*Күп «җыланнар» сызгырып читтән карыйлар бәхтемә,*
*Борла-сырла, бәдбәхетләр, үрмәлиләр тәхтемә.*
*Аз кеби баскан бу золмәт тормышым йортын минем,*
*Түзмиләр бит бер генә яктан ачылган яктыма!*
*Үзләре... сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән;*
*Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.*
*Дөньядан туйдым, өмидем юк, алар күпсенсә дә;*
*Тик мин үлгәчтән, карагыз, типмәсеннәр нәгъшемә!*
*Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна;*
*Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәля.*
*Якты йөз берлән алам каршы авырлык, ауруын;*
*Чүпкә дә саймыйм йөрәккә кап-кара кан саулуын.*
*Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!*
*Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.*
*Золмәт — караңгылык.*
*Нәгъшемә — табутыма.*
*Фәна — бетә торган.*
*Мөбтәля — «мавыгалар» мәгънәсендә.*
*Саймыйм — санамыйм.*

## Ана догасы

*Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,*
*Көмешләнгән бөтен өйләр, вә сахралар тора балкып.*
*Авыл тын; иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган*
*Халык йоклый — каты, тәмле вә рәхәт уйкуга талган.*
*Урамда әрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;*
*Авыл кыръенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.*
*Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык*
*Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;*
*Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:*
*Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!*
*Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;*
*Карагыз: шул догамы инде тәңре каршына бармас?*
*Уйку — йокы.*
*Яд иту — исенә төшеру.*
*Булсайде — булса иде.*

ИПОЗЕМБАНК
Лицензия ЦБ РФ № 3026

Туган Тел

# КТО, ЕСЛИ НЕ МЫ САМИ?...

Самарское областное татарское общество «Туган тел», НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям» и ООО «ИПОЗЕМбанк» готовы рассмотреть социальные проекты, направленные на улучшение социально-экономического положения татарского населения нашего региона, развитие национальной культуры и образования.

Задача нашей программы – создать условия для увеличения числа активных граждан из числа татар, способных самостоятельно решать как свои проблемы, так и отдельные проблемы татарского сообщества. Именно поэтому мы считаем необходимым стимулировать социальные инициативы «снизу». Любой человек и любая общественная организация могут обратиться к нам со своим проектом и получить нашу поддержку.

По условиям программы, его участники должны представить обоснование своих проектов, пояснить, как будут расходоваться выделенные средства и что это даст в конечном счете непосредственно татарскому населению Самарской области.

Наши организации готовы участвовать в софинансировании проектов, лоббировании бюджетного финансирования для реализации представленных проектов.

## ПОЖЕЛАНИЯ К ПРОЕКТАМ:

- Проект должен реализоваться на территории Самарской области и способствовать достижению позитивных культурных и социальных изменений в татарском обществе.
- Проект должен быть направлен на решение/смягчение существующих социальных проблем; на появление долгосрочных, устойчивых позитивных социальных изменений, улучшение качества жизни татарского населения, региона в целом и/или представителей социально незащищенных слоев/групп населения и людей, нуждающихся в особой поддержке для развития своих способностей и самореализации.
- Проект должен иметь потенциал к масштабированию в других регионах РФ.
- Бюджет проекта должен быть частично обеспечен собственными средствами заявителя.

**По всем вопросам обращаться по тел. 331-47-77, 956-34-33 или электронной почте: Samartatarlary@bk.ru**

# АССОЦИАЦИЯ СОДЕЙСТВИЯ ТАТАРСКИМ ПРЕДПРИНИМАТЕЛЯМ САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ

Организована в апреле 2011 года. Основная цель создания ассоциации – консолидация татарских предпринимателей для взаимовыгодного сотрудничества, их объединения в рамках единого делового и информационного пространства; содействие в организации новых направлений деятельности; сохранение (возрождение) национально-культурных традиций, самобытности и религии татарского народа.

В руководство Ассоциации избраны авторитетные, успешные предприниматели из г.г. Самара, Тольятти, Сызрань, Новокуйбышевск, Камышлинского и Похвистневского районов.

Председателем правления Ассоциации избран доктор экономических наук **Шакуров Ильяс Гумерович.** Членами правления являются **Галимов И.М., Латыпов Р.М., Хакимова Ф.Ф., Шайдуллин М.И., Киямова Р.Г., Хабибуллова Н.А.**

**Члены Общественного совета:** Абдрахимова М.М., Замальдинов Г.Р., Мухаметшин В.Г., Сафин И.Х., Аюпов Х.М.

По всем вопросам обращаться по тел./факс: **953-56-95, 956-34-33**
E-mail: **Tatbizsamara@yandex.ru** Сайт: **www.samtatdelo.ru**

**АССОЦИАЦИЯ – открытая организация и приглашает предпринимателей к сотрудничеству по разным направлениям бизнеса. В Настоящее время региональные Ассоциации работают в Ульяновской, Оренбургской областях. В Татарстане в 2010 году создана Всемирная Ассоциация содействия татарским предпринимателям.**

# “ЮГАРЫ ЭШ ХАКЫ АЛЫР ӨЧЕН, ЛАЕКЛЫ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТЕРГӘ КИРӘК”

***Яратып башкарган эшендә кеше зур уңышларга ирешергә мөмкин. Милләттәшебез Хәмзә Юныс углы Салькин шундый кешеләр исемлегенә керә.***
***Кечкенәдән хәрби булырга хыялланган малай үзен полиция хезмәтенә багышлый.***

**Миләүшә Газимова**



Ульян өлкәсенең Зур Черкели авылында туып-үскән Хәмзә армиядә хезмәт иткәннән соң, әтиәнисе яшәгән Кинель районына кайта. Биредә ул, балачак хыялын тормышка ашыру ниятеннән, милиция бүлегенә эшкә урнашырга бара. Аңа бу өлкәдә хезмәт итәр өчен, башта махсус белем алырга кирәклеген әйткәч, егет Новосибирск шәһәрендәге милиция мәктәбенә укырга китә. Чөнки Хәмзә гади милиция хезмәткәре генә булырга түгел, ә зур җаваплы урында эшләргә теләгән. Ә Новосибирск мәктәбендә нәкъ шундый юнәлештәге белем бирәләр. Шулай ул спекуляция һәм социалистик милекне урлау белән көрәшүче бүлек (урысча ОБХСС) хезмәткәре булырга ниятли.

Кайда гына эшләмәсен, Салькин үзен таләпчән, җаваплы, тырыш хезмәткәр буларак күрсәтә. Шуңа күрә хезмәт баскычыннан ул тиз югарыга күтәрелә.

Хәмзә әфәнде кайларда гына эшләми!

Самар өлкәсенең Алексеевский районында оператив хезмәткәр, спекуляция белән көрәшү бүлегенең өлкән хезмәткәре, криминаль милиция начальнигы, шул районның милиция начальнигы.

Хәмзә Салькинның тормышы һәрвакыт үсештә. Ул Самар дәүләт университетының юридик факультетын, Мәскәүдә эчке эшләр министрлыгы академиясен тәмамлый. Ә яхшы хезмәте өчен аны һәрвакыт рәхмәт хатлары, акчалата премия белән бүләклиләр.

Салькинның фотосурәте Самар өлкәсе эчке эшләр бүлегенең Мактау тактасында эленеп торган. Аның бүләкләре исемлегендә СССРның эчке эшләр министры тарафыннан бирелгән Мактаунамә дә бар.

Хезмәтендә шушындый уңышларга ирешергә Хәмзә әфәндегә аның үз-үзенә һәм хезмәткәрләренә таләпчән булуы ярдәм итә.

Алексеевский районының эчке эшләр бүлеге начальнигы булып 15 ел эшли Хәмзә әфәнде. Ә хуҗа кешенең җилкәсендә тавык чүпләп бетермәслек мәшәкатьләр. Ремонт. Төзелеш. Хезмәткәрләрен машина һәм ягулык белән тәэмин итү, җәмәгать тәртибен саклау.

**Федор Ларьков, Олы Черниговка районының элеккеге башлыгы:**

– Хәмзә Салькин - кеше буларак та, белгеч буларак та мактауга лаеклы кеше. Безнең милиция бүлеген җитәкләгәч, ул бинада да, хезмәткәрләр арасында да тәртип урнаштырды. Миңа аның белән эшләве бик җиңел булды, чөнки ул үз эшен белеп башкара, акыллы һәм көче күңелле кеше.

Тырышып, эшен җиренә җиткереп башкарган начальникның хезмәте югары бәяләнә. СССР вакытында Алексеевский районының эчке эшләр бүлеге өлкә буенча ун иң уңышлы милиция бүлеге исемлегендә санала.

Шулай бервакыт бирегә тикшерү белән баш идарә начальнигы, генерал-майор Александр Реймер килә. Хәмзә әфәнденең үз эшенә мөнәсәбәтен, яхшы тәртибен, милиция бүлеге бинасының югары сыйфатын күреп алган Реймер тиздән Салькинга Олы Черниговка районының милиция бүлегендә дә шундый ук тәртип урнаштыруны йөкли.

Ә биредә, чыннан да, тәртипсезлектән башка берни булмый. Районның эчке эшләр бүлеге бинасында хәтта су да, бәдрәф тә, пар казаннары урыны (котельная) да булмый. Күз алдына ташландык бина килеп баса. Аның эченә керу дә куркыныч була!

– Әле дә ярый ул вакыттагы район башлыгы Федор Ларьков гозерләремне үтәп, безгә ярдәм итте, рәхмәт яусын инде үзенә, - ди Хәмзә әфәнде.

Шулай итеп, Салькин милиция бинасын да өр-яңа итә, хезмәткәрләр арасында да тәртип урнаштыра.

**Владимир Щанькин, Алексеевский раонының элеккеге башлыгы:**

– Без Хәмзә белән 13 ел бергә эшләдек. Биредә ул полковник званиесенә иреште. Аның кандидатурасы турында минем белән дә киңәшләштеләр. Мин моңа шатланып ризалаштым, чөнки Хәмзә әфәнде принципиаль, яхшы оештыручы. Без берберебезне һәрвакыт аңлап эш иттек. Аның үтенече буенча мин милиция бүлеген машина, ягулык белән тәэмин итәргә булыштым. Хәмзә Салькинның инициативасы буенча хезмәткәрләренә фатир белән дә ярдәм итә идем. Ул аларны рухи яктан да, матди яктан да хуплап торды. Хәмзә – яхшы иптәш, үз эшен тәгәл үтәүче кеше.



Системада үзгәртеп кору чоры башлангач, Хәмзә әфәндене Самар шәһәренә күчерәләр. Биредә ул Самар районының 6 санлы полиция бүлеге начальнигы булып хезмәт итә.

Шушы вазифада берничә ел эшләгәннән соң, аңа Олы Глушица районара полиция бүлеген җитәкләргә тәкъдим итәләр. Ул бүгенге көндә дә полковник званиесендә биредә хезмәт итә.

Салькинның полиция өлкәсендәге стажы 34 ел! Бу бит үзе бер кеше гомере. Ә полиция хезмәте – утлы хезмәт. Монда тик чын ирләр генә эшли һәм авырлыкларга түзә ала.

– Аллаһы Тәгалә миңа сәламәтлек, көч-куәт, зиһен биргән, шөкер. Шуңа күрә яраткан эшемдә уңышларга ирешергә насыйп булды, – дип Ходайга рәхмәтләрен укый Хәмзә әфәнде.

Таләпчән ир үзенең кешелеклелек, ярдәмчеллек, мәрхәмәтлелек сыйфатлары белән дә аерылып тора. Полковник сүзләренчә, тормышта иң мөһиме – ул кешеләрне ярату. Шул вакытта барлык ишекләрне дә ачып була. Ә бу сыйфатларны Хәмзә әфәндедә эти-әнисе тәрбияләгән. Әтисе Юныс әзерләүче (заготовитель) булып эшләгән, әнисе Хаҗәр гаиләсен карап, өйдә утырган.

– Без – биш бала. Әти-әниебез безгә карата бик таләпчән булдылар. Алар һәрвакыт укырга, эшләргә кирәклеген әйтеп тордылар. Һәм, Аллаһыга шөкер, беребез дә начар юлга басмады, лаеклы кешеләр булдык, – дип горурланып сөйли Хәмзә әфәнде.

Әле Алексеевский районында эшләгәндә үк анда булачак хатыны белән таныша ул. Наилә шулай ук полициядә хезмәт иткән. Хәмзә әфәнде аның тыйнаклыгын, чибәрлеген ошата. Бүгенге көндә Наилә ханым – хуҗабикә.

Салькиннар Ислам кануннары, шәригать буенча яшәргә тырышалар. Бер генә дини бәйрәмне дә билгеләмичә калмыйлар, дини мәҗлесләр уздыралар. Мәчеткә йөриләр, догаларын укыйлар, туганнарының каберләрен карап торалар.

– Минем әтием – дини кеше иде. Нәкъ ул миндә Исламга мәхәббәт тәрбияләде, – ди Хәмзә әфәнде.

Аның улы Ринат та, бертуганнарының уллары да, аның эзеннән китеп, полиция хезмәтен сайлаганнар. 28 яшьлек Ринат бүген капитан званиесендә өлкә прокуратурасында эшли.

– Улыгызны тәрбияләүгә кем күбрәк өлеш кертте, Сезме әллә хатыныгызмы? – дигән соравыма:

– Тәрбия эшенә икебез дә зур өлеш керттек. Мин мәктәпкә җыелышларга да йөрдем. Ә укуын тәмамлаганда улым миннән үзенә нинди һөнәр сайлап алырга дип, киңәш сорады. Мин аңа үзенең



Хәмзә әфәнде хатыны Наилә белән



Ринат хатыны Гүзәл белән

теләген тормышка ашырырга киңәш иттем.

Шөкер, улыбыз акыллы, эчми-тартмый, безнең сүзгә «колак сала», – дип шатланып сөйләде эти кеше. Атага моннан да зур бәхет буламы!

– Хәмзә әфәнде, Сезнеңчә, җәмгыятьтәге бозыклык кими барамы әллә арту ягындамы?

– Элек бозыклык күпкә азрак иде. Моның сәбәбе, иң беренче чиратта, икътисадта, дип саныйм. Бүгенге көндә халыкка эш табуы бик авыр. Әйтик, элек төрмәдән чыккан кешеләрне эш белән тәэмин итүче махсус оешма бар иде. Хәзер ул юк. Шуңа күрә эшсез кешеләр тагын урларга керешәләр.

Шулай Самар районы бүлегендә хезмәт иткәндә көн саен урлау хәлләре булды.

Шунда элек бер дә хөкемгә тартылмаган бер егеттән аның ни сәбәпле җинаять юлына басуы турында кызыксындым. Ул миңа: «Эш юк. Әгәр эшем булса, урламас идем», – дип җавап бирде.

– Сезгә хезмәт урыннарын еш алмаштырырга туры килгән. Татар милләтеннән булуыгызга кырын караучылар очрамадымы?

– Юк, бер җирдә дә кырын караш күрмәдем. Киресенчә, элек эшләгән районнарда әле бүген дә мине яхшы сүз белән искә алалар, Аллаһыга шөкер. Үзем дә кешеләрне милләте буенча аермыйм, барысына да тигез карыйм. Полиция күзлегеннән ике генә төрле халык бар - кануннарга буйсынып яшәүчеләр һәм закон бозучылар.

Тормышта бөтен нәрсә халык бәхете өчен эшләнергә тиеш. Әгәр дә кеше миңа ярдәм сорап килә икән, мин аңа хәлемнән килгәнчә булышырга тырышам.

– Бүгенге көндә Сезнең кебек җаваплы, тәртипле, хезмәтен чын күңелдән яратып, җиренә җиткереп башкаручы полиция хезмәткәрләре еш очрыймы?

– Элек барыбер хезмәткәрләр ничектер җаваплырак иде. Бүген исә яшьләрне өйрәтергә, тәрбияләргә туры килә. Тәртипләре начар булганнары да еш очрый. Күпләр армиядә хезмәт итмәгән. Бу да үз ролен уйный.

Әлбәттә, яхшы хезмәткәрләр юк дип әйтмим. Андыйлары да бар. Бигрәк тә хәзер полиция хезмәткәрләрен эшкә кабул иткәндә кырыс таләпләр куела. Һәм бу дөрес тә, чөнки югары эш хакы алыр өчен, лаеклы хезмәт күрсәтергә кирәк.

– Нинди шигарьне (девиз) күздә тотып яшисез?

– Эшләргә теләмәгән сәбәп, ә эшләргә теләгән чара эзли.

– Кешеләрдә нинди сыйфатларны өстен күрәсез?

– Иң беренче чиратта, әдәплелекне, тыйнаклыкны. Кеше бар нәрсәгә дә мәхәббәт белән карарга тиеш – өенә дә, гаиләсенә дә, сәнгатькә дә, шигъриятка да дигәндәй. Әгәр дә шулай булмаса, бу кеше уңышсыз була.

Кешеләрне ярату – зур казаныш ул. Берсендә дә үзең турында начар фикер тудырырга ярамый. Тормышта саф күңелле булырга кирәк.

– Ә үзегездә нинди яхшы сыйфатларны билгеләп үтә аласыз?

– Җаваплылыкны.

Таләпчәнлекне.

Кешеләргә мәхәббәтне аерып әйтәсе килә. Боларның барысын да миндә әти-әнием тәрбияләде.

Алар мине таләпчән, җаваплы, мәрхәмәтле, гадел булырга, олыларны хөрмәт итәргә өйрәттеләр. Әти-әнием - яхшы, гади кешеләр иде. Әтием, таләпчән булса да, бик аралашучан, ярдәмчел иде.

Шуны да өстәп әйтәсем килә: әниебез этине, гаилә башлыгы буларак, хөрмәт итәргә өйрәтте.

Әгәр дә мин алардан бу сыйфатларны кучермәсәм, тормышта уңышларга ирешә алмас идем.

– Кимчелекләрегезне дә атап үтегез инде.

– Мин бик тиз кызып китәм. Шулай да берәрсенә гаделсез кисәтү ясаганымны аңласам, аңардан гафу үтенәм.

– Сез бәхетлеме?

– Әйе, мин бәхетле. Яраткан хатыным, улым, хезмәтем бар. Тормышта уңышларга ирештем, полковник званиесен алдым, кешеләрне яратып яшим, Аллаһыга шөкер.

*В самом начале прошлого века на страницах татарских газет и журналов стали часто появляться стихи, подписанные «Хәдичә Сөнгатьзадә». Её имя в нашей семье овеяно легендами и никогда не предавалось забвению. Старшая сестра моего деда Рауфа Сайфетдинова Хадича Сайфетдинова-Шаммасова была одной из небольшой еще тогда плеяды татарских женщин-литераторов и просветителей, смело заявивших о равных правах женщин-мусульманок с мужчинами во всех сферах общественной и культурной жизни.*

**Ирек САЙФИЕВ,**
**член Союза журналистов СССР и РФ,**
**лауреат литературной премии имени Габделжаббара Кандалыя**

# СОЛОВЕЙ НАШЕЙ ПОЭЗИИ

## ИЗ ИСТОРИИ ЖЕНСКОГО ВОПРОСА

Это было время перемен и надежд, пробудившихся на волне революционных событий 1905-го года, которое потом назовут периодом ренессанса татарского просвещения, литературы и культуры. На небосклоне национальной литературы ярко вспыхнули имена женщин-поэтесс Загиды Бурнашевой, Сании Гыйффат, Зухры Тагировой, Галимы Биктемирия, Магруй Мозаффаровой, Хадичи Шаммасовой... Многих из них некоторые исследователи потом назовут зачинателями феминистского движения среди мусульманок.

Вопросы женского равноправия и свободы в татарском просветительстве имеют глубокую историю. Вспомним поэзию Габделжаббара Кандалыя, преисполненную уважением и любовью к женщине, повесть Мусы Акъегета «Мулла Хисметдин», в которой рассказывается о судьбе девушки Ханифы, не подчинившейся выбору родителей и сбежавшей к любимому парню, красавицу Махитап из драмы Габдрахмана Ильяси «Несчастная девушка», порвавшей брачные узы с нелюбимым мужем.

В начале века появляются литературные произведения Г. Исхаки, Г. Тукая, Р. Фахретдинова, Ф. Амирхана о нелегкой, горькой доле татарской женщины. Либерально настроенная татарская интеллигенция ставила женский вопрос во главу угла, подчеркивая необходимость женского равноправия во всех сферах общественной жизни как определяющего фактора зрелости нации. При этом передовые мыслители непременно сталкивались с яростным сопротивлением реакционного духовенства, видевшим в их позиции попытку разрушения векового уклада мусульманской жизни и норм шариата. Муса Бигиев утверждал, что одной из причин кризиса исламского мира как раз и является лишение женщин основных прав и свобод. Ризаэтдин Фахретдин доказывал, что участие женщин в политической и социальной жизни, просветительстве нисколько не противоречит нормам ислама, а остается их естественным правом. Он же утверждал ошибочность запрета посещения женщинами мечетей, ссылаясь на времена Пророка, когда женщины непременно участвовали во всеобщих молениях в мечетях. Наиболее весомый вклад в разработку и развитие женского вопроса внес Закир Кадыйри, который в своей публицистике сумел раскрыть всю глубину проблемы в историческом и общемировом аспекте. Гаяз Исхаки не представлял становление современной татарской нации без устранения бесправия и угнетения женщины.

В 1907 году в Уфе появилось мусульманское дамское благотворительное общество, объединившее женщин-мусульманок независимо от их национальности и материального состояния, ставившее целью вовлечение как можно большего количества женщин в просветительскую и культурную деятельность. Это была первая в России женская мусульманская организация. Пять лет спустя такое же общество образовалось и в Оренбурге. А в 1916 году в Казани открылась первая татарская женская гимназия…

Споры вокруг женского вопроса среди татар то утихали, то возрождались с большей яростью и силой. Сторонники и противники женского равноправия столкнулись в очередной и решающий раз в мае 1917 года на Всероссийском мусульманском съезде. Несмотря на яростнее сопротивление консервативно настроенной части делегатов, сторонникам Исхаки, Максуди, Баруди, Кадыйри, Биги удалось большинством голосов провести резолюцию о наделении всеми гражданскими правами женщин-мусульманок.

Можно говорить, что в дореволюционной России женщины-мусульманки все же смогли пройти трудный путь к своей эмансипа-

ции. Им разрешили посещать мечети, открылся довольно широкий доступ к образованию. Появились общедоступные библиотеки, заработали женские курсы, готовились к открытию ясли и детсады для детей-мусульман.

Как видим, идея женской эмансипации в мусульманской среде первоначально исходила от мужчин. Но чего бы она стоила без самой активной деятельности самих женщин, таких, как и наша землячка Хадича Сайфетдинова-Шаммасова?!

## ЖИЗНЬ, КАК ПЕСНЯ

Мой отец Завдат Рауфович Сайфиев (Сайфетдинов) успел до конца своей жизни составить подробную историю нашего рода – «до седьмого колена». В семейном архиве сохранились фотографии, письма, книги, многочисленные документы. Остались в памяти и его рассказы о нашей многочисленной родне.

Характеризуя каждого из предков, он, в первую очередь, подчеркивал их образованность: какими языками владел, какую имел библиотеку, что написал. У его деда Сунгатуллы-хазрата было четверо детей: по двое сыновей и дочерей. Сам С. Сайфетдинов получил образование в одном из казанских медресе и в 26-летнем возрасте приступил к исполнению обязанностей ахуна-хазрата мечети в селе Большой Калмаюр, расположенного вдали от губернского центра Самары. (Ныне это село Татарский Калмаюр Чердаклинского района Ульяновской области.) Двух сыновей – Мухамметсадыка и Габдрауфа – отправил учиться в Казань. Старшая дочь Хадича (род. в 1875 г.) обучалась под отцовским началом, а потом продолжила учебу в селе Иске Кызыл-су у своего дяди Жамали-хазрата.

Науки ей давались легко. Вскоре она уже могла в подлинниках читать стихи и прозу арабских и персидских поэтов и писателей и свободно говорить на этих языках. Общительная и любознательная она жадно впитывала народные легенды, сказания, пословицы, поговорки, песни. Окружающих восхищало богатство речи молодой девушки, выдававшей её острый ум и глубокие познания. И уже тогда к ней пристало ласковое прозвище «Былбыл» - соловей.

В 1897 году она вышла замуж за сына Насретдина-ахуна Мухаметгарифа Шаммасова и переехала к нему в село Старое Файзуллово (Җурэй), где стала обучать грамоте сельских девочек. В 1908 году Шаммасовы переехали в Татарский Калмаюр. Хадича-былбыл и в родном селе продолжила педагогическую работу. Школа в Татарском Калмаюре одной из первых в округе перешла на новометодное обучение. Вместе с Хадичей в этой школе преподавали и ее младший брат Габдерауф со своей женой Шамседжихан (сестрой Закира Кадыйри).

Деятельность педагогов встречала глухое, а порой и открытое сопротивление темной, забитой части населения. Распространялись неимоверные слухи, что эта школа сеет разврат среди учащихся-девочек, которые – того и гляди – начнут переписываться с парнями. Доходило до того, что некий старец Гинният призывал сельчан забить Хадичу-былбыл палками… (Забегая вперед, скажу, что именно эта школа долгие годы считалась лучшей среди татарских школ в округе, здесь учились народный артист СССР Габдулла Шамуков, поэт Демьян Фатхи, из ее стен вышли будущие крупные ученые, общественные и политические деятели).

